КИРАМ САТИЕВ

# Консерватория
# Армия
# Филармония

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 811.512.145-94:(-1)
ББК 84(2Рос=Тат)6:(-5)
С23

**Сатиев, К.Ш.**

С23 Консерватория. Армия. Филармония : мәкаләләр, җырлар, шигырьләр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 159 б.
ISBN 978-5-298-01844-9

Үзенең гармуннары белән Американы яулаган Татарстанның халык артисты, виртуоз баянчы Кирам Сатиевның әлеге китабында аның күпкырлы иҗаты турында татар зыялылары, сәхнәдәшләре язган мәкаләләр, шулай ук үзе иҗат иткән җырлары, шигырьләре, юмористик әсәрләре, афоризмнары, вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалары һәм фоторәсемнәр урын алды.

УДК 811.512.145-94:(-1)
ББК 84(2Рос=Тат)6:(-5)

ISBN 978-5-298-01844-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Сатиев К.Ш., 2009

«...Татар сәнгатенә иң зур өлеш керткән, иң күп көч түккән филармония артистлары: Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова һәм Кирам...»

*М.Ш.Шәймиев*
*2007, 20 декабрь*
*Казан*

«Если Ильгаму Шакирову аккомпанирует Кирам Сатиев, то это о многом говорит...»

*Ф.Х.Мухаметшин*
*2006, 7 июля*
*Казань, Кремль*

«Мин гомерем буе гармунчылардан «көнләшеп» яшәдем. Бик күп эшләрне эшли беләм, әмма гармун уйнарга өйрәнә алмадым. Ходай андый сәләт бирмәгән. Үзебезнең гармунчыларыбызны күреп танып беләм, һәрберсенә ихтирамым зур. Ә инде Кирам ак баянын иңнәренә асып килеп чыкса, уйный башлаганчы ук кул чабарга әзерләнәм. Кайвакыт баянда Кирам түгел, баян Кирамны уйната сыман. Өстәвенә Кирамыбыз музыкант кына түгел, ул әдәбиятны чит итми, каләменең көчен сынап-сынап ала. Үз татарыбыз, үз гармунчыбыз. Аны мин «Афәрин!» дип алкышлап, иңеннән баяны төшмәсен дигән теләк телим».

*Т.А.Миңнуллин*
*2008, 29 октябрь*

# КЕРЕШ

«Ак баян» исемле икенче китабым басылгач (беренче китабым «Татар баянчылары» иде), бер укучым миңа мөрәҗәгать итеп: «Кирам, «Ак баян»ны укып чыктым. Ошады. Әйбәт булган. Рәхмәт. Син әллә яшь чагыңда көтү көтмәдеңме?» – диде. Бу китабымны кире укып чыктым: гөлҗимеш җыю, кайры төшерү, печән чабу, борчак әйләндерү, умбы (торф) чыгару, атка атланып чүмәлә тарттыру, кибән кою, олтан салу; колхозның, мәктәпнең бәрәңгесен-чөгендерен гектарлап эшкәртү – барысын да санап тормыйм, күпкә китә. Саналган эшләрдән саналмаганнары, һәрхәлдә, күбрәк булыр.

Ничек мин көтү көтүне төшереп калдырганмын? Гаҗәп, ләкин факт. «Ак баян» исемле китапта «көтү» сүзе бөтенләй юк. Шул сәбәпле өченче – «Консерватория. Армия. Филармония» дип аталачак китабымда «хатаны төзәтү»не зур максат һәм изге бурыч итеп куйдым. Беренче карашка «көтү» сүзе әллә ни зур мәгънәгә ия түгел дә кебек. Ә төптәнрәк уйласак?

Көтү. Кемнәр ниләр генә көтми бу дөньяда?! Ана айлар буе бала туганны көтә. Атлап, йөреп китүен көтә. Мәктәпкә барып, яхшы билгеләргә укып чыгуын көтә. Аннары инде бала (укучы) алдагы уку йортына китә, кабул итү имтиханнарыннан соң... диплом көтә...

Төрмәдә утыручы да көтә. Ул амнистия булуны көтә. Дөньяда барлык кеше дә көтә. Депутат буласы кеше сайлауларны көтә. Айлар буе концерт оештыра алмаган артист та шуны көтә. Кандидатны яклап, аның янына басып җырлап, «өлеш чыгару»ны көтә.

...Мин дә көтәм, син дә көтәсең. Барыбыз да революция (инкыйлаб), сугыш-талаш беткәч тормыш яхшырыр дип көтәбез. Ләкин күпчелек очракта ялгышабыз.

Әйе, кешене курку белән өмет арасында тотарга кирәк, диләр. Безне инде күптән куркытып бетерделәр. Ипи белән бәрәңгегә риза, сугыш кына чыкмасын дип яшибез. Куркулар җитәрлек. Совет төрмәләре, бетмәс-төкәнмәс сугыш-революцияләр, урамдагы кычкыртып талау-янаулар, рэкет, бандит, башкисәрләр. Менә болар курку-куркытуның компонентлары... Ә өмет? Өмет ул – көтү дип исбатласам, бик үк дөрес булмас, ләкин чынбарлыкка якын килер. Өмет яшәтә кешене. Өмет белән яшәү, минемчә, барыбер «көтү»гә кайтып кала.

Солдат приказ чыкканны көтә. Мин дә көттем. «Сто дней до приказа»ны Совет Армиясендә мин дә санадым. Көттем. Консерватория тәмамлауны биш ел көттем. Армиядә, әйткәнемчә, оборона (саклану) министрының приказын көттем; аннары филармониягә эшкә урнашу турындагы приказны тагын көттем! Әле мин һаман да көтәм. Тормыш тагын да яхшырыр дип өмет итәм.

Кадерле укучым! Син дә (син дип әйткәнем өчен, үзем белән тиң куйганым өчен, ошамаса, гафу ит) көтәсең, нидер өмет итәсең бит! Гомумән, көтмәгән кеше юктыр ул. Җир – язларны, кеше назларны көтә. Мәктәп укучысы дәрестән чыгара торган кыңгырау зеңгелдәгәнен көтә. Лагерьда, пионерлагерьда, концлагерьда да көтәләр. Каян чыккан ул «от звонка до звонка» дигән сүзләр. Кем уйлап тапкан? Шулай кирәк булгандыр. Ләкин, ничек кенә булмасын, звонок (кыңгырау) сүзе миңа ошап бетми. Шуңа да карамастан ниндидер звонок тавышы белән без бер хәбәр көтәбез. Элек авылларда урыслар тимергә сукканнар, хәзер – техника, тавыш-микрофон заманы. Радио, телевидение, Интернет...

Ә инде бәйрәмне! Бәйрәмне яратабыз инде көтеп алырга. Ну яратабыз да инде без бәйрәм итәргә. Һәм аны күбәйтергә! Аналар һәм табибларның бәйрәме берәр көн иде, икешәр ясадылар. Теге, бу бәйрәмнәр өстәлде һәм өстәлә бара. 1 май, 7 ноябрь һаман элеккечә бәйрәм ителә. Ничек инде аны тарихтан сызып ташлыйсың да ничек итеп бәйрәм итмисең?! Булмаганны!

Чынлап, ныклап, аек акыл белән уйласаң, бу дөнья гел көтүдән тора икән. Һәм гел көтүчедән... Элек авылларда профессиональ көтүчеләр бар иде. Хәзер юк. Шуның өчен көтү – чираттан. Авылда барысы да көтүче. Шәһәрдә дә шулай лабаса. Ул сыер-сарык көтми, трамвай-троллейбус, автобус көтә. Такси көтә. Иренең эштән кайтканын көтә...

...Президент указларын да мин озак көттем. Дөрес, беренчесе – «атказанган» дигәне – кырык яшь тулганчы ук булган иде. Ә менә икенчесен алтынчы дистә башлангач кына күрү, көтеп алу насыйп булды. Хәер, миңа илле беренче яшемдә бирелгән «халык артисты» дигән исемне бер артистыбыз җитмеш яшендә генә алган иде. Бер уйласаң, зарланырга урын юктыр да кебек.

Ничек кенә көттем әле мин көтүне! Үзебезнекен – чират көтүен, колхоз көтүен, кайбер көтүче булырга «оялган» түрәләрнең көтүен... Ялланып көттем. Китап-дәфтәр, кәгазь-каләм алырга. Көтү көтеп велосипед алдым, кулга сәгать тактым. Авылдагы җиденче-сигезенче класс укучысының шушы ике әйбере булмаса, ул кеше егет булмый иде. Кыз-кыркыннар алардан читләшә

иделәр. Өстәвенә әле мин гармунчы да идем бит! Гармунчы булу бер яктан абруйлы булса, икенче яктан аның миңа тискәре йогынтысы да бар иде. Кемдер кызлар куенында вальс әйләнә. Хыял канатларына утырып, сихри мәхәббәт диңгезенең татлы-ләззәтле кочагына кереп чума. Ә гармунчы... Салкын тимер кочаклап гомерен уздыра. Матур кызлар сайланып беткән. Сүз куешылган. Аларның маршруты билгеле. Ә син, мәче сыман йомшак басып, әткәй-әнкәйне уятмасам ярар иде дип, ишекне әкрен генә ачып кереп, йокларга ятасың...

Ләкин мин шәхсән баянчы-гармунчы булып китүемә бер генә тамчы да үкенмим. Киресенчә, горурланып, шатланып яшим.

1964 елның 18 сентябрен мәңге онытасым юк. Әткәй баян(!) сатып алды ул көнне. Өйдә шатлык, ә авылның кайбер «недалекий» кешеләре өчен кайгы булды. Шәйхиҗан, җүләр, йөз утыз сумга баян алган. Бүгенге көн һәм ашау турында гына уйламады әткәй. Офыкка, еракка карады. Алдан күрүче кеше булды. Ләкин, ни кызганыч, зур сәхнәләрдә чыгыш ясауларымны, китаплар авторы булуымны, берничә тапкыр лауреат исемен яулавымны әткәй күрмичә-белмичә якты дөньядан китеп барды. Әнкәй дә шулай. Кызганыч, әмма ләкин шулай булды шул. Нишлисең... Телибезме-теләмибезме, вакыт үз эшен белә. Ашыгырга кирәк. Укырга, эшләргә, көрәшергә, язарга...

Тарих безнең дөреслегебезне аклар, дип әйтә иде әткәй. Шапырына, мактана бу Кирам дип уйламагыз. Юк, Аллам сакласын. «Ак баян» исемле китабыма кереп бетмәгән материаллар урын алыр бу китапта.

Мәктәп еллары, үзешчән сәнгать, Такталачык авылында, Актанышта сигезьеллык мәктәпләр арасында беренче урынны алулар, Әлмәт музыка училищесы һәм, әлбәттә инде, әткәйнең алдан күрүчән булуы мине Казанга әдәбият-сәнгать үзәгенә – консерваториягә алып килде.

Консерватория турында язганчы, «Ак баян» исемле китабым белән таныштырырга кирәк дип таптым. Бу китап минем язмышым: үткәнем, бүгенгем, киләчәгем. Укымаган кешеләр булган очракта, кыскача аның эчтәлеге белән таныштырып узам. Китап ике өлештән тора. Беренче кисәктә – татар зыялыларының виртуоз баянчы иҗатына бәяләре, икенчесендә – Кирам Сатиевның сатира-юмор остасы буларак иҗат үрнәкләре урын алган.

# КОНСЕРВАТОРИЯ

Үз гомеремдә миңа «ия»ләр күп булды: консерватория, армия, филармония, милиция, гимназия... Татар теле грамматикасын искә төшереп, бераз шаяртып әйтсәк (җөмләнең иясе, хәбәре һәм тиңдәш кисәкләре була бит), «ия»ләре күп, ә «хәбәр»ләре азрак булды. Шушы «ия»ләр арасыннан минем өчен иң зурысы, иң кадерлесе, иң җаваплысы консерватория дигәне булды, чөнки бу югары уку йортына теләсә кем кабул ителә алмый. Аның өчен башта музыка училищесын яисә консерватория каршындагы унъеллык махсус мәктәпне тәмамларга кирәк.

...1979–1981 елларда миңа Совет Армиясе сафларында хезмәт итәргә туры килде. Беркөнне «Правда» газетасын (1981) укып утырам. «Указ Президиума Верховного Совета СССР о присвоении звания Героя Социалистического Труда композитору Жиганову Н.Г.» Газетаның шушы Указын, рөхсәт белән кисеп алып, гражданкага алып кайттым, сакладым...

Ул көнне минем нинди горурлык кичергәнне белсәгез иде! Шул вакыттагы ил җитәкчесе Л.И.Брежнев үзе кул куйган! Газетаны күрсәтеп, солдатларга укып йөрдем. Шатлану, сөенү, горурлану хисләре мине урап-чорнап алды. Бу бит – минем остазым, миңа студент билеты һәм консерватория тәмамлаганлыкка диплом биргән шәхес! Консерваториянең оештыручысы, беренче ректоры, СССРның халык артисты, профессор, СССРның Дәүләт һәм башка күпсанлы премияләр лауреаты, опера-балетлар, симфонияләр авторы, композитор Нәҗип Гаяз улы Җиһанов! Үзе!.. Ул җитәкләгән консерваториядә белем алган шәхесләрнең кайберләрен атап узу гына да аның бөеклеген дәлилләүче тагын бер фактор булып тора. Илебезне данлаган, татар сәнгатен дөньякүләм аренага чыгарган Илһам Шакиров, Мәсгут Имашев, Ренат Ибраһимов, Миңгол Галиев, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Рафаэль Сәхәбиев, Мөнир Якупов, Зөһрә Сәхәбиева, Галина Казанцева, Мирсәет Сөнгатуллин, Анатолий Шутиков, Фәнис Гыйльметдинов, Харис Нигъмәтҗанов, Владимир Федотов, Әбүзәр Фәйзуллин, Рөстәм Вәлиев, бу язманың авторы һәм герое Кирам Сатиев – барысы да Нәҗип Җиһанов шәкертләре.

Казан консерваториясе, аның үткән данлы иҗат юлы турында китаплар, җыентыклар дөнья күрде. 1945 елдан алып 1988 елга кадәр (43 ел дәвамында!) аның ректоры Н.Г.Җиһанов булды. Соң-

гы сулышына кадәр җитәкләде ул аны. Бар микән рекордлар китабына кирәрлек тагын шундый җитәкче!.. Һәрхәлдә, мин белмим.

Минем консерватория дипломына Дәүләт имтиханнары комиссиясе председателе Н.Д.Шпиллер, астарак ректор Н.Г.Җиһанов һәм башкалар кул куйган. Моның белән нәрсә әйтмәкче булам? Беркөнне телевизордан тапшыру булды. Наталья Дмитриевна Шпиллер И.Сталинның иң яраткан җырчыларыннан берсе булган икән! Менә сиңа мә! Тарих! Шул шәхес – юлбашчының яраткан җырчысы – ниндидер бер авыл малаеның дипломына кул куйсын әле! Сөйләсәң кеше ышанмаслык хәл бит бу. Ләкин факт!

Әйткәнемчә, консерваториягә юл музыка училищесы аркылы. Ә анда уку кызыклы вакыйгаларга бай. Барысын да язып булмас, ә шулай да, киң катлам укучыларның теләкләрен искә алып, берничәсенә тукталып узам.

...Саша исемле бер егет бар иде (фамилиясен хәтерләмим). Арлы-бирле йөри торгач, синең музыкаль белемең юк дип, контрабас классына алдылар. Беренче курста ук (шул бер генә курс укыды да инде ул) контрабаста (!) «Полет шмеля»ны уйнап маташа иде. (Рус композиторы Н.А.Римский-Корсаковның «Солтан патша» әкиятенә нигезләп язылган операсыннан музыка. А.С.Пушкин либреттосы.) Шуны уйный башлагач, тыңлаучылар: «Это не полет шмеля, а ходьба слона», – дип көләләр иде. «На четвертом курсе, как положено, за одну минуту сыграю», – дип вәгъдә итә иде Александр. Кызганыч, әйткәнемчә, бер генә ел укыды ул. Ә вакыйга болай булды.

Имтиханнарны вакытыннан алда тапшырырга рөхсәт сорап, ул завуч янына керә. Ә тегесе үз чиратында ризалыгын бирми. Студент үпкәләп чыгып китә һәм бераздан портфель күтәреп кире керә. Рөхсәт бирүен үтенеп тагын мөрәҗәгать итә. Завуч тагын кире кага. Ярсыган укучы, портфелен ачып, балта (!) тартып чыгара һәм завучка (уку-укыту бүлеге мөдиренә) ташлана... Бар көченә кычкырып үзенекен таләп итә. Авырган әнисе янына ашыккан студентның теләге тормышка аша, ләкин... ул, училищедан куылып, бөтенләйгә кайтып китә. Ярый әле «балталы имтихан»ның эшен зурга җибәрмәделәр, кем әйтмешли, «чүпне читкә чыгармадылар». Ә Сашаны гел искә алдылар, чөнки ул елларда Яр Чаллы шәһәрендәге автомобиль төзүчеләргә багышлап «КамАЗ» операсын яза башлаган иде. До-мажор тональностендәге гел до-мажордан торган аккордларга нигезләп: «О, КамАЗ, строишься в Набережных Челнах», – дип башланган әсәр, туганда үлгән

баланы хәтерләтеп, язылмыйча, яңгырамыйча калды. Балта Былтырны коткарды, ә Сашаны, киресенчә, «батырды». Татар опера сәнгате зур югалтуга дучар булды. Каләмнең көче балтаныкыннан көчле икәнен булачак композитор аңламады (урысларның «что написано пером, не вырубишь топором» дигәнен әллә белмәгән, әллә белеп оныткан иде). Шул «балта» вакыйгасын әллә ишетеп, әллә ишетмәмешкә салышып, беркем дә «КамАЗ» операсын язарга алынмады. Кем белә, бәлки, шул опера чынлап та милләтебезне, эш сөючән халкыбызны данга күмәр иде?! Нәрсәгә кирәк иде контрабаста «Полет шмеля»ны уйный ала торган яшь талантның канатын кисәргә? Бәлки, аннан Бетховен, Чайковский, Җиһанов кебек бөек композитор чыгар иде. Бу «канлы балта» вакыйгасын көләр өчен түгел, акны карадан аера белер өчен яздым. Беренче карашка бу көлке тоела. Ә чынлап, төптәнрәк уйласак, салкын акыл белән фикер йөртсәк? Мин нәтиҗә чыгармыйм. Миннән акыллыраклар, миннән зурраклар бар бит әле. Моны алар хөкеменә калдырам. Алар хөкем чыгарсын.

...Сукыр укытучы бар иде училищеда. Валентин Макарович. Фамилиясе Царенко. Минем өчен иң куркыныч өч әйбернең икесе бухгалтерия белән теш врачы булса, беренчесе шушы укытучы иде. Минем өчен генә түгел, барыбызга да. Берүзе йөри. Өйдән эшкә, эштән өйгә. Әллә ул адымнарын саный, әллә, кем әйтмешли, колагы белән күрә (укытырга килгәндә тын да алмый карап торабыз), ник училищеның почмагына берәр тапкыр бәрелсен! Уку-укыту аудиторияләренә кергәндә дә шулай. Керә. Без торып басабыз. Ялгыш кына басмый калган укучының фамилиясен әйтә. Кергәч үк пианиноның капкачын ябып куя. Тавыш яратмый. Иң үртәлгәне – кәгазь ерту. Аннан да начаррагы – кәгазь йомарлау. Ул безне психология, педагогика, СССР тарихы һ.б. фәннәрдән укытты. Бүгенгедәй хәтеремдә: тарих фәненнән «Распад колониальной системы империализма»ны сөйләп, бишле билгесе алган идем! Мин бит авыл малае. Шәһәргә чыгып киткәндә дүрт-биш кенә рус сүзе белә идем (бераз арттырыбрак, дөресрәге, киметебрәк әйтүем). «Садитесь, Сатиев, я вам ставлю пять», – дигәне әле хәзер дә колагымда яңгырап тора. Яхшы мәгънәсендә. Менә инде утыз биш ел буе...

Валентин Макарович шахмат уйный иде. Без дәрескә кергәндә, бер студентка мат куйды. Һәм рәхәтләнеп, гадәттәгечә кычкырып көлде. Ә шахматы махсус ясалган иде: тактага тишек тишеп. Аумасыннар өчен. Шушы сукыр укытучы ике кулы белән бер генә капшап ала да... уйный. Җиңә!

Китап тотып чыксаң, сизә. Ишетү сәләте нык көчле. Әйткәнемчә, сукырлар колак белән күрә, диләр. Безгә кадәр укыган бер студент китап тотып чыга. Һәм... тотыла. Гади генә. Җөмләсе болай була: «Советский народ строит бесклассовое общество ком...» – дип әйтә дә битне ача, «мунизм» дип җөмләне тәгәлли. «Коммунизм» сүзе харап итә курку белмәс укучыны. Укытучы аңа берле куя. Бу инде училищедагы иң куркыныч нәрсә иде. Димәк, син зачет тапшырырга тиеш буласың. Булдыра алмасаң, автоматик рәвештә имтиханга кертелмисең һәм музыка училищесы белән саубуллашасың.

Ә бервакыт «ялга баргач, безнең сөекле сукыр укытучыбыз «зрячий» булып кайткан икән» дигән бик тә шомлы, үтә дә куркыныч, җан өшеткеч хәбәр таралды. Имеш, ул элеккечә сукыр булып юри кылана, ә чынлыкта күрә. Тикшереп карый...

Әлмәт музыка училищесын тәмамлап, Казан дәүләт консерваториясенә укырга кердем. Бер курс алда укып киткән дустым белән Бауман урамында кич һава сулап йөрибез. «Чулпан» ресто-раны янындагы ике тиенлек автоматтан кычкырып-кычкырып, көр һәм таныш тавыш белән бер ир кеше сөйләшә. Царенко Валентин Макарович! Без тиз генә «Восток» ягына тайдык. Аның белән алыш-биреш тә юк, ул безне күрми дә, ләкин теге еллар үзенекен итә...

Укыганда егерме сум стипендия бирәләр иде. Шуны утыз көнгә бүләсең. Алтмыш алты тиен була ул. Шуңа яшә, укы, иҗат ит... (Ел саен йөз миллион тонна (!) кара алтын бирә торган нефть башкаласы Әлмәттә бит бу... Ярый мин сәясәтче түгел. Гади бер укучы, уйнарга өйрәнүче.) Ә котлет ашау шул стипендия алган көнне генә була. Айга бер тапкыр. Төп ризык – тозлы тюлька (вак балык). Йөз граммы – өч тиен. Уналты тиенгә бер иш. Ә килькинең йөз граммы биш тиен иде. Шуның өчен алты тиенгә ике йөз грамм тюлька алу отышлырак иде безнең өчен. Гади арифметика. Экономия! (Ул вакыттагы бәяләрне искә төшереп узыйм: шырпы бер тиен, ишине әйттем, трамвай өч тиен.)

Унҗиде яшемнән Әлмәт шиннар ремонтлау заводына каравылчы булып эшкә кердем. Көндез укыганлыктан, йокы туймый. Ә укырга кирәк. Кеше буласы, кеше арасына керәсе килә!

...Берничә егет (егетме, малаймы, кем белсен) милициягә бардык. Беренче сорау: «Сезгә ничә яшь?» – «Унҗиде». Ак чәчле милиция подполковнигы русча: «На работу принимают с 18 лет. Случись что, неужели я с седой головой пойду за решетку. Ведь вы не несете ответственность», – диде. Ә без белер-белмәс рус-

ча белән: «Товарищ подполковник, работаем до первого замечания», – дидек. Һәм эшләдек. Тәртип бозмадык. Менә шуннан соң 1972 елдан алып бүгенге көнгә мин утыз дүрт ел инде штаттан тыш милиция хезмәткәре, әле хәзер дә ГИБДД буенча инспектор. Мәктәп-гимназияләрдә юл кагыйдәләрен өйрәтеп лекцияләр укыйм. Әйткәнемчә, миңа «ия»ләр күп булды: консерватория, армия, филармония, милиция, гимназия. Ә «хәбәр»ләре генә ни өчендер азрак. Бер уйласаң, җөмләдә күпме ия булса, шулкадәр хәбәр булырга тиеш. Юк шул. Иясез җөмләләр булган кебек, хәбәрсез җөмләләр дә була һәм, киресенчә. Шулай ук сораусыз җаваплар һәм җавапсыз сораулар да була. Бар шундый сораулар, җавабын мәңге таба алмыйсың. Ә сәбәбе гап-гади: җавапсыз кеше. Менә шулар бутый да инде дөньяны. Җавапсыз һәм башсыз да булса – бетте баш. Бөтен бәла дә шунда: башлы кеше утырасы урынга башсыз кешене куялар. Ә башсыз кеше үз чиратында башлыларның үзе кебек башсыз булуын хуп күрә. Нәтиҗәдә... Нинди нәтиҗәсе булсын инде башсызлыкның. Нәтиҗә чыгарыр өчен баш кирәк шул! Аннары, һәркем үз урынында түгел. Үз урынында утырса, аннан файда күбрәк булыр иде, һичьюгы, зыяны тимәс иде. Бераз читкәрәк тайпылдым бугай. Мин генә түгел ич тайпылучы. Башкалар да тайпыла, ялгыша. Ә кем ялгышмый бу дөньяда? Кем эшләми, шул ялгышмый, аны әрләмиләр дә. Ул әүлия, ул гөнаһсыз, чөнки аның гөнаһлы икәнен белеп булмый. Гөнаһларын ак күлмәге каплый. Ләкин бер нәрсәне белми: «Күлмәге ак, йөзе кара!» дигән әйтемне...

...Консерватория турында язып, доцент А.В.Тихоновны һәм башка укытучыларны искә алмасак, алар турында фикерләрне әйтмәсәк, кем әйтмешли, олы гөнаһ һәм зур хата булыр иде.

Кулымда ике фоторәсем. Икесенә дә бер үк сүзләр язылган. «Волгоград, Куйбышев, Саратов. Гастроли. Ноябрь 1975 года». Берсендә – Мамай курганында Ватан-ана һәйкәле янында, икенчесендә «Волгоград–Казан» поезды янәшәсендә басып торам.

...Мактанып әйтүем түгел, ул елларда А.В.Тихонов җитәкләгән бу коллектив Советлар Союзындагы студентлар оркестрлары арасында иң яхшыларыннан санала иде. Моның шулай икәнен безнең югарыда әйтеп узган гастрольләр исбатлады.

Саратов (Сары тау) Дәүләт консерваториясенең концерт залында зур концерт башкардык. Штрауснең «Полька-пицикатто»сын уйнагач, бу әсәрне кабатлауны сорап, залдан мөрәҗәгать иттеләр. Ул консерватория укытучысы, баян өчен күп кенә эшкәртмәләр (обработкалар) авторы И.Я.Паницкий иде. Аның соравы буенча

икенче тапкыр башкаргач, ул, А.В.Тихоновка мөрәҗәгать итеп: «Большое спасибо. Это гениально», – диде. Һәм: «Это самый лучший оркестр не только Поволжья и Советского Союза, но и всего мира», – дип соклануын белдерде. Бәлки, ул бераз арттырыбрак та җибәргәндер... Аның бу сөйләме чын күңелдән, ихлас әйтелде. Ул ялганлый алмый иде, чөнки бу сукыр укытучы дөньяны фәкать «колагы белән» күрә. Һәм аны да алдап булмый иде. Дулкынлануын, соклануын йөгәнли алмыйча, озак һәм нәтиҗәле итеп сөйләгәннән соң: «Мне не удобно третий раз просить Вас, Анатолий Васильевич, но, пожалуйста, лично для меня не могли бы Вы исполнить еще раз это произведение», – диде. «С удовольствием», – диде дирижер. Һәм без бу әсәрне өченче тапкыр башкардык. Сукыр укытучы, үзен-үзе белештермичә, урыныннан сикереп торып, көчле итеп кул чабарга тотынды. Аның бу гамәлен шыгрым тулы зал хуплап алды. Ничә минут кул чапканнарын хәтерләмим. Ялган булмасын. И.Я.Паницкийның бу әсәрне дүртенче тапкыр тыңларга да теләге бар иде. Ләкин ул бераз тыйнакланып, сабырлыгын җыеп тыелып калды...

Яшәү аерым бер (прицепной) вагонда булды. Безне, әле бер составка, әле икенчесенә тагып, вокзалда калдырып, исән-сау йөртеп кайтардылар. Бу 1975 елның ноябрь ае иде. Шундый катлаулы гастрольне оештыруда, хәвеф-хәтәрсез башкарып чыгуда, әлбәттә, консерваториянең, безнең кафедраның башка укытучылары да зур ярдәм күрсәттеләр. Ә кайберләре, русча әйткәндә, безне «сопровождать» итеп йөрделәр. Куйбышев–Саратов–Волгоград шәһәрләрендәге гастрольләр минем профессиональ сәхнәгә аяк басуымның беренче адымнары булды...

Хәтер йомгагымны сүтеп, безгә аң-белем биргән, катлаулы профессиональ музыканың тирәнтен серләрен чишәргә ярдәм иткән һәм олы юлга чыгарган укытучыларыма – А.В.Тихонов, С.М.Хәбибуллин, И.И.Шәрипов, Н.А.Черняев, Ю.А.Цагарелли, Я.К.Лебенсон, Ю.Г.Корлев, В.И.Яковлев, Л.А.Яковлевага – чиксез рәхмәтемне һәм тирән ихтирамымны юллыйм. Рәхмәт сезгә, остазларым!

# АРМИЯ

Дүрт тапкыр Советлар Союзы герое маршал Г.К.Жуковның истәлекләрендә мондый юллар бар: «При подготовке операции войск Степного фронта мне пришлось познакомиться с командующим 53-й армии генералом И.М.Манагаровым. [...] А когда была кончена работа, и мы сели ужинать, он взял в руки баян и прекрасно сыграл ряд очень веселых вещей. Усталость как рукой сняло. Я глядел на него и думал: таких командиров очень любят бойцы и идут за ними в огонь и в воду...

Я поблагодарил И.М.Манагарова за отличную игру на баяне (чему, кстати говоря, всегда завидовал!) [...]»*.

Хәрби хезмәт мәктәбен узган солдат буларак, Совет Армиясенә ихтирамым зур иде. Иде. Ни өчен «иде»? Нигә соң үткән заманда? Чөнки мине, «карт солдатны» (армиядә шаярышмы, чынлапмы «дедушка Советской Армии», соңрак «дембель» диләр), күптән түгел Чиләбе өлкәсендә булган канлы вакыйга (бу сүзләрне курыкмыйча язам, чөнки ул чынлап та шулай) тетрәндерде, сискәндерде: яшь солдат исән-имин хәрби хезмәткә барып, ике аягын кистереп (ампутировать итеп) гарип калып, «дедушка» исемен алмыйча кайтып китәргә мәҗбүр булды. Бу фаҗига үзенең кансызлыгы, җансызлыгы, җавапсызлыгы белән хәрби частьны гына түгел, ә бөтен Рәсәйне, алай гына да түгел, бөтен дөньяны таң калдырды. Начар мәгънәсендә, әлбәттә.

«Дедовщина» дигән төшенчә без хезмәт иткәндә дә бар иде. Ләкин болай ук варварларча, вәхшиләрчә түгел иде!

Ата-ана баласын үстереп, исән-сау килеш Туган илен сакларга җибәрә һәм... башы миңгерәүләнгән, эч-бавыры изелгән, вөҗданы тапталган, йөрәге канланган, ике аягы киселгән, мәңгелек гарипләнгән баласын – күз карасын каршы ала. Нинди куркыныч, җан өшеткеч... Сүз таба алмыйм. Башка, акылга сыймаслык хәл.

Ничә еллар, дистә еллар Советлар Армиясенә мин шәхсән рәхмәт белән, олы ихтирам, ярату хисләре белән: «Рәхмәт сиңа, гражданкада белмәгән күп нәрсәләргә өйрәттең», – дип йөрдем. Бизмәнгә салып үлчәсәң, чынлап та, яманга караганда яхшысы күбрәк иде. Уены-чыны белән әйтсәк, ашау-эчү, йоклау мәсьәләсе анда ныклап, уйлап, җиренә җиткереп уңай якка хәл ителгән. Алга-

* Ж у к о в Г.К. Воспоминания и размышления. М.: АПН, 1971. С. 473.

рак китеп тагын шунысын да әйтим: армиядән кайтып филармониядә эшләгәндә, менә бу ике мәсьәлә мәңгелек проблемага әйләнде. Кунакханәдә урын юк, фатирга кертмиләр. Безгә кадәр фатирда яшәү табигый хәл булган: беренчедән, артистлар аз, икенчедән, тәртипле. Сәхнәгә гитаристлар, шәһәр тәрбиясе алган маңкортлар, «өлкән братлар» менгәч, фатирларга керү-кертү бетте. Клуб сәхнәсендә йоклаган вакытлар да шактый булды. Ә икенчесе – ашау-эчү (туклану) чын мәгънәсендә газап иде: кич ашханәләр ябылган, кунакханәдә суыткычлар юк, булса да, андагы хезмәткәрләр өчен генә. Анысы да әллә ни куркыныч нәрсә түгел. Талон заманы килде. Менә монысы инде газап иде. Азык-төлек торак урын (прописка) буенча бирелә. Ә без гастрольдә. Кулда талон юк. Кемнең кулында, шуның авызында, диләр бит. Шул уңайдан бер күңелсез вакыйганы искә төшереп узсам да ярыйдыр.

Әйткәнемчә, талон вакыты. Оныгына йөз грамм пешкән казылык сорап, зур исемнәр алган һәм олы ихтирамга лаек булган бер артистыбыз кибеткә керә. Сабыен ияртеп, әлбәттә. Казылык бирми чыгаралар. Беренче карашка кибетче хаклы. Талоның юк, сау бул. Ә инде икенче яктан карасаң, милләтебезнең горурлыгы, йөзек кашы, куанычы-мактанычы булган шәхеснең (хәзерге көндә инде ул легендага әйләнеп бара) оныгына йөз грамм казылык бирсә, әллә ни зур югалту булмас иде. Бар – закон (канун), бар – кешелекле булу. Бөтен нәрсәне дә законлаштырып булмый һәм бар нәрсәне дә кешелек күзлегеннән чыгып кына да хәл итү мөмкин түгел. Алтын урталык дигән төшенчә бар. Законны, кешелек сыйфатына кушып, урталай бүләргә кирәктер. Ә бәлки, мин ялгышамдыр. Кайсы дөрес, кайсы хаклы – әйтү кыен.

Армиядә менә шушы югарыда искә алынган кайбер мәсьәләләрне чишәсе юк иде. Алар инде күптән чишелгән һәм хәл ителгән. Бу әле башы гына. Чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтте безне армия. Баштан алып аякка кадәр. Чәчләр, тиешле озынлыкта калдырып, матур итеп алынган, муен чиста итеп кырылган. Атнаун көн саен старшина аяк-кул тырнакларын тикшереп тора (балалар бакчасымыни, болай дип әйтүем яхшы мәгънәсендә). Төймә-сәдәфләр барысы урынында, киемнәр яхшы итеп үтүкләнгән, аяк киемнәре ялтырап тора...

Күңелем белән, җаным-тәнем белән яхшыны, кызыклы хәлләрне, көлкеле-мәзәкле вакыйгаларны язып узмакчы булам.

Нишлим, «пистолетым итте хыянәт» дигәндәй, каләмем тыңламый: һаман Чиләбегә таба тарта. Дөрес, мин хезмәт иткәндә дә яхшы белән яман гел янәшә атлады. Ләкин бу кадәр түгел! Кеше кешелеген, сәламәтлеген югалтып, Кеше булудан туктап, ике

аягын кистереп, Мәңгелеккә туктап калды. Аның йолдызы сүнде, Кояшы батты! Ата-анасын, әби-бабасын, күрше-күләнен, аң-белем биргән укытучыларын, кыскасы, Ватанын, туган йорт-нигезен сакларга барган егет, Солдат, арабыздан мәңгелеккә рухи яктан китеп барды. Бу дөньяда аның аккан каны һәм чыкмаган җаны гына калды! Күңел сыкрый, йөрәк әрни, ниндидер бер сихри-кара көч бәгырьне телгәли. Һәм иң аянычы шул: бу Солдатка (баш хәреф белән язуым хата яки очраклы хәл түгел) инде бернәрсә белән дә ярдәм итеп булмый. Булмый! Һәм булмаячак! Менә бит хикмәт нәрсәдә!..

Ә менә без хезмәт иткән урында бер солдат икенчесен атып үтерде!.. Автоматтан. Шаярып. Үлгәне «досрочно» цинкланган табутта өенә кайтып китте, ә тегесе «бушлай ашата торган оешмага» озатылды. Монысы Чиләбедән дә куркынычрак! Ләкин аерма шунда: беренчесе – саксызлыктан, ә тегесе – уйлап эшләнгән фаҗига. Злоумышленно! Преднамеренно! Бәлки, Чиләбе солдаты терелер, савыгыр, аңа протез аяклар куярлар, өйләнер, балалары, оныклары булыр. Ләкин йөрәгенә мәңгелеккә тирән уелып кергән яра аның күңеленнән китәр микән? Терелсен, ашасын, эчсен, яшәсен. Ә менә инде тегесе... цинкланган табуттагысы... Аннан кире кайту юк. Юк. Юк...

Дөресен әйтәм, баштарак мин армияне ни өчендер өнәп бетермәдем. Консерваториядән соң, егерме дүрт яшемдә, Илһам Шакиров, Ренат Ибраһимов, Зилә Сөнгатуллиналар кебек диплом алып, «сез», «рәхим итегез» кебек сүзләрдән соң «твою», «мою», мат-перематлар, өч хәрефле, биш хәрефле сүзләр мине шок хәленә калдырды. Җөмләдә дүрт сүз булса, шуның өчесе китап сүзләре түгел иде. Урысча белмәгән өчен түгел, «закулисный», «нецензурный» сүзләрне аңламаган өчен (дөресрәге, аңларга теләмәгән өчен). Авыр булды хезмәтне башлау. Шуннан соң мин тиз генә бер шигырь язып куйдым.

### ТӘМУГ

Монда икән тәмуг эшчеләре,
Хәшәрәтләр, зәһәр еланнар.
Чагар өчен, телен салындырып
Чирек гасыр көтеп торганнар.

Җыен этлек, урлау, талау, сугу,
Кыерсыту, мыскыл итүләр.
Кеше сату, көлү, мәсхәрәләү,
Зур булсаң да кече итүләр!

Монда икән Арыслан-патшага
«Син – Куян» дип паспорт бирәләр.
Хәлең җитсә, булдыралсаң, дустым,
Бу тәмугны үт син тирәләп.

«Стариклар» монда йөргән була,
Биш-алты яшь миннән кечеләр.
Киребеткән, явыз һәм тормыштан
Артта калган надан кешеләр.

Кафе-кофе – аңа бары да бер,
Аералмый акны карадан.
Аптеканы оптика дип аңлый,
Укымаган, ул бит чи надан.

Шул наданнар мине чолгаганнар,
Коллык кебек урап алганнар.
Ярты елга алдан килгәннәр дә
Әйтерсең генерал булганнар.

Барысын да язу мөмкин түгел,
Солдатта булганнар аңларлар...
Шаһит булсын «тумбочка» янында
Каравылда аттырган таңнар...

«Гнев рождает поэта», – дип дөрес әйткән Карл Маркс.

Гадәттә, кая гына, кайда гына, нәрсә генә язсаң да, кызык хәлләр, көлкеле вакыйгалар турында язуны, сөйләүне үтенәләр. Армиядә кызык-мәзәк хәлләр шактый. Бер мәзәгем өчен әздән генә мине гауптвахтага (гади тел белән аны «губа» диләр) утыртмадылар. Тагын да гадирәк тел белән әйтсәк, губа – төрмә эчендәге төрмә, ягъни солдат төрмәсе була. Башта гауптвахтаның нәрсә икәнен аңлатып узыйк. (Белмәгәннәргә һәм белергә теләмәгәннәргә.) Таш диварлар. Идән-түшәм – бетоннан. Урындык (үлчәме 40 ´40 см) – тимердән. Тәрәзә төбенә беркетеп, ябыштырып куелган. Күчереп булмый. Тәрәзә пыяласы йә юк, йә ватылган (махсус). Урамда 30–35$^{0}$C салкын. Караватта тимердән, стенага чылбыр белән беркетеп куелган. Булырга тиеш такталарның берсе генә дә юк! Кемдер аны ягып җылынган. Караватның дүрт тимере (тышкы ягы гына) калган. Нинди генә бөек комбинатор яки фантазер булсаң да, анда йоклап булмый. Йокы мәйданы, әйткәнемчә, урындык – 40 ´40 см. Солдат идәнгә ята. Нишләсен,

бичара. Ә анда ятканны күрсәләр, берничә чиләк бозлы суны таш идәнгә түгәләр. Солдат урындыкка «кунаклый». Арт санына салкын тимәсен өчен, кирза итекләре өстенә утыра, портянканың берсен аякларына, икенчесен баш, муен тирәсенә урый, чөнки төнгә бирелергә тиешле шинельне бирмиләр, бирсәләр дә, талап алып чыгып китәләр. Каршы әйтсәң, тагын өч сутка өсти. Дәшмәү хәерле, чөнки пистолет тоткан офицерга, автомат аскан солдатка бер пар кирза итек белән син бернәрсә дә эшли алмыйсың.

Бу зарланумы? Армиянең начар ягын күрсәтергә тырышумы? Һич юк. Син анда эләкмә. Кем кушты? Нәрсә этәрде? Тәртип бозган өчен офицерларның (прапорщикларның) сүзен аяк астына салып таптаганың өчен эләктең син анда. Булачак солдат, мыегыңа чорна син боларны! Тәртипле бул. Мин-минлегеңне башыңнан гына түгел, аягыңнан ук мәңгегә чыгарып ташла. Ләкин бу чүпрәк бул дигән сүз түгел. Үзеңә тиеш булган вазифаны җиренә җиткереп үтәү белән чүпрәкбаш булу – икесе ике нәрсә. Ә инде җитәкчеләр белән хисаплашмый йөрсәң, сине гауптвахта көтә. Хәйләкәр булып кылансаң да, чамадан тыш акыллыларга да, үткеннәргә дә шул ук бер юл.

«Акыллылык бәласе»н («Горе от ума») мәктәптә өйрәнгән идек. Менә шуның өчен, акыллыбаш булуым аркасында, «губа»га утыра яздым. Уйланып йөрдем-йөрдем дә «Нәрсә ул армия?» дигән сорауга болай дип җавап бирдем: «Армия состоит из трех компонентов: из автомата, тряпки и нервотрепки». Шушы «канатлы» сүзләрне җимеш ашый торган яклардан килгән солдатка өйрәттем. Шаярып. Ул ятлап йөри. Коридорда. Кычкырып-кычкырып кабатлый: «Армия состоит из трех...» Тагын ятлый, тагын кабатлый. Кирәк бит! Шунда бер офицер тыңлап тора икән. «Солдат, Уставта мондый сүзләр юк, кем өйрәтте?» – дигән. Ә теге җимеш ашаучы беркатлы малай (малай сүзе «мал» дигән сүздән алынмады микән, сүзнең тамыры шул уйга этәрә): «Рядовой Сатиев өйрәтте», – ди. Сөйләшә белмәгән авыздан нәрсә яхшы диләр әле? Чүт утыртмадылар «губа»га. Партиягә кандидат булуым коткарды. (Коммунистларны, кандидатларны гауптвахтага утыртырга ярамый иде.) Шуннан соң шаяртканым, шаярып сөйләшкәнем булмады...

Шагыйрь әйтмешли, бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте: кайсыгызның кулы җылы, бәйлисе бар йөрәкне. Шаярмаска өйрәтте армия, тәртипкә өйрәтте. Чисталыкка, пөхтәлеккә, әдәпкә...

Гадәттә, укырга кызык булсын дип, күңелле, көлкеле хәлләрне яз, сөйлә, диләр. Күп очракта хакыйкать күңелле булмый инде ул.

...Химбатта хезмәт иттем мин. Анда илле дүрт шигырь яздым. Шуларның барысын бергә туплап, «Химбат дәфтәре» дип аталган шигырь китабы (җыентыгы) хасил булды. Иң беренче шигырем «Санчасть гөле» дип атала. Күн (кирза) итекләр аякларны кырып, шештереп, хәрби частьның хастаханәсенә керергә туры килде.

Эх син, гөлем, минем сагынуымны,
Януымны аңлый алмыйсың!
Күп калмады кайтыр көнеңә, дип,
Алдыйсың бит мине, алдыйсың!..

«Химбат дәфтәре»нең тышына, чәнечкеле чыбыкка урап, «Вольск, 12 ноябрь, 1979 ел. Казан, 18 май, 1981 ел» дип язылган.

## МИН КАЙДА?

«Кайда син хәзер, нинди хезмәттә?»
Җавап тик бер: түгел ул ялган,
«Двадцать пятый отдельный батальон
Химзащиты» диеп аталган.

Калын урман, куе томанлыкта,
Ул урнашкан Идел ярына.
Сәламемне җил һәм хатлар аша
Озатып калам сөйгән ярыма.

Резин итек һәм противогазлар,
Плащлар кия адәм баласы.
Төшләрендә – сәхнә, ак баяннар,
Уйларында – Казан каласы.

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Чорналган ул төрле ягыннан.
Ел ярымны эчендә үткәргәч,
Урап үтәрмен мин яныннан.

Кулда чүпрәк, иңдә автомат,
Өстә х/б*, аста наралар.
Рөхсәт булса ятып йокларга,
Бигрәк йомшак шушы такталар.

* Х / б – хлопчато-бумажное обмундирование.

Сигез постны көн-төн саклыйбыз
Кар, буранда, ачы җилләрдә.
Ак чәчләрем арткан саен арта
Химбат дигән ерак җирләрдә.

Килер бер көн: химбат капкасын
Шыгырдатып каерып ачармын!
Чал башымнан чәчләр коелганда,
Бик еракка синнән качармын.

Нигә соң мондый пессимистик рухта язарга? Үзем теләп бардым бит армиягә. Берәү дә көчләмәде. Егерме дүрт ел буе «Син армиядә булмаган, дөнья күрмәгән пацан» кебек ярым мәсхәрәле, ярым рәнҗетелүле сүзләр ишетеп йөрдем. Һәм, ниһаять, 1979 елның 12 ноябре. Чирек гасырга якын көтеп алган көн! Ел ярым хезмәт итеп исән-сау кайта алсам, мине инде беркем дә, беркайчан да «рәнҗетмәс», беркем дә миңа, син хезмәт итмәдең, дип, бармак белән төртеп күрсәтмәс...

Беренче чакыру (повестка) 1979 елның 26 октябрендә килде. Бардым хәрби комиссариатка. Тегесе туры килми, монысы болайрак дип, өйгә кайтарып җибәрделәр. Өй дигәнем тулай торак. Буп-буш бүлмә. Бернәрсә юк. Мин бит кайтырмын дип китмәгән идем. Ярый комендант, хәлгә керең, ачкычны кире бирде. Дус-ишләрем (рәхмәт аларга) кайсы акча бирде, кайсы кәстрүл белән аш кертте, чәй кайнатты... Кабат чакыруны көтәм. Юк кына бит. Үземне ниндидер гөнаһ иясе дип хис итәм. Коменданттан, малайлардан уңайсыз. Мин иждивинец – әрәмтамак. 31 октябрьдә килде кәгазь: «Взять с собой кружку, ложку...» Алга – Татвоенкоматка. Тагын шул ук хәл: документация туры килми, кабат чакырырбыз, диләр. Ни йөзем, ни күзем белән тагын кайтыйм тулай торакка? Ә кая барасың? Апаларга? Юк. Үзләренең дә фатирлары кысан... Зарлану булмасын, мине гомерем буе ике әйбер газаплады, җанымны кыйнады, бәгыремне телгәләде: йокларга урын юк, кесәдә акча юк. Армиядән кайткач та шулай булды. Гастрольдә дә болар еш кабатланды! Бәхетеңне бер керпе үпсә, диләрме әле...

...Офицер, кыска һәм аңлаешлы итеп: «Ждите повестку после Октябрьского праздника», – дип тагын кайтарып җибәрде. ...Ә хәзер ничек? Хәрбиләр белән милиция хезмәткәрләре булачак солдатларны өйләренә килеп аулап йөриләр. 1979 елның 31 октябрь белән 12 ноябрь арасы ел ярым хезмәт иткәннән дә озаграк тоелды миңа. Унике көн, унике төн ярым ач килеш, матрассыз

диван-караватта баш астына куртканы җәеп, радио-телевизорсыз бүлмәдә берүзем газап чиктем... Менә чын гауптвахта кайда ул!

Ниһаять, 1979 елның 12 ноябре. Татвоенкомат. Автобус. Поезд. Алып кына китсеннәр. Ә хәрби комиссариатка шушы көнне уйлап ук бардым: документларыгыз туры киләме-юкмы, анысы сезнең эш, ләкин мин кире тулай торакка кайтмыйм. Һәм шулай булды да. Алып киттеләр...

Поезд алга ыргыла. Волгоград поезды. Бу транспортта консерваториядә укыганда доцент А.В.Тихонов җитәкләгән студентлар оркестры белән Куйбышев (Самара), Саратов, Волгоград шәһәрләренә гастрольләргә барган идем. Таныш булмаса да, таныш яклар... Килеп җиттек. Стройга тезеп, безне тагын алып киттеләр.

...Икенче көнне хәрби киемнәр тоттырдылар. Шул көнне тагын бер шигырь язып ташладым.

СИН КЕМ?

«Син ирме?» – дип әгәр сорасалар,
Башта уйла, аннан җавап бир.
Совет Армиясе сафларында
Хезмәт иткән егет кенә ир!

Нинди ир син, хәтта уңны, сулны,
«Отбой», «подъем»нарны белмәгәч.
Чәнчә-чәнчә тырнак төпләренә,
Кара погоннарны текмәгәч!

«Бегом» дигәч, кулны алга куеп,
«Равняйсь» дигәч, уңга борылып,
Таң атканда йөгермәдең шул син,
Йөрмә, дустым, ир саны булып.

Кара төндә, яңгыр, кар-буранда
Сакламадың илнең чикләрен.
Алты сумга сатып аласың да
Черетәсең кибет итләрен.

Хезмәт итү авыр һәм мактаулы,
Туган илне сөю, ярату.
Күреп, тоеп белмәгән кешегә
Мөмкин түгел аны аңлату!

«Син ирме?» – дип әгәр сорасалар,
Башта уйла, аннан җавап бир.
Совет Армиясе сафларында
Хезмәт иткән егет кенә ир!

Кайда һәм нинди шартларда яздым соң мин бу шигырьләрне?

ШИГЫРЬЛӘРЕМ КАЙДА ЯЗЫЛГАН?

Кышкы салкын. Постта торган чакта
Туңа иде каләм карасы.
Тула иде кар өстенә язып
Чәнечкеле чыбык арасы.

Язган сүзләр яз көне эреде,
Ә йөрәктә калды эзләре.
Барысы бергә теркәлделәр алар
Тәшкил итеп «Химбат дәфтәре»н.

Салкын чакта алар туңмадылар,
Йөрәгемнән җылы биргәнгә.
Кар эреде, шигырьләрем исән,
Чөнки сеңгән алар җиргә дә.

Бик күпләрен «тумбочка»да яздым,
Дневальный торган чагында.
Офицерлар күрмәгән вакытта,
Озын төннең салкын таңында.

Кайберләрен айның яктысында,
Иҗат иттем калын урманда.
Шигырьләрем һаман яфрак ярыр,
Чәчәк атар карлы буранда!

Алты ай «тумбочка»да дневальный торгач, каравылга йөри башладым. Автомат. Чәнечкеле чыбык. Пост. Уен эш түгел. (Несение караульной службы является выполнением боевой задачи... – ст.97. Устав Г и КС ВС СССР.) Автомат. Ике магазин. Утызар хәрби патрон. Штык-нож.

## КАРАВЫЛГА БАРУ

Караңгы төн. Йоклый тереклек.
Дөнья тынган. Барысы ял итә.
Дүрт-биш егет никтер йокламыйча
Таңнан торып каядыр китә.

Уң иңнәргә нидер асканнар,
Сүзсез генә алга баралар.
Караңгылык, тынлык томанны
Нәкъ икегә алар яралар.

«Кемнәр килә?» дигән сорауга
Разводящий бирә җавапны.
Егетләрнең кемнәр икәне
Мәгълүм була бары ул чакны.

Бер-бер артлы җепкә тезелеп,
Елан шуган кебек атлыйлар.
Һәр көн саен шушы сукмакны
Әллә ничә тапкыр таптыйлар.

Каравылга – автомат иңнәрдә,
Аякларда кирза итекләр,
Тәүлек буе уяу торалар,
Керфекләрен какмый егетләр.

Кар-буранда, ачы җилләрдә
Һаман саклыйм хәрби постларны.
Ә бит күпләр өстәл артларында
Шушы вакыт әйтә тостларны.

Миңа хәзер тостлар кирәк түгел,
Эшем мөһим – мин Ил сакчысы.
Йозак бикле, ләкин онытмыйм:
Тынычлыкның миндә ачкычы!

«У природы нет плохой погоды» дигән җыр бар. Нинди генә һава шартлары булмасын: җилме, яңгырмы, эссе кояшмы, караңгы төнме, буранлы көнме – часовой һәрвакыт үз урынында – постта. Постны ташлап китү хәрби җинаять санала...

## ЯҢГЫР ЯВА, ЯКИ НАЧАР ЗАКОН

Яңгыр ява... Берөзлексез ява...
Плащтан үтеп шинель чылана.
Портянка – сыгарлык, ә чалбарның
Балаклары тәнгә сылана.

Часовойга яңгырдан качам дип
Өйгә керү катгый тыела.
Мондый шартлар уяу саклар өчен
Устав тарафыннан куела.

Кайбер постта өйләр бөтенләй юк,
Гел әйләнеп алга барасың.
Таш яуса да ташлап китмим мин
Чәнечкеле чыбык арасын.

Постны ташлау – хәрби җинаять,
Ташлап китү – төрмә дигән сүз.
Син бит солдат, совет солдаты,
Яңгырда да, салкында да түз.

Алга атлыйм, карыйм сәгатькә,
Туктаган күк аның телләре.
«Хәрәкәтлән, җылынырсың», – ди
Көзге төннең ачы җилләре.

Ләкин җилләр исә каршыга.
Бу – тормышның кырыс законы.
Шул законнар янып көл булыр,
Кабынгачтын дембель ялкыны!

Мин хезмәт иткән хәрби частьны (химбатны), ярым шаяртып, «караульно-строительный батальон с химическим уклоном» диләр иде. Чыннан да ул шулай, «через день на ремень» дигән төшенчә бар иде. Һаман шул бертөслелек: автомат, чәнечкеле чыбык һәм... тынлык... Тәүлек саен шулай. Ирексездән Муса Җәлилнең:

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз,
Көне-төне шунда казынабыз,
Әйтерсең лә тирес корты без, –

дигән шигырь юллары искә төшә иде.

## ЧӘНЕЧКЕЛЕ ЧЫБЫК

Муса абый, әйткән сүзең дөрес,
Август төне чынлап караңгы!
Чәнечкеле чыбык хәтерләтә
Яшәү белән үлем арасын.

Ике яктан чәнечкеле чыбык
Биек итеп ерак сузылган.
Гомереңнең соңгы минутлары
Шушы ике арада булган.

Чәнечкеле чыбык һаман тырный
Мораль яктан күңел кылларын.
Шаһит булып искә төшерер ул
Онытылмас хезмәт елларын.

«Чәнечкеле чыбык» сүзен кат-кат
Күп язуның сере бардырмы?
Йөрәгемдә ул яра калдырды...
Ә автомат иңне талдырды.

Һәм шуннан соң, Муса абыйны искә алып, тагын бер шигырь яздым:

## ЧӘНЕЧКЕЛЕ ЧЫБЫК БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

– Әйт син миңа, чәнечкеле чыбык,
Күпме таңнар синдә аттылар?
Бер ел ярым, ягъни унсигез ай,
Томанлыкта ерак калдылар.

Көн, атналар, айлар, еллар буе,
Күпме вакыт мине чәнечтең?
Тормыш – диңгез, ә мин корыган
Инешеңнән ятып су эчтем.

Салкын чакта мине җылыттыңмы?
Сакладыңмы яңгыр яуганда?
– Мусаны да мин бит харап иттем,
Ике тормыш бергә ауганда.

Керфек какмый үткән төннәрнең
Мин бердәнбер шаһиты, солдат.

Уяу тордың йокың килгән чакта,
Кулга тотып хәрби автомат.

– Сине өзеп китим дигән чакта,
Киңәш көтте минем күңелем.
Ник әйтмәдең андый ысул белән
Котылуның мөмкин түгелен?

Туганнардан, дус-иш, яшь кызлардан
Аерганда тормыш сукмагы,
Кабул иттең, чәнечкеле чыбык,
Карурманда җәеп кочагың.

Башка кермәс өчен арака
Нәрсә кирәк? Моңа җавап бир.
Ике икең – биш, акны кара дип,
Камыш төбен тешләп кенә йөр.

– Киңәшем шул: мине гел урап үт,
Башка кермә минем арага.
Тоз сибәрмен җаныңны әрнетеп
Төзәлмәгән тирән яраңа...

Инде кадерле укучыма шунысы да мәгълүм булсын: без гаиләдә биш ир бала үстек, шуларның бишесе дә солдат. Хәзер генә ул, альтернатив хезмәт дип армиядән качып, хастаханәдә тас-чиләк (горшок) ташып йөриләр. Оялмыйча. (Бәлки, мин хаталанамдыр, анысы да эш, анысы да хезмәт. Ләкин мин аның хәрбилеген, хәрби хезмәт икәнен күрмим, аңлап җиткермимдер.)

Радиодан бер күңелсез хәбәр ишеттем: рота командиры – капитан – бер солдатны кыйнап үтергән. Нинди хокукың бар синең кеше үтерергә?! Кеше бит ул! Аллаһы Тәгалә кешегә ана карынында җан кертә, һәм җанын Ул гына алырга тиеш. Ул Аның эше. Ул бирә, Ул ала!.. Гафу ит, укучым. Тагын берничә шигыремне тәкъдим итәм дә, армия турында җитеп торыр.

## БАЙРАК САГЫНДА

Кызыл Байрак, ул сугышчан Байрак,
Бүген бастым аны сакларга.
Минем бурыч – үлем янаса да,
Ышанычны сезнең акларга.

Безнең частьның йөрәге ул Байрак,
Аны белә хезмәт иткәннәр.
Керфек какмый уяу саклаганнар
Өйләренә кайтып киткәннәр.

Җаваплылык миндә бик зур, бик зур,
Аңлаталмыйм шигырь юлында.
Алтмыш патрон, утызы – корылган,
Хәрби автоматым кулымда.

Бәла килсә, һөҗүм итсәләр,
Мин кайгыртам синең турыңда.
Үлгәндә дә сине кочаклап
Җан бирермен шушы урында!

Үзем язам, үзем урамга, урманга, болын-кырларга карыйм. Чү! Бу бит август ае! Егерме бише – Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен җәзалап үтергән көн якынлаша. Мөмкинме соң каһарман-шагыйрьгә багышлап шигырь язмаска!

## БАШ ИЯМ

Муса Җәлил, сине шигырьләрең
Үлгәннән соң кабат терелтте.
Күпме утлар, сулар кичкәннән соң,
Ничә кулдан укылып үтте.

Йөрәгеңдә шыткан җырларың
Ил кырында чәчәк аттылар.
Шагыйрьләрнең барыр юлларында
Маяк алар шуңа хаклылар.

Фашист эте «Моабит дәфтәре»н
Тарткалады, ертып карады,
Вөҗданыңны Туган ил алдында
Җиргә салып таптый алмады.

Илһам бирә, алга омтылдыра,
Шигырьләрең ача күземне.
Муса – диңгез, ә мин – тамчысы дип
Атый алсам иде үземне.

Үлмәс җырың Казан каласында
Һәйкәл итеп ташка язылган.
Үлгән чагың кара август түгел,
Яфрак яра торган яз булган.

Җәлил кебек язу – хыялым ул,
Булсам иде мин шундый, диям.
Муса абый, синең алга килеп,
Горурланып башымны иям!

Озак уйланып утырганнан соң, башыма мондый уй килде: өч мәктәпне – консерватория, армия, филармонияне узган баянчыларыбыз азмы, күпме? Гомумән, бармы? Булса ничәү, кемнәр алар? «Татар баянчылары» китабыма кергән утыз биш баянчы янына тагын утыз бишне яздым да санап-барлап утырам: консерваториядә укыган, армиядә хезмәт итмәгән; кайберләре армиядә булган, филармониядә эшләгән, ләкин консерваториясе юк; кыскасы, консерватория тәмамламаганнарын исемлектән сызып ташладым да алга таба чистарта башладым, һәм нәтиҗәсе болай булды: без биш баянчы – Әзһәр Абдуллин, Фәнис Гыйльметдинов, Харис Нигъмәтҗанов, Кирам Сатиев, Рөстәм Вәлиев – өч мәктәпне дә узганбыз икән. Мин хәтта биш баянчы дип түгел, ә биш кенә баянчы дип әйтер идем. (Сүз уңаеннан шунысын да искә төшереп узыйм: бу биш кешенең бишесе дә «Татар баянчылары» китабына кертелгән иде.) Һәм тагын да әйтеп үтим: беркемгә дә үпкәләрлек булмасын өчен, бу биш музыкантны хронология тәртибендә яздым. (Әгәр дә кемдер онытылып яки ялгышлык белән искә алынмый калган булса, гафу итсен.)

Күпләрнең миңа мондый сорау бирәселәре киләдер: татарча концертлар тыңлый ала идегезме, бар идеме андый мөмкинлек, гомумән, җыр-музыка, баянда уйнау... «Каптерка»да. Яшел төстәге «Этюд» баяны бар иде. Нарядтан соң, юыну бүлмәсенә кереп, татар көйләрен, биюләрен уйнадым. Хәрби частьның бөтен татарыбашкорты минем янга җыела иде. Алай гына да түгел, башка милләт вакилләре дә килде. Менә шул безнең өчен иң зур бәйрәм була торган иде. Кәефе килмәгән чакта, ротаның старшинасы, иптәш прапорщик баянны бирми иде. Чиста, пөхтә, акыллы, тәртипле һәм... куркыныч кеше иде ул. Мин хәтта аның исем-фамилиясен әле хәзер дә әйтергә-язарга чиркanып-куркып торам. Соң, чирканмаслык идемени? Партсобраниене ул алып бара, бөтен офицерлар аны ихтирам итә. Ә тавышы! Казарманың бер башыннан икенче башына яңгырап ишетелеп тора.

Беркөнне иртәнге тезелүдә (плацта) частьның командиры чыгып исәнләште, аннары беренче ротаның командиры (ул капитан чинында иде) «кайда?» дип сорады. «Я его отпустил, товарищ майор», – диде прапорщик. «Хорошо, понял, Фәлән Фәләнович», – диде дә командир сүзен башка темага дәвам итте. Әйбәт кеше иде ул. Мине күргән саен, туктап йә туктатып, яхшы сүз әйтә иде. «Идел буе хәрби округының оркестрына җибәрәм» дигәненә үзем ризалашмадым. «Бирегез миңа автомат һәм чәнечкеле чыбык арасын. Искә алып сөйләрлек булыр», – дидем һәм үкенмим. Менә шунда туры килде инде миңа илле дүрт шигырь язарга. Барысын бергә туплап, «Химбат дәфтәре» дип исем куштым. Икенче күрүдә, отпускага җибәрәм, диде. Мөнәсәбәте яхшы иде миңа. Ләкин ул утыз дүрт яшендә автомобиль авариясенә эләгеп һәлак булды. Илле дүрт яшьтә үлгән илле дүрт шәхес турында язган идем теге китабымда. Ә менә бу утыз дүрт саны мине тагын уйландыра башлады: космонавт Юрий Гагарин, язучы Николай Островский, очучы Валерий Чкалов... һәм безнең командир утыз дүрт яшьтә һәлак булдылар. Ярар, бу аерым тема. Ул үлде, отпуск булмады.

...Постта торам. Өстә шинель, аякта кирза итек, иңдә автомат. Кыш. Буран. Салкын. Мәскәү шәһәренең «Маяк» радиосы концерт бирә. «В исполнении Ильгама Шакирова звучит...» Һәм ул «Идел буе каеннары»н «Идел» ансамбленә кушылып башкарды. Ә мин Идел ярларында, ак баян аскан иңемә автомат асып, җыр тыңлыйм:

Әгәр сездән аерып еракларга
Алып китә калса юлларым...

Алып та китте, исән-сау алып та кайтты. Кайта алмаучылар да булды.

Язмыш дигән төшенчә бар. Урысчасы – судьба. Икесе дә бер мәгънәне аңлата торган кушма сүзләр. Язмыш – язма эш. Судьба – Суд Божий. Синең язмышыңа ничек язылган, ул шулай була. Ризыгы кайда – кеше шунда. Язмыш. Судьба. Армиядә блокнотта (бер миндә генә түгел) мондый сүзләр бар иде: «То, что должно случиться с тобой написано в Книге Жизни, и ветер вечности перелистывает ее страницы».

...Көз көне безне Зур Иргиз елгасы ярына бәрәңге җыярга алып бардылар. Палаткаларда яшибез. Бер офицерның «Океан» исемле радиоалгычы бар иде. Шунда кич «Әгәр син булмасаң янымда» җырын тыңладык. Ә икенче көнне (көндез), бәрәңге басуын яңгыратып, Миңгол Галиев «Чык юлларга» җырын (Ф.Яруллин сүзләре,

Ф.Хатыйпов көе) башкарды. Моң, сагыш, юксыну, туган якны сагыну...

Постта торам ил чигендә,
Бер коры җир калмады.
Сагындырып искә төшә
Татарстан моңнары...

МИН – ЧАСОВОЙ

Күңелемдә Тукай «Шүрәле»се,
Искә төшә мәктәп еллары.
Иңгә «авто» аскан солдатны
Постка илтә урман юллары.

Юл тарая, сукмак башлана.
Ә көзге төн шундый караңгы!
Кайтырсыңмы кире – әйтү авыр,
Беләсең тик анда барганны.

Килеп җиттек, кабул иттем, дидем,
Ялгыз калам, китә егетләр...
Арабызны һаман ерагайта
Шыгырдаган кирза итекләр.

Ялгыз калдым... Һич тынгы юк.
Кем генә юк төнге урманда...
Коралланган «сырлы киемлеләр»,
Төрле киек кошлар бар анда.

Әнә шәүлә, яфрак кыштырдый.
«Тукта, кем?» – дим. Җавап бирми ул.
Тын кысыла, аяк-кул калтырый,
Шәүлә алга таба тота юл.

Минут саен шундый вакыйга,
Караңгыда ату файдасыз.
Төннәр буе ике, дүрт аяклы
Хайван күреп таңнар атасыз.

Ике төннең берсе – каравылда,
Каршы алам таңнар атканын.
Часовойлар дошманны үткәрми,
Уяу саклый Ленин Ватанын!

Бу шигырьдә Ленин дигән сүзне алып ташларга дип әйтүчеләр табылыр. Тукта. Алмый тор. Бу бит тарих. Ә тарихны бозарга, үз файдаңа үзгәртергә тырышырга кирәкми. Бу зур гөнаһ һәм олы хата. Ленин яшәгән, революция ясаган, сугышлар, җиңүләр, җиңелүләр булган. Тормыш бит ул. Гадәттә, без кемнеңдер, нәрсәнеңдер тискәре ягын күрергә, шуны алга сөрергә күнеккәнбез. Кирәкми. Ул бит үз эшен эшләде: «Дайте нам организацию революционеров, и мы перевернем Россию», – диде һәм сүзендә торды. Урыслар әйтә бит: «Победителей не судят», – дип. Һәм дөрес тә. Ул әйләндереп салды. Кайсы якка, ничек – анысы икенче мәсьәлә. Ни өчен соң Совет властена кадәр Казанда консерватория булмаган? Мәскәүдә, Петербургта булган бит! Әнә шул консерватория, анда белем алган шәкертләр Казанны, Татарстанны күпме зурладылар. Дөньякүләм аренага чыгардылар. Бу турыда күп һәм нәтиҗәле язарга булыр иде. Хәер, язылганнары да шактый. Укырга гына кирәк. Ә укучылар сирәк, язучылар аннан да әзрәк. Хәзерге заманда күпләр байлык артыннан куалар, бер язучы әйтмешли, күбрәк корсак турында уйлыйлар. Киләчәк, милләт язмышы аларны бөтенләй диярлек кызыксындырмый. Ләкин бөтен җитәкчеләр дә андыйлардан түгел бит. Халкыбыз өчен дүрт күпер салдырды Президентыбыз М.Ш.Шәймиев. Бу җитәкче – сирәк һәм зирәк акыл иясе, чын-чынлап халкы, кешеләр турында кайгыртучы шәхес. (Сүз уңаеннан шунысын да әйтим: минем иҗатыма һәм минем иҗатташларыма югары бәя биреп, ике тапкыр Указга кул куйды. Татарстанның атказанган һәм халык артисты исемнәренә.) Идел суы һәм Казансу елгасы инде күптәннән ага. Ләкин Идел, Чулман, Казан елгалары аша күпер салу алдагы җитәкчеләрнең башына да килмәгән. Әллә белеп тә күпер салмаганнар. Күпме шоферлар, күпме пассажирлар рәхмәтле безнең сөекле Президентыбызга! Үз чиратында бу да тарих. Ә тарихны бозарга яки күрмәмешкә салышырга һич кенә дә ярамый. Беребез дә бу фани дөньяга мәңгелеккә килмәгән. Шагыйрь әйтмешли, «янып калсын гомерең маяк булып үзеңнән соң килгән буынга». Әгәр дә мин шигырь язу остасы булсам, һичшиксез:

Рәхмәт Сезгә, Минтимер,
Салдырдыгыз дүрт (!) күпер, –

дип язар идем. Төп фикерем: тарихны бозмагыз, тарихны ясау, тарихка керү һәркемгә дә бирелмәгәндер ул.

Инде тагын Совет Армиясенә әйләнеп кайтыйк та укучыбызга «Химбат дәфтәре»ннән берничә шигырь тәкъдим итик:

## КҮҢЕЛЛЕМЕ КОШ САЙРАГАНДА?

Тынлык... әкияттәге сихри тынлык.
Әйтерсең лә бу төш, өн түгел.
Аңлатмаслык тәэсир, йогынтыга,
Хискә чума, уйлана күңел.

Бу тынлыкны кош сайравы боза,
Боза түгел, бизи ямь өстәп.
Шул урманда моңнар арасында
Ләззәт алам саф һава иснәп.

Бер кош түгел, мең кош сайрый монда,
Моңнар арта, урман җанлана.
Монда бик күп ерткычлар, еланнар,
Кош сайравын тыңлап алданма!

Дүрт аяклы җәнлектән курыкмыйм,
Чөнки кулда хәрби автомат.
Бигрәк явыз ике аяклысы,
Патроның беткәнче ат та ат.

Яхшы һәм яман турында уйлыйм,
Ә хисләрем китә еракка...
Ялгызлык ул бер дә бәхет түгел
Егерме бишкә җиткән ир-атка.

Кошлар сайрый... Нинди күңелле!
...Ләкин нидер тырный күңелне.
Ике яктан мине чорнаган
Чәнечкеле чыбык түгелме?

## ЧАСОВОЙ

Бар нәрсәдән мәхрүм ителгән,
Иңнәренә аскан автомат.
Часовой дип атала ул кеше –
Пост кабул иткән уяу солдат.

Сөйләшергә ярамый,
Утырырга ярамый.
Ул бит арый, җаны барга,
Ярамыйга карамый!

Төн дә дими, көн дә дими,
Ару-талуны белми.
Саклаган әйберсен түгел,
Хәтта шырпы да бирми.

Ятып тору ярамый,
Эфир тыңлау ярамый,
Айлар, еллар шулай йөрсәң,
Ярамыйга карамый.

Табигатьнең кырыс чагы бик күп,
Салкын җиле, яңгыр, бураны.
Бер шинель ул – аңа һич кенә дә
Йөреп булмый төренеп, уранып.

Ике сәгать син сакларга тиеш,
Үлем яный – китә алмыйсың.
Шунда гына, часовой хезмәтен
Үзең тойгач кына аңлыйсың.

Уңга басу ярамый,
Сулга бассаң ярамый.
Кайчагында «аяк таеп китә»,
Ярамыйга карамый.

Өшисеңме, арыгансыңмы,
Ачмы, әллә йокың киләме?
Бу сорауга беркем җавап бирми,
Кеше хәлен кеше беләме?!

Язу-сызу ярамый,
Җырлар җырлау ярамый.
Постта чакта күңелне моң баса,
Ярамыйга карамый!

Сүзсез генә алга атлыйсың
Чәнечкеле чыбык эчендә.
Бар нәрсәдән мәхрүм ителгән дим
Часовойны шуның өчен дә.

Патронникка кирәкмәгән чакта
Патрон кую һич тә ярамый.
Ә тормышта төрле хәлләр була,
Ярамыйга карамый.

«Ярамый»лар Устав тарафыннан
Уяу саклау өчен куела.
Бу Законны тормыш үзе язган,
Закон бозу катгый тыела!

Әгәр бозсаң тормыш законнарын,
Цинкланган табут... Кирәкми!..
Шушы бер сүз икенче ел инде
Әчеттерә, тырный йөрәкне...

## ТОМАН

Вольскида Лондон томаннары.
Бар нәрсә ак: ак та, кара да.
Уңда, сулда чәнечкеле чыбык,
Часовойлар ике арада.

Күзгә төртсәң дә күренми дисәм,
Ялгыш булыр, булыр арттыру.
Куе томан... Чәнечкеле чыбык...
Ай-һай авыр таңны аттыру!!!

Өстәвенә җил кистереп исә,
Юка шинель озын итәкле.
Әйтерсең лә газраилләр сине
Салкын кулдан тотып җитәкли.

Берөзлексез яңгыр явып тора,
Итек юеш, куллар туңалар.
Ә шулай да постны ташлап китми,
Часовойлар уяу торалар.

Ил чикләрен, хәрби постларны
Керфек какмый уяу сакладың.
Бозмый биргән антны, Туган илнең
Ышанычын, солдат, акладың.

Вольскида соңгы кыш та үтәр,
«Ак урманнар» тагын «каралыр».
Сиксән бернең дембель язы килгәч,
Бу томаннар мәңге таралыр!

## ГАФУ ИТ...*

Көткәнсеңдер минем килүемне
Кышкы төннең салкын таңында.
Мин килмәдем, чөнки басып тордым
Цинкланган табут янында.

Ул табутта ята абыемның –
Туганымның үле гәүдәсе.
Әйтә кебек: «Сак бул автоматтан,
Минем кебек булма», – янәсе.

Гафу ит син, иркәм, очрашуны,
Күрешүне теләп өзмәдем.
Һаман элеккечә яратуым,
Синдә генә минем күзләрем.

Төшенкелек чолгамасын сине,
Очрашырбыз Сарман ягында.
Баш иярбез яшьли һәлак булган
Абыемның кабере янында...

## НЕЙТРАЛЬ ПОЛОСА

Нейтраль полоса дип атадым
Чәнечкеле чыбык арасын.
Кем ышанмый минем бу сүзгә,
Үзе шунда кереп карасын.

Чөнки монда тик часовой йөри,
Башкалар кусаң да кермиләр.
Үлем яный торган тар сукмактан
Тик солдатлар гына йөриләр.

Сәгать теле кебек әйләнгәндә
Уң якта пост: керсәң, аталар.
Сул якта йөр: бер сүзем юк,
Тик, якынайсаң, туктаталар.

---

* Бу шигырь, Сарман районы егете Илдус Вәлиуллинның соравы буенча, абыйсы һәлак булганнан соң язылды.

Часовойның гына хакы бар
Нейтраль полосада йөрергә,
Хәрби постларны саклаган чакта
Дошманнарга отпор бирергә.

Нейтраль полосада бик күп йөрдем,
Өч пар кирза итек туздырдым.
Әллә бушка, әллә кирәккә
Ел ярымны шунда уздырдым.

## БУРАН

Буран. Күз ачмаслык көчле буран.
Давыл чыкты, дулап җил уйный.
Урман шаулый, чәнечкеле чыбык
Әйтерсең лә бүредәй улый.

Йөзгә кунган юеш кар бөртеге
Чиркандырып ага муеннан.
Кергән җилләр шинель итәгеннән
Чыгып китәр төсле куеннан.

Буран туктар, җилләр басылыр,
Ә йөрәктә калыр эзләре.
Алмаш киләчәк сукмакка карап
Талып бетте инде күзләрем.

Гомерем үтә юлда зарыгып.
Гомер буе сузылган куллар...
Көтми торган бәхет аланына
Алып барсын иде шул юллар...

## ЙӨРӘК САЛКЫНЫ

Казармада тугыз градус җылы,
Ә төннәрен була биш-алты.
Шушы салкын аяк-кулларымны,
Йөрәгемне үзенә алды.

Кайчан бетәр әрнү.
Кем җылытыр йөрәк салкынын?
Икеләнми моңа җавап бирәм:
Сиксән бернең дембель ялкыны!

## ХАТЛАР, ХАТЛАР

Ешрак яз, иркәм, хатларыңны,
Алмасаң да миннән аларны
Сагынуларны, януларны баса,
Якынайта ерак араны.

Хатлар монда бердәнбер юаныч,
Хат булмаса, авыр солдатка.
Бик күп язма, күп сүз кирәк түгел,
«Исән-сау» дип кенә яз хатта.

Әгәр мине онытмаган булсаң,
Элеккечә өзелеп яратсаң,
Бер җөмләдән аңлармын мин, иркәм,
«Кайтуыңны көтәм» дип язсаң...

## ТУГАН ЙОРТТАН КИТӘ МАЛАЙЛАР

*(Русчадан тәрҗемә)*

Туган йорттан ерак китәләр
Гимнастерка кигән малайлар.
Югалткан күк сагынып, аларны
Ике-өч ел көтә аналар.

Бәйрәм кебек сирәк хат алгач,
Күршесенә ана ашыга.
Яшьле күзен текәп, «ябыккан» дип,
Моңсу карый фотокарточкага.

Хатлар яза улы, зарланмый,
Хезмәт авыр, читен дип язмый.
«Тирне сөртми өйрәнмисең», – дип,
Старшина әйтеп алгалый.

Бер ел атлый кирза итек киеп,
Икеләтә чыныгу арта.
Ирешелмәгән үрләр яшь солдатны
Һаман алга, биеккә тарта.

Ә анасы озын төннәр буе
Йоклый алмый, керфеген какмый.
«Сугыш чыкса, нишләр балам, – ди ул, –
Китте хәтта ярын табалмый».

Кайгырма син, ана, борчылма,
Улың чыга кайтыр юлына.
Оныкларны – улын улыңның
Алырсың син назлап кулыңа.

Сугыш булмас, сугыш кирәкми!
Тыныч йоклагыз сез, аналар.
Чөнки сакта уяу торалар
Туган йорттан киткән малайлар.

## КЕМ ГАЕПЛЕ?

*(Мәсәл)*

Урмандагы барлык җәнлекләр дә
Укыганнар, чиннар алганнар.
Ә куяннар, белмим, ни сәбәпле
Укымыйча надан калганнар.

Яхшы гына тормыш иткән чакта,
Гадәттән тыш хәл килеп чыга.
Арадан бер үтә ялагае
Хуҗасы Арысланга чаба.

Һәм әләкче вакыйганы сөйли,
Гаеплене төртеп күрсәтми.
Чөнки аңа үз тиресе кыйммәт:
«Әйтер идем, белсәм, күрсәм», – ди.

Әй шуннан соң Арыслан котыра,
Ачулана, бүртә, кабара...
Җәнлекләрне җыеп әмер бирә:
«Гаеплене тизрәк табарга!»

Күз карашы Аюга текәлә:
«Мин түгел, – ди, – сора Бүредән».
Төлке дә аклана: «Гаепсез мин,
Сезгә әйтәм йөрәк түреннән».

...Һәм, кыскасы: гаепле юк һаман,
Куяннардан сорау алалар.
Ышанмыйлар алар әйткән сүзгә,
Чөнки надан, чинсыз бит алар!

Монда мораль болай әйтелде:
Көчсез, чинсыз һәрчак гаепле.

## ЯЗЫЛМАГАН ШИГЫРЬ

Күп уйладым шигырь язарга,
Дөреслекне ачып салырга –
Туры карап барлык кыенлыкка
Каләм белән чәнчеп алырга.

Дөреслеккә барган кешеләрнең
Төрмәләрдә башы чиреде.
Бик күпләре Себер салкынында
Кояш баткан кебек сүрелде.

Нәрсә соң ул язылмаган шигырь?
Йөрәгемә җыйган әрнүләр,
Рәнҗетүләр, яла, пычрак ягу,
Бер дә юкка каты бәрелүләр.

Бар теләгем – бүгенге һәм үткән,
Алдагыны – хезмәт көннәрен.
Дөрес итеп чагылдырып язу
Керфек какмый үткән төннәрнең.

Дөреслекне әгәр әйтим дисәң,
Атың булсын, диләр, иярле.
Булмаган ат булмаган иярне,
Йөгәннәрне ул соң киярме?

Ат турында сүз бармый шул монда,
Калганын үзегез аңлагыз.
Күңелемдә әрнү, йөрәгемдә сагыш,
Аңлагыз сез, аңлый алсагыз.

Башка язмыйм, һәм кирәк тә түгел,
Күпкә түздең, йөрәк, түз тагын.
Ышанам мин, якты аланда
Каршыларбыз без бәхет таңын.

Бу шигырьне үзем белән йөртәм,
Алып китәм, китсәм еракка.
Үпкәгезне миңа түгел, аңа
Белгертегез – ярсу йөрәккә...

## УМЫРЗАЯ БУКЕТЫ

Еллар үтә... Ләкин һич шиңдермим
Букетымны умырзаядан.
Сокланалар, кыш уртасы, диләр
Һәм сорыйлар: «Алдың син каян?»

Сиңа аны күптән җыйган идем,
Үткән айлар, еллар шаһитлар.
Сүнмәс яшьлек, чиксез яратуның
Һәм сөюнең билгесе алар.

Букет шиңми, түзә салкынга да,
Чөнки бирдем йөрәк җылымны.
Зарыгып көтә, тели умырзая
Кавышуны, бергә булуны.

Яшьлек таңы, аның аткан чагы
Чагылалар умырзаяда.
Кемгә бирим, кайда соң син, иркәм,
Гомер үтә бушка, заяга.

Һаман көтәм дулкын шаулаганда
Букет тотып Идел ярында.
Һәм бирермен томан арасыннан
Килеп чыккан сөйгән ярыма!

## БЕРСЕН-БЕРСЕ, ЯКИ КТО КОГО

Адым саен тавыш, скандаллар,
Минут саен ызгыш-талашлар.
Берсен-берсе нәкъ ашардай булып
Текәләләр серле карашлар.

Өстәгеләр астагыны баса,
Ә алары – түбән торганын.
Һәрберсе дә җылы булсын өчен
Үзенә тарта тормыш юрганын.

Берсен-берсе бертуктаусыз «ашый»,
Тавыш-гауга чолгый химбатны.
Солдатларның көн-төн эшләүләре
Хәтерләтә җигелгән атны.

Берсен-берсе төпкә батыралар,
Текә ярдан төртеп төшереп.
Урысларның «кто кого» дигән
Әйтемнәрен искә төшереп.

Кем соң алар? Бүре тиресенә
Төренеп йөрүче сарыклар,
Яки әтәч кикериге тагып
Басалмыйча йөргән тавыклар.

Минут саен нерв какшаталар,
Бер дә юкка тавыш чыгарып.
Акыл түбән, тиреләре юеш,
Ә шулай да борын югары.

Бүре булсаң, ки син үз тиреңне,
Сарык булсаң, тимә аңарга.
Сарыкныкы кадәр акылың булса,
Син бит тиеш моны аңларга!

## ТӨШ

Төш күрдем мин. Кошлар сайраганда
Йөрибез Ак Идел ярында.
Сөю билгесенә чәчкәләрдән
Букет бирәм сөйгән ярыма.

Җәйге кояш, алтын нурлар чәчеп,
Иртәнге томанны тарата.
Ятып аунап чык кипкән үләндә
Ял итәргә бигрәк ярата

Иркәлиләр таң җилләре безне.
Бал кортлары куна. Чакмыйлар.
Бөдрә таллар – сөю шаһитлары –
Әйтерсең лә бергә атлыйлар.

Идел суы дәшеп ага кебек:
«Яшь чакларның кадерен белегез.
Минем кебек ул да кире кайтмый,
Иркен сулап бергә йөрегез».

Былбылларның моңлы тавышлары
Дәртләндерә безнең күңелне.
Нидер теләп типкән чакта йөрәк
Бергә булу бәхет түгелме?

Һәм уяндым салкын казармада,
«Подъем!» сүзе яргач колакны.
Татлы төшне күреп бетермәдем,
Елый яздым үксеп шул чакны.

Шинель өстә, итек аякларда,
Х/б кидем, мажка* кулымда.
Идән таптап аяк чалучылар
Чүпләр генә минем юлымда.

## ТЕГЕ ДӨНЬЯДА

Үлгән чакта җан алучы әйтте:
«Синең урының, – диде, – оҗмахта.
Яннарыңда фәрештәләр йөрер,
Хур кызлары булыр кочакта».

Җан алучы ялгыш әйткән икән,
Барып эләктем мин тәмугка.
Кайнар таба хәзер баскан җирем,
Яндыралар көн саен утта.

Күз күрмәгән, колак ишетмәгән
Эшләр эшли адәм баласы.
Шул тәмугка килеп эләккәч,
Кая качып, кая барасың.

* М а ж к а – рельска йомры щетка беркетеп ясалган идән себерү коралы.

Көнне төнгә, төнне көнгә ялгап,
Ару-талу белми эшлисең.
Ял бирү юк, гел әрләп торалар,
Язмыштан узмыш юк, нишлисең.

Адым саен, секунд, минут саен,
Булмаса да, гаеп табалар.
Яла өчен йөрәк әрни-сыкрый,
Күренмичә яшьләр тамалар.

## ПУТАЧКА

Путачка ул урыс сүзе була,
Татарчасы аның – болгату.
Туры юлдан кыек юлга кертү –
Җеп чуалтып очын югалту.

Һәрбер кеше монда эштән кача,
Хуҗалар киткәнне көтәләр.
Эшләренә бармак аша карап,
Үз юллары белән китәләр.

Кемнәр кемне күбрәк алдый дигән
Көрәш бара, ярыш җәелә...
Һәм уйлыйлар: путачка ясарга
Җитсен иде тизрәк җәй генә.

Иңнәренә сугып күрсәтә дә:
«Офицер юкмы?» – дип сорый ул.
Һәм шунда ук этлек уйлый башлап,
Ишек тарафына тота юл.

Төп уйлары – берсен-берсе алдау,
Бары тик ул гына ял итсен.
Баш болгатып ашап эчкәннән соң,
Казармага йокларга китсен.

## АВТОМАТ

Декабрьнең беренче көнендә
Тантаналы сафка тезелдек.
Кулга тоткач хәрби автомат:
«Илгә хезмәт итәрбез», – дидек.

Җаваплылык миндә тагын артты,
Хәзер инде мин ил сакчысы.
Буш вакытта кулга Устав алам,
Устав – хәрби хезмәт ачкычы.

Алда әле авыр имтиханнар,
Чын тормыш мәктәбен үтәсе.
Киртәләрне йөгереп сикерәсе,
Туган илгә хезмәт итәсе.

Ак баянны аскан уң җилкәгә
Бүген инде автомат астым.
Шушы көннән мин дә солдат булдым,
Туган илне сакларга бастым.

Иң беренче язган «Санчасть гөле» исемле шигыремнең дүртенче куплеты:

...Эх син, гөлем, минем сагынуымны,
Януымны аңлый алмыйсың!
Күп калмады кайтыр көнеңә, дип
Алдыйсың бит мине, алдыйсың!..

## «СӘРВИНАЗ»*

*(Уйлану)*

Сиксән бернең салкын кышы үткәч,
Гөрләп килер ямьле, матур яз.
Синең белән Казан каласында
Очрашырбыз тагын, «Сәрвиназ».

Яшьлегемнең сызылып аткан таңы
Синең исемең белән бәйләнде.
Бергә үткән биш ел минем өчен
Хатирәгә, төшкә әйләнде.

Сәхнәләрдә(н) җыр агылган чакта,
Күпме халык безгә карады!..
Чыңлап чыккан моңлы тавыш белән
Якынайттык ике араны.

* «С ә р в и н а з» – ансамбль исеме.

Әлмәт, Чаллы, Казан каласында
Яңгырады синең тавышың.
Җырларыңны тагын бер ишетсәм,
Бетәр иде йөрәк сагышы.

Мин еракта... Кулда баян түгел,
Ә автомат хәзер иңемдә...
Сезне саклыйм, керфегемне какмый
Хезмәт итәм туган илемә.

Күңелемдә һәрчак сезне йөртәм,
«Сәрвиназ» кызлары – сылулар.
Караңгылык мине чолгап алса,
Юлларымда маяк булырлар.

«Сәрвиназ»ны хәзер сүнгән диләр.
Юк, «Сәрвиназ», син һич сүнмисең.
Совет сәнгатендә югарыга –
Биеклеккә һаман үрлисең!

* * *

...Шигырьләрем – «Химбат дәфтәре» ул,
«Нурландыра» һәрбер явызны.
Чагылдыра бүгенне, үткәнне,
Киләчәкне – тормыш язымны.

## МИН ҮЛДЕМ

Мин үлдем. Салкын тирән кабергә
Ак кәфенгә төреп күмделәр.
Языласы җырлар һәм шигырьләр
Үзем белән бергә «үлделәр».

Үкенечле үлем белән үлдем,
Күпме җырым яңгырамады.
Күпме шигырь язылмыйча калды,
Әчеттерә үлгәч яраны.

Эшкә кереш бүгенге көннән үк,
Тузаннар кундыр син җиңеңә.
Иҗатны, хезмәтне, гомереңне
Багышла халкыңа, илеңә.

Калган эшкә кар ява, диләр бит,
Кар-бураннар аны күммәсен.
Киләчәкне бүгенге хәл итә,
Яшь гомерең бушка үтмәсен.

Каләмем юк, тагын язар идем,
Моңнар, уйлар тулган башыма.
Мин язмаган җырны, шигырьләрне
Сез языгыз кабер ташына...

## ЯҢА ДЕМБЕЛЬ ЕЛЫ

*(1979 – 1981)*

Хуш киләсең, Яңа ел,
Хуш киләсең, Дембель елы!
Шушы сүзне авыз тутырып әйтү
Нинди рәхәт, нинди җылы!

Совет сәнгатенә кайта торган
Хуш киләсең, Дембель елы!
Алдагыны күздә тотып,
Шатлык белән иркен сулыйм!

Еллар тыныч, имин булсын,
Такыр булсын кайтыр юлым.
Аналары кочсын улын...
Хуш киләсең, Дембель елы!!!

## САК БУЛЫГЫЗ ИРКӘ КЕШЕДӘН!

Өф-өф итеп үстерделәр аны,
Авырлык, кыенлык күрмәде.
Йөрде ул ташсыз тигез юлдан,
Яуламады биек үрләрне.

Көннәр буе сөрән сугып йөрде,
Җилләр куды, урам таптады.
Аркылыны торкылы салмыйча,
Эт сугарып алга атлады.

Иркә үсте канатлар астында,
Җылы иде ана куены.
Уйламады киләчәк турында,
Дәвам итте көлке-уенны.

Читкә китте... бетте назланулар,
Иркәләүләр, сыйпау юк инде.
Алда киртә, тар тормыш сукмагы,
Зур сынаулар чолгый шул инде.

Тыныч чакта – мәкерле, ялагай;
Сугыш чыкса – Илен сатачак.
Үз тиресен саклап, дусларына,
Командирларына атачак.

Сак булыгыз иркә кешеләрдән,
Тормыш корма иркәләр белән.
Үзең кебеккә чык син тормышка,
Үзеңә тиң булсынга өйлән!

## АВТОМАТЫМ, ЯКИ БЕЗ ИКӘҮ ИДЕК

*(Поэма)*

Кышкы салкын. Толып бирмәгәндә,
Шинель киеп постта торганда,
Син, автомат, тик бер шаһит идең,
«Җан биргәндә» карлы буранда.

Сакламады чәнечкеле чыбык,
Коеп эре яңгыр яуганда.
Карурманда икәү генә идек,
Көчле җилдә агач ауганда.

Ә көз көне кырау төшкән чакта,
Искән чакта кисеп таң җиле,
Шомлы итеп бүре улаганда,
Ныграк кысып тоттым мин сине.

Исеңдәме, «Дүрт»тә торган чакта,
Дошман безгә таба укталды.

(Казарма якынга, өскә аттым),
Караңгыда кинәт туктады.

Нидер мыгырданып артка чикте,
Җиңалмады, китте, югалды.
Караңгыда карурманга кереп,
Еракларга бездән юл алды.

Ул атмады, әгәр аткан булса,
Пуля сиңа очса... юк чара...
Алтмыш патрон телгә килде шунда:
«Без һәрвакыт әзер очарга».

«Җиденче»дә бүре улаганда,
Бер мизгелгә без катып калдык.
Ә аннары зур имән янында
Һөҗүм итәргә урын алдык.

Син елыштың миңа, мин – сиңа,
Ә бүреләр якын килмәде.
Төрле яктан безгә каршы исте
Бу тормышның ачы җилләре.

«Алтынчы»да кабан дуңгызлары
Карбыз ашап кайткан чагында,
Чәнечкеле чыбык аралады,
Алар һөҗүм иткән чагында.

Август төне, һай, караңгы иде!
Ике поши чыкты урманнан.
«Тукта!» диеп биргән командамнан
...Китә алмый тордым урыннан.

Авыр иде төнге сәгать өчтә
Тапчаннардан торып киткәндә.
«Айный идек» бары постка гына
Якынаеп барып җиткәндә.

Йокы баса, күз йомыла иде,
Авыр иде сакта торганда.
Ачы бураннарда карурманда
Төнлә бергә «сәгать борганда».

«Өченче»дә төнлә еш аттылар
Әллә аучы, әллә башкалар.
Әллә җәнлек, әллә часовойны,
Әллә башканы аулаучылар.

Иван дуска төзәп аттылар,
Ләкин аңа пуля тимәде.
Ул гильзаны тапты, дошман качты,
Беребез дә башны имәде.

Төрле яклап үлем янаганда,
Куркыныч ялкыны ялмады.
Ә шулай да (Алла саклагандыр)
Карурманда ятып калмадым.

Искә төшсә дә ул постлар хәзер,
Йөрәк ярым туктый тибүдән.
Иң хәере – бу химбаттан тизрәк
Ерактан да ары китүдән.

Бүген Беренче май. Күп калмады инде.
Туган якларга кайта солдат!
Чәнечкеле чыбык монда калсын!
Хушлашыйк без, дустым, автомат...

Ниһаять, 1981 елның 18 мае килеп җитте. Хәрби хезмәт тәмам...

Мине көтә Идел дулкыннары,
Көләч кызлар, татар моңнары.
Сау булыгыз, йокысыз төннәрем!
Сау булыгыз, химбат таңнары!..

# ФИЛАРМОНИЯ

Әйтеп-әйтеп тә аңламаган кайберәүләргә кабат аңлатып узам: филармониядә эшлиләр, консерваториядә укыйлар. «Син филармония бетердең бит әле», – диләр кайбер кешеләр. Монда берьюлы ике хата. Беренчесе: мин филармонияне бетермәдем, ул булды, бар, булачак. Икенчесе: филармония уку йорты түгел. Уку йорты булса да, бетердем дип түгел, тәмамладым дип әйтү хәерле. Бетерү ул башка мәгънәгә ия.

Ә бер иптәш, әллә чынлап, әллә шаярып, миңа болай дигән иде: «Консерваториядә юк тавышны бар итәргә тырышалар, ә филармониядә, киресенчә, бар тавышны бетерергә тырышалар».

...Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә стажер (яшь белгеч) буларак консерваториянең бишенче курсында укыганда (1978) эшли башладым. Башладым дип әйтү бик үк дөрес булмас: мине – булачак артистны (музыкантны) сынап карадылар. Ә инде алдагы елда югары уку йортын тәмамлагач (бетергәч түгел, консерватория әле дә бар), эшкә мине филармониягә билгеләделәр. Ләкин шул елның көзендә мине армиягә алдылар. 1981 елда консерватория тәмамлаган, армия хезмәтен тутырган, гади тел белән әйткәндә, ике Мәктәп узган («Мәктәп» сүзен баш хәреф белән язуым очраклы түгел) музыкант-солдат җиң сызганып өченче Мәктәптә – филармониядә эшли башладым. Автоматны куйдым да иңнәремә ак баянны астым. Армиядәге «через день на ремень» дигән сүзләр «каждый день на ремень»гә алышынды: көн саен концерт (концертлар).

Ниһаять, без дә җиңүгә ирештек: алда – гражданка! Кем әйтмешли, кайтсам, монда да оҗмах көтеп тормый икән. Һәрвакыттагыча: йокларга урын, ашарга акча юк. Филармониянең өченче классында куныш йөрим. Менә монысына инде мин үзем гаепле (өлешчә). Югыйсә райкомга барып бер генә җөмлә әйтәсе бит инде: мин – Ватанны саклап кайткан югары белемле коммунист. Бетте-китте. Барысы да, бәлки, хәл ителер иде. Юк бит. Артык тыйнак. Шуңа күрә дә бит урыслар, шаярып: «Скромность угрожает человеку», – диләр. Не украшает, а угрожает. Бу «батырлык»ны Рамил Курамшин башлаган иде, аннары мин, соңыннан Рөстәм Вәлиев дәвам итте. Рояль әйбәт, әлбәттә, ләкин тая. Бик шома. Мендәр урынына баш астына салынган ботинкалар шуып төшә. Шнурын муенга чорнасаң, буылып үлүең ихтимал. Тфү, тфү, Аллам сакласын. Әле бит аның хурлыгы ни тора! Кайбер мал хөке-

мендәге бәндәләр, өч мәктәпнең берсен дә үтмәгәннәр, юри төрттереп, мыскыл итеп торган булалар. Ачның хәлен тук белми. «Джентльмены удачи» киносындагы Василий Алибабаевичның канатлы сүзләрен искә төшереп, парлап куелган урындыкларга ятып: «Эх, хәзер армиядә макарон бирәләр инде», – дип уйланам.

Иртәгә, иртәге көн тугач ук сөйгән ярым янына барам. Ул авылдан килә. Әлегә «Химбат дәфтәре»мне ачып, аңа атап язган шигыремне укып ятам.

КӨТ СОЛДАТНЫ

Ун ай әле хезмәт итәсе бар,
Сиңа язам сагыну хатларын.
Тап төшерми керсез мәхәббәткә,
Уртак юлдан ялгыз атлармын.

Көтәрме ул синең кайтуыңны,
Каршылармы килер язларны?
Элеккечә сөю хисе белән
Сине, солдат, ул соң назлармы?

Өченче яр яки башкаларда
Булмасмы соң аның күңеле?
Әйтмәсме ул яшьле күзләр белән
Кавышуның мөмкин түгелен?

Солдат кайткач, ягымлы елмаеп,
«Исәнме» дип сузар кулларын.
Дәшми көтәр... Ике ел эчендә
Сөйлә аңа ниләр булганын.

Көт солдатны айлар, еллар буе.
Озак көттең... Бераз көт тагын.
Ышанам мин: якты аланлыкта
Каршыларбыз без бәхет таңын!

Ләкин... ул көтмәгән. Һәм мин, тиз генә кулыма каләм алып, «Хыянәт» исемле шигырь язып ташладым. Күңелем сизгән иде...

Вәгъдә бирде ике яшь йөрәк:
«Мәңге бергә булыр таң ату.
Чәчәкле яз шаулар диңгездәй,
Дәвам итәр сөю, ярату».

Хатлар шаһит: ике ел буе
Мәхәббәткә тузан кунмады.

Тап төшмәде уртак сөюгә,
Читкә тайпылулар булмады.

Кайтты солдат туган ягына,
Өмет сүнде... Гөрләп туй бара...
Сөйгән ярын ятлар алганга,
Гомер буе әрнер бу яра.

## Еллар һәм юллар...

Мин дә бит сезнең арада
Канат үстергән бала.
Кайларга гына китсәм дә,
Йөрәгемездә кала.

Әлеге истәлек-язманы Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә багышланган шундый юллар белән башлыйсым килә. Чыннан да шулай бит. Бөтен яшьлегем шушы сәнгать сараенда үткән. Монда эшләгәндә партия сафларына кабул ителдем. Монда мин гармунчыларның Ф.Туишев исемендәге бүләге иясе булдым, «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем алдым, «Татар баянчылары» исемле китап яздым. Үзәк (Мәскәү) телевидениесендә сольный концертым булды. Татарстан телевидениесе ике концертымны зәңгәр экраннардан күрсәтте.

Еллар һәм юллар... Алар аккан су кебек әкрен генә уза бирде. Без һәрчак юлда булдык. Юл газабы – гүр газабы, диләр. Ничек кенә булмасын, яшьлек үзенекен итте, сәнгатькә чын күңелдән бирелгәнгә күрә, ул газаплар бер дә сизелми иде. Нинди генә илҗирләрне гизмәдек ул елларда! Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Мурманск калалары; Идел, Урал, Себер, Урта Азия яклары дисеңме...

Күңелле иде ул чакта. Шыгрым тулы тамаша заллары, алкышлар, чәчәкләр һәм инде, әлбәттә, эш беткәч уйнарга ярый дигәндәй, концерттан соң кунакка барулар, бәлешкә йөрүләр. Һәммәсе истә, күңелдә калган. Истә генә түгел, сагындыра да ул еллар, ул юллар. Ләкин, ни кызганыч, үткәннәргә кире кайтып булмый, сагынып сөйләргә генә кала шул...

Солист (аерым уйнаучы) буларак та, аккомпаниатор-концертмейстер буларак та чыгышлар күп ясарга туры килде. Озак еллар буена Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Вафирә Гыйззәтуллина, Флера Сөләйманова, Хәнәви Шәйдуллин, Рабига Сибгатуллина, Минхәмәт Гыйләҗев, Габдулла Рәхимкулов белән бергә эшләргә

насыйп булды миңа. Ә аңа кадәр, Казан дәүләт консерваториясендә укыганда ук, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җырчылары – Фәхри Насретдинов, Хәдичә Гыйниятова, Рәйсә Билалова, Рәйсә Нуриева, Рафаэль Сәхәбиев белән чыныгу алган идем. Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева, Мирсәет Сөнгатуллин, Рөстәм Маликов, Галина Казанцева, Рузалия Абдуллина – болары минем сабакташларым, иҗатташларым. Мәсгут Имашев, Рафаэль Ильясов, Миңгол Галиев, Исламия Мәхмүтова, Ринат Мифтахов һәм башка, исемнәре телгә алынмаган профессиональ һәм үзешчән артистлар – барысы да минем сәхнәдәшләрем, юлдашларым. Тугандаш Башкортстан артистлары Фәридә Кудашева, Фидан Гафаров, Рамазан Ямбәковлар белән дә зур сәхнәләрдә чыгыш ясадык.

Әгәр дә миңа: «Филармония синең өчен нәрсә ул?» – дип сорау бирсәләр, мин, һич икеләнмичә: «Ул – чын тормыш һәм иҗат Мәктәбе», – дияр идем. Ә «Мәктәп» сүзен баш хәреф белән язуым очраклы түгел. Филармония ул – Мәктәп, ә ул үз чиратында күп нәрсәгә өйрәтә.

Шуның белән «Филармония» өлеше тәмам дигән идем. Юк, тәмам түгел, чөнки Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе юбилее уңаеннан аның 70 еллык тарихына багышланган «Татарская государственная филармония им. Габдуллы Тукая 1937–2007» дигән китап басылып чыкты. Әгәр дә мин бу зур хезмәт турында үз китабымда язмасам, аның басылып чыгуын бераз гына булса да яктыртмасам, кем әйтмешли, зур гөнаһ һәм олы хата булыр иде.

Китап Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиевнең хәер-фатихасы, аның «Созвучие и содружество» дип исемләнгән язмасы белән башлана. Илбашыбызның бу бәяләмәсен без бөек Тукаебыз исемен йөртүче Татар дәүләт филармониясен, анда эшләгән һәм эшләячәк артистларны, хезмәткәрләрне олылау, зурлау, катлаулы һәм мактаулы сәнгать диңгезендә йөзүче корабка ныклы җилкәннәр кую дип кабул итәбез.

Филармония турында озак һәм нәтиҗәле итеп сөйләргә, күп һәм мәгънәле итеп язарга була. Аллага шөкер, миңа эш җиңеләйде: филармония турында китап дөнья күрде. Шуның өчен «Филармония» бүлеген озын-озак итеп язып тормыйм. Китапны укырга кирәк. Китапны сөйләү мәгънәсез бер гамәл булыр иде. Озын сүзнең кыскасы: 1937 елда (21 август көнне) нигез салынган Татар дәүләт филармониясе яңа утларга, нурларга төренеп, гөрләп торсын!

# СӘНГАТЬ КҮГЕНДӘГЕ ЙОЛДЫЗЛАР

*Әдәбият-сәнгать өлкәсендә зур эшләр башкарган, тирән эз калдырган шәхесләребезгә һәрвакыт игътибарлы һәм ихтирамлы булдым. Арабыздан мәңгелеккә киткән һәм бүгенге көндә дә иҗат итүче шәхесләребез турында истәлекләр язарга сорасалар, мин бик теләп алындым, алар турында тиз арада язып бирә бардым. Бу шөгылемне әле хәзер дә дәвам итәм.*

## ИЗГЕ КЕШЕ ИДЕ

1996 ел. Габдулла Рәхимкуловның 70 еллык юбилеен билгеләп узарга әзерләнәбез. Күренекле баянчы Рамил Курамшин белән Габдулла абыйның чираттагы репетициягә килүен көтәбез. Гомер буе төгәл, тәртипле булган кешенең соңга калуы гаҗәп иде. Күңел нәрсәдер сизенә кебек. Һәм дөрес булып чыкты.

Гамилә апага шылтыраттым.

– Габдулла абыең 18 нче больницада, бүген репетициягә килми ул, – диде хәләл җефете.

Мин тиз генә хастаханәгә йөгердем. Барып, баш табиб Рөстәм Бакировны күрдем.

– Барлык сәнгать әһелләре, бөтен татар халкы Габдулла абыйның 70 еллыгын билгеләп узарга җыена. Юбилярыбызны, зинһар, тиз арада терелтеп бирегез! Вакыт көтми, – дидем.

Аның белән бергәләп Габдулла абый янына юнәлдек. Коридор буйлап барабыз. Юлыбыз ашханә яныннан үтә. Әнә Габдулла абый үзе! Ашханәдә утыра. Мине күргәч, егетләргә генә хас җиңеллек белән йөгереп чыкты. Һәм мин аны баш табиб белән таныштырдым.

Г.Рәхимкулов палатасында өчәүләп шактый гына сөйләшеп утырдык. Габдулла абый белән Рөстәм әфәнде якташлар булып чыкты (шулай икәнен аңа кадәр үк белә идем).

– Габдулла абый, әйт, нәрсә кирәк? Мөмкин кадәр ярдәм итәрбез, кулдан килгәнчә тырышырбыз, – диде аңа баш табиб.

Габдулла абый терелеп чыкты. Репетициягә йөри башлады. Юбилее шаулап-гөрләп узды.

Язманың исеме «Изге кеше иде» дип атала. Моның тарихы болай булды. Без 1997 елның 1 октябрендә Арча районы Урта Бирәзә авылында концерт бирдек. Бу Габдулла абыйның соңгы шәхси

концерты булды... Дөрес, ул моннан соң да Язучылар берлеге йортында җырлаган, ләкин бу үз концерты түгел иде.

Әле тагын да эшләргә исәбе бар иде. Тик көтмәгәндә-уйламаганда арабыздан китеп барды.

Габдулла Рәхимкуловның соңгы концертына афишаны да миңа ясатырга туры килгән иде. Ул сөекле җырчыбызга «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелү уңаеннан басылды. Ләкин, ни кызганыч, шушы афишалар белән эшләргә генә язмаган икән...

Вафатына бер ел тулар алдыннан Габдулла Рәхимкуловны искә алырга каберенә бардым. Ул Чүпрәле районының Кече Шәйморза авылы туфрагына җирләнде. Җәсәде Казаннан ике йөз чакрым чамасы ераклыкта ятса да, ул бүген дә безгә якын, бүген дә безнең арада...

## МАЭСТРОНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Рифкать Гомәров дисәк – «Саз» халык вокаль ансамбле, «Саз» дисәк, Рифкать Гомәров күз алдына килеп баса. 1968 елда оешкан бу коллектив Ауропаның бик күп илләрендә: Румыния, Чехословакия, Болгария, Венгрия, Германиядә гастрольләрдә булды. Кем әйтмешли, 70 нче еллар «Саз»ның чәчәк аткан чагы иде. Ул әле һаман да чыңлый, халыкка хезмәт итә.

Рифкать Әхәт улы Гомәров 1942 елның 20 гыйнварында Татарстан Республикасының Чирмешән районы Кара Чишмә авылында туа. Ятимлек аны гомере буе эзәрлекли. Башта әтисе фронтта һәлак була, аннары әнисе дөнья куя. Әтисе фронтка киткәндә, ул карында гына кала, шулай да Әхәт абзый әйтеп калдыра: «Малай туачак, Рифкать исеме кушарсыз», – ди. Кечкенә малай әнисе тәрбиясендә үсә. Әмма озакламый җиде яшьлек сабый бөтенләй ятим кала. Әнисенең әнисе аны үз канаты астына ала.

Сагышлы бала яшьли җыр-моңга гашыйк була, күршеләреннән тальян гармун табып, үзлегеннән уйнарга өйрәнә. Ул вакытта татар сәхнәсенең йолдызларына әверелгән мәшһүр баянчыларыбыз Мөхтәр Әхмәдиев һәм Рокыя Ибраһимованың уйнауларын пластинкадан тыңлый. Бу ике останың уйнавы яшь Рифкатьтә сәнгатькә, җыр-моңга ихтирам, мәхәббәт уята.

1956 елда Кара Чишмә авылына ул чорның зур артистларыннан берсе, олы талант иясе Әзәл Яһүдин концерт белән килә. Үзе җырлый, сөйли һәм, әлбәттә, кечкенә аккордеонда да сыздырып җибәрә. Рифкать әлеге артистны кызыксынып, онытылып, йотлыгып тыңлый...

Ат җигеп колхоз эшендә эшләүче Рифкатькә икенче көнне Әзәл ага Яһүдинне күрше авылга – Бәркәтәгә илтеп куярга туры килә. Клуб янында җыелган халык Әзәл Яһүдингә: «Рифкатьне укытырга кирәк, ярдәм итсәгез иде», – дип мөрәҗәгать итә.

Калганын алар юлда барганда сөйләшеп бетерәләр. Шушы елда авыл халкы, акча җыеп, Рифкатьне Казанга укырга озата.

Керү имтиханнарын уңышлы гына тапшырып, Рифкать Гомәров 1959 елда Казан музыка училищесында укый башлый. Баяны булмау сәбәпле, училище директоры Ильяс Әүхәдиев Рифкатьне Мөбарәк Батталов укыткан гобой классына тәкъдим итә. Ул анда озак укымый. Һөнәр училищесына укырга китә, чөнки биредә өч тапкыр бушлай ашаталар һәм киендерәләр. Ә музыка училищесында стипендия дә аз була, гобой да ошап бетми. Һөнәр училищесын тәмамлап, слесарь-җыючы дигән белгечлек алып чыга егет. Рифкать училищеда укыган елларда ук «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең М.Горький исемендәге клубына йөри башлый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. Баян буенча Виктор Яковлевтан дәресләр ала. Уку түләүле була. Ләкин Рифкатьнең ятим икәнен белгәч, укытучы аннан акча алуны туктата. Әлеге егетнең баянда уйнавына тиздән профессиональ җырчылар да игътибар итә башлыйлар.

Бервакыт Рифкатьнең уйнавын Зифа апа Басыйрова тыңлап тора. Үз янына дәшеп алып сөйләшә дә тиздән аны Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә алып килә. Ул вакыттагы директор М.Ф.Боголюбов Рифкатьне, һөнәрчеләр училищесын тәмамлагач, филармониягә эшкә килергә чакырып кала. 1959 елда Р.Гомәров филармониядә эшли башлый, аны Әлфия Авзалова бригадасына билгелиләр. Соңрак яшьләр бригадасы оештыралар: җырчылар Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, нәфис сүз остасы Рафаэль Галиев, баянчы Рифкать Гомәров... Элеккеге Советлар Союзы буйлап гастрольләр башлана.

Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Рифкать яңадан филармониядә эшли башлый.

Бервакыт Уфа шәһәрендә гастрольдән соң Р.Гомәровка Әлфәрит Солтанов мөрәҗәгать итә (ул заманнарда Әлфәрит Солтанов Башкортстанның иң оста баянчыларыннан берсе була. Аның уйнавын Татарстан радиосы да еш яңгырата иде): «Энем, моңлы да уйныйсың, бармакларың да йөгерә, ләкин нишләп басларны унисон уйныйсың?» – ди. Музыкаль белеме булмаган Р.Гомәров сул яктагы аккордларга басмый гына уйный. Сәбәбе – мажорны минордан аермау. Алга таба музыкаль грамотасыз эшләү мөмкин булмый. Һәм Рифкать үзенә сүз бирә: укырга. Бары тик уку гына аны коткара алачак. Ул 1967 елда Казан музыка училищесына ка-

бат укырга керә. Бу юлы инде: «Баян классына егерме биш яшьлек күсәк укырга килгән», – диш, Ломоносовтан көлгән кебек, Гомәровтан көләләр. Геннадий Дмитриевич Шаронов классында белем алып, музыка училищесын ул 1971 елда тәмамлый. Р.Гомәров 1968 елда «Тасма» берләшмәсе клубында «Саз» кызлар вокаль ансамбле оештыра. Ансамбльне күп тавышка җырлатыр өчен училищеда баян классында алган белем генә җитми. Шуңа күрә Рифкать 1971 елда Казан дәүләт мәдәният институтының хор дирижерлыгы бүлегенә укырга керә.

Институтны тәмамлагач, клубта ансамбль белән эшләвен дәвам итә, бер үк вакытта шул клубта директор вазифасын да башкара. Ансамбльгә кызларын мәктәпләрдән, техник училищелардан җыя. Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисткасы Венера Ганиева, сүз остасы, пародияче Алмаз Хәмзин кебек талант ияләре сәхнәдәге беренче адымнарын Р.Гомәровның «Саз» ансамблендә башлыйлар. Ул гына да түгел, унбишләп вокаль ансамбльнең булачак җитәкчеләре дә Гомәров мәктәбен узалар.

Рифкать Гомәров берничә чит илдә булып кайта. 1960 елда ул Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары белән Вьетнамда, Кытайда һәм Кореяда гастрольләрдә була. Концертлар зур-зур стадионнарда уздырыла, халык бик яратып тыңлый, чөнки аларның музыкасы да пентатоникага нигезләнгән. (Гади тел белән әйтсәк, аларның музыкасы да «татарча».) Татарстан артистларын ул вакытта шулкадәр җылы каршылыйлар: Пекиннан Ханойга очарга Хо Ши Мин хәтта үзенең шәхси самолетын бирә. Вьетнам халкы татар артистларын чәчәкләргә, алкышларга күмә...

«Саз» ансамбле җырлаган барлык җырларны Р.Гомәров үзе эшкәрткән. Ә инде аның үзе язган җырлары телдән телгә күчте.

## ИҢ АВЫР ТАШ

Таһир Якупов белән миңа сәхнәдә бергә эшләргә туры килмәде. Шулай булса да, без аның белән танышлар идек. Мин Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә килгәндә, ул аннан «эшләп бетереп» киткән иде.

Ә нәрсә бәйли соң мине җырчы Таһир Якупов белән? Нинди уртаклык бар?

Болай булды. Таһир аганың соңгы көннәренә, аның якты дөньядан киткән вакытының шаһиты булырга туры килде миңа. Аяныч, әлбәттә...

...Мәскәү шәһәреннән администратор шылтыратты:

– Халкыбызның бөек җырчысы Хәйдәр Бигичевның вафатына бер ел тулуга багышлап Мәскәүдә зур искә алу концертлары оештырабыз. Таһирны да монда югалттылар, аны көтәләр, сагыналар. Кирам, сиңа шундый үтенеч: Таһирны Мәскәүгә алып кил әле. Халкыбыз аны күрсен, тыңласын, шатлансын. Рәхим итегез, көтәбез, – диде ул.

Шуннан соң Таһир абый белән очрашырга һәм репетицияләр ясарга сүз куештык. 1999 елның ноябре якынайганнан-якыная. Әзерләнергә кирәк. Алда – гастроль, Мәскәү...

Октябрь ае килеп җитте. Һәм... аяз көнне яшен суккандай булды: көтмәгәндә, уйламаганда халкыбызның сөекле җырчысы, милләтебезнең моңлы, газиз баласы Таһир Якупов арабыздан мәңгелеккә китеп барды.

...Без аны Тукайлар, Сәйдәшләр күмелгән зиратка җирләдек. Максат Гомәровны алыштырып, көрәкне кулыма алдым. Бөтен тәнемә салкын тир бәреп чыкты. Өс киемемне Флера Сөләймановага бирдем һәм уйлап куйдым: иң авыр көрәк – зират көрәге, иң авыр таш кабер ташы икән.

Кире кайтканда, килгәндәге кебек, машинада без биш кеше идек: Хәнәви Шәйдуллин, Рамил Курамшин, Максат Гомәров һәм хатыным Гөлшат, рульдә – мин. Авыр тынлык. Башлар түбән иелгән.

Ә күктә кояш елмая. Җир өстендә хәсрәт сибелгән кебек сары яфраклар...

## «АЯКЛЫ» ТАРИХ

Гади тел белән аңлаешлы итеп әйткәндә, Әзәл ага Яһүдин белән мине язмыш таныштырды. Ә вакыйга болай булды.

Егерменче гасыр тәмамланып килә. Кешелек дөньясы яңа меңьеллыкка кереп бара. Ә баянчылар турында китап һаман да юк! Нишләргә? Язарга. Булдырырга. Бастырырга. Ә ничек? Исәннәр турында мәгълүматларны язып алып редакциягә бирәсең. Ә үлгәннәр турында? Алар хакында бер белешмә дә, истәлек тә юк. Менә бу мәсьәләдә инде бүгенге көндә исән өлкән буынга мөрәҗәгать итәсең. Легендар җырчыбыз Рәшит Ваһапов белән бергә эшләгән данлыклы баянчы-гармунчы Гани Вәлиев турында язарга мин Әзәл Яһүдиннән үтендем. Аның белән без Матбугат йортында (Бауман урамы, 19 нчы йорт) очраштык. Габделәзәл ага бик теләп һәм берсүзсез, бернинди ялындырусыз риза булды. Сөйләшенгән вакытка материалны һәм Гани Вәлиевнең фотосын

алып та килде. Бу язма ул вакыттагы «Татарстан хәбәрләре» (баш мөхәррире Ренат Харис) газетасында басылды һәм соңрак «Татар баянчылары» дип аталган китапта үзенең лаеклы урынын алды. Гани Вәлиевнең концерт афишаларын миңа Рәшит Ваһаповның туган авылы Актукта (Нижгар өлкәсе) күрергә туры килде. Эре хәрефләр белән өстә – «Гани Вәлиев уйный», аста – «Рәшит Ваһапов җырлый» дип язылган. Хәзерге игъланнарда, гадәттә, җырчы алдан языла. Ә миңа гади генә итеп бер иптәш аңлатты: «Башта баянчыны язуның сәбәбе шул: чөнки ул көйне җырчыдан алдарак башлый һәм шул дәрәҗәле хезмәт башкара», – диде. Бәлки, шулай дөрестер...

Сүз башым бит Шүрәле дигәндәй, Әзәл агага әйләнеп кайтыйк әле. Мин Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлаганда, югарыда исемнәре атап узылган артистлар лаеклы ялда иделәр. Кайберләре инде безнең арабызда да юк иде.

Утыз биш күренекле баянчыны үз эченә алган «Татар баянчылары» исемле китап дөнья күрде. Шушы китапны язуда бәләкәй генә өлеш керткән, күпмедер күләмдә көч куйган Әзәл ага Яһүдингә үземнең исемнән, гомумән, барыбыз исеменнән дә олы рәхмәтемне әйтәсе килә. Бу эшләрне, рәхмәтләрне аның туганнары, дуслары кабул итеп алсыннар, ә Әзәл ага Яһүдингә бу изге теләкләр дога булып ирешсен иде.

## «САРА БЕЗНЕҢ БЕЛӘН БАРА»

1978 елның февраль ае иде. Казан консерваториясендә укыган чагым. Кышкы каникул вакытында М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артистлары белән Пермь шәһәренә гастрольгә барырга җыенабыз.

Гастрольгә барыр алдыннан Фәхри ага Насретдинов ниндидер йомыш белән Татарстан радиосына керә. Шушы сәфәр белән хәбәрдар бер хезмәткәр җырчыдан сорап куя: «Фәхри абый, сез Сара апа белән барасызмыни?» – ди. «Юк, Сара безнең белән бара», – ди Фәхри ага.

Концертның бер бүлеге С.Садыйкованың иҗатына багышланса да, афишада зур кызыл хәрефләр белән «Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Фәхри Насретдинов җырлый» дип язылган иде. Шуннан аңлагыз инде кемнең кем белән барганын...

Әйткәнемчә, бер бүлек Сара Садыйкованың иҗатына багышланды, һәм бары тик аның әсәрләреннән генә төзелгән иде. Концерт уңышлы гына бара. Рояль артында, әлбәттә, автор Сара ханым Садыйкова. Алып баручы тагын бер җырын игълан итте.

һәм... Кирәк бит! Сара апа үзенең җырын үзе онытты! Менә сиңа мә! Паузаны тутырыр өчен Мәхмүт Хөсәен нәрсәдер сөйләгәндә, тиз генә мине эзләп табып (мин сәхнә артында фикер җыеп, образга кереп йөри идем), җырның көен тиз генә искә төшер, диделәр. Гомер буе бу көйләрне тыңлап, җырлап, уйнап үскәнгә күрә, тиз генә җырлап та бирдем. Сара апа, берни булмагандай (дөрес, ул бераз борчылган иде, шулай да халыкка сиздермәскә тырышты, чын артист сәхнәдә көтелмәгән хәлләрдән югалып калмаска тиеш): «Рәхмәт, Кирам акыллым», – диде дә кереш музыканы уйнап та җибәрде. Рәисә ханым Билалова белән матур итеп, югары башкару осталыгы белән җырлап та бирделәр.

И бу гомер дигәнең... Юкка гына аны аккан суга, искән җилгә тиңләмәгәннәр. Хәтер йомгагымны сүтеп утырам. Менә фоторәсем: «Пермь шәһәре. Февраль ае, 1978 ел» дип язылган. Бу истәлекләрне мин 2006 елның февраль аенда язып утырам. Егерме сигез ел үтеп тә киткән... Ә инде шушы гастрольдә бергә булган, бер сәхнәдә чыгыш ясаган артистларыбызның да берничәсе – Фәхри Насретдинов, Сара Садыйкова, Рәисә Билалова, Мәхмүт Хөсәен, Рәисә Нуриева, Зиннур Гыйбадуллин – арабыздан мәңгелеккә китеп бардылар... Ләкин аларның иҗаты яши. Алар мәңге безнең арабызда...

## АҢА УЙНАУ УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

Илһам Шакировның баянчысы булу миңа җиңел генә бирелмәде. Зур сәхнәгә менеп, аның янәшәсенә басып уйнау өчен мин фәкыйрегезгә шактый еллар кичәргә һәм озын юллар үтәргә туры килде: башта Әлмәт музыка училищесы, аннары Казан дәүләт консерваториясе, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Әлфия Авзалова җитәкчелегендәге концерт бригадасы... И.Шакировка уйнау гади уйнау гына түгел, ул – бөтен татар халкы алдында, барлык төрки халыклар алдында имтихан тоту дигән сүз.

Нинди генә шәһәр-авылларда булмадык без Илһам ага белән: Мәскәү, Оренбург, Уфа, Түбән Новгород, Екатеринбург дисеңме... Ә 2003 елда без Илһам Шакиров белән Мәскәү сабан туенда чыгыш ясадык (безнең белән Әлфия апа Авзалова да бар иде). Ә бервакыт безгә Әлмәт төрмәсендә дә концерт белән булырга туры килде. Җәй көне иде ул. Эссе һавада әлсерәп, су коенып кайтып киләм. Шунда каршыма сабакташым Миңнегаян очрады.

– Кирам, – диде ул, – Әлмәткә концерт белән килгәнсез икән. Бездә дә концерт күрсәтә алмассызмы?

– Кайда? – дип сорадым мин.

– Төрмәдә...

– Ә?! Мин риза, ләкин Илһам ага белән киңәшләшергә кирәк, ул ни әйтер бит...

Илһам Шакировка хәлне аңлатып бирдем.

– Кара, кызык бит бу! Кайларда гына булмадым, төрмәдә концерт куйганым юк иде әле, – диде җырчы. – Барабыз!

Икенче көнне без Әлмәт төрмәсенең штабында идек инде. Концертны алып баручы Рәшит Сабиров артистлар белән таныштырды. Миңа да чират җитте.

– Ә монысы – баянчыбыз Кирам Сатиев. Сезнең замполитыгыз майор Әхмәтов белән 8 ел бергә утырган, – диде Рәшит. Пауза. Төрмә штабы шаулашып алды. Рәшит сүзен дәвам итте: – Бер парта артында...

Зал җиңел сулап куйды.

Мәскәүнең П.Чайковский исемендәге концерт залында чыгышыбыздан исә Илһам ага белән Татарстанга «Алтын Аполлон» бүләген алып кайттык. Русия күләмендә уздырылган бу бәйгедә Кара диңгез флоты ансамбле, Якут-Саха Республикасыннан, Санкт-Петербург, Мәскәү, Түбән Новгород һәм башка шәһәр, төбәкләрдән бик күп сәнгать осталары катнашты.

Ел саен 15 февральдә Илһам Шакировның туган көне зурлап билгеләп үтелә. Шушы тантанада мин ел саен катнашам. Зал һәрчак шыгрым тулы була. Анда минем дә туганнарым, дусларым килә. Әткәбез Шәйхиҗан гомер буе Илһам аганың репертуарыннан «Әниемә хат» (Ә.Даутов сүзләре һәм көе), «Менәргә иде Урал тауларына» (Г.Зәйнашева сүзләре, М.Мозаффаров көе) җырларын җырлады. Ә энем Хәсәнгә «Төннәрем йокысыз үтә» (Ә.Ерикәй сүзләре, В.Усманов көе) аеруча ошый. 1993 елда мине «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә тәкъдим иткәндә, документларны да Илһам ага Шакиров үзе тутырган иде...

«Кырык биш ел тоташ җыр ява» дип исемләнгән концертта миңа Илһам Шакировның абыйсы Кыям агага, аның уллары Флүргә, Рөстәмгә, абыйсының оныгы Илгизгә дә уйнарга туры килде. Мин шуның белән дә бәхетле. Әле Илһам аганың туган авылы Яңа Бүләктә сабан туенда катнашканым турында әйтергә онытып торам икән. Менә монысы белән инде мин икеләтә бәхетле!

*«Мәдәни җомга», 2005, 11 февраль*

# МОҢ САРЫЛА ЙӨРӘК ТҮРЕННӘН

## САГЫНУ

Син генә минем уйларымда,
Төнлә төшләремә керәсең.
Ал чәчәкләр җыеп кулыңа,
Минем алларыма киләсең.

Нинди чибәрләрне күрдем мин,
Синең кебекләрен тапмадым.
Ямалының айлы кичендә
Урман аланнарын таптадык.

Кайтыйк, иркәм, безнең якларга,
Агыйдел буенда йөрербез.
Бергә эчкән чишмә суларын,
Болын тугайларын күрербез.

Ямалының урманнары ямьле,
Шул урманга яшьләр килерләр.
Синең белән тагын очрашырбыз,
Тиңдәш булсын безнең күңелләр.

Нишлик, дускай, җәйләр үтә инде,
Озакламый язлар килерләр.
Туган якта кабат очрашырбыз,
Салкын (озын) кышлар тизрәк үтсеннәр.

Челтерәп аккан чишмә сулары,
Агыйдел буйлары,
Болын тугайлары,
Айлы төннәре,
Кояшлы көннәре,
Җәелеп яткан алма бакчалары...
Бары тик Тат.Ямалы авылында гына.

*1972*

## ТАШЧЫ КЫЗГА

Тыңладым мин елгаларның шавын,
Күрдем кызның кирпеч өйгәнен.
Әй беләсе иде ни уйлавын,
Бу чибәрнең кемне сөйгәнен.

Урамнарны иңләп-буйлап йөрдек,
Ләкин болар күпкә бармады.
Өзелеп-өзелеп минем яратканны,
Белмим, никтер аңлый алмады.

Яшь йөрәктә хәзер минем сагыш,
Берьялгызы калгач, нишләсен...
Ташчы кызны күргәч талшына ул,
Күргән саен түгә күз яшен...

Кайберәүләр мине үгетлиләр:
«Ташла аны, башка табылыр».
Юк, юк, сине ташлап китә алмам,
Ташлап китсәм... күңел зарыгыр.

Сөйгән ярым калыр минем белән,
Мине аңлый бары ул гына...
Без төзегән йортлар, яңа йортлар,
Яңа җырлар – яңа буынга!

Тыңладым мин елгаларның шавын,
Күрдем кызның кирпеч өйгәнен.
Бәлки, берәр вакыт ул да әйтер:
«Сине генә өзелеп сөям мин».

*1975*

## ЯРАТАМ

Язлар җитсә, минем күңелемдә
Бөре кебек хисләр уяна.
Иске ярам әйтә: «Оныт аны,
Аның турында башка уйлама».

Бик тиз генә онытып булырмы соң,
Китәрме ул минем күңелемнән?

Минем өчен оныту, аны оныту
Кыен булыр хәтта үлемнән.

Язлар җитсә, үзенең хуш исләрен
Сирень төрле якка тарата.
Минем йөрәк типкән саен әйтә:
«Аны гына өзелеп яратам».

*1976*

## СӨЙГӘНЕМНЕ ЭЗЛИМ

Үземә тиң гади авыл кызын
Айлар, еллар буе эзләдем.
Ләкин, аны таба алмасам да,
Табалмам дип өмет өзмәдем.

Җәйге таңда кояш чыккан кебек
Килеп чыгар төсле каршыма.
Әйтер кебек: «Кемне сөясең син,
Нинди уйлар синең башыңда?

Төштә күрәм: авыр газап чигеп,
Яшел болыннарда йөрисең,
Ник соң шунда сөю билгесенә
Чәчәкләрне өзеп бирмисең?

Мин дә синең кебек тиң кешене
Гомерем буе эзләп йөримен,
Синнән акыллырак, синнән матуррак,
Ягымлырак кеше күрмим мин...»

Сүнмәс өмет, татлы хыял белән
Яшәрмен мин гомерем буена.
Күрмәсәм дә сине, чәчәк бирмәсәм дә,
Син булырсың минем уемда.

Син эзләдең мине, ә мин – сине,
Тик язмышлар туры килмәде...
Бәлки әле, безне очраштырыр,
Кавыштырыр тормыш җилләре!

*1978*

## ИДЕЛЕМ ТАҢНАРЫ

Идел өстендәге таң җилләре
Чәчләремнән назлап исәләр.
Акчарлактай очкан «Метеор»лар
Еракларга алып китәләр...

Алып китсәләр дә еракларга,
Аерса да тормыш юллары,
Һич онытмыйм, исләремнән чыкмас
Халкыбызның милли моңнары.

Башка җирләр матур булсалар да,
Тукай туган якка гашыйкмын.
Туган ягым сиңа, Иделемә,
Казаныма кире кайтырмын.

*1978*

## ЯШЬЛЕК ГӨЛЕ

Яшьлек гөлен сиңа өздем диеп,
Күзләреңнең яшьләрен түкмә.
Тәрәз гөлем хуш исләрен бөрки,
Иснәмичә тирәләп үтмә.

Иснә, дустым, мин утырткан гөлне
Һәм тыңлап үт йөрәк тибешен.
Әйтмә миңа үзәк өзгеч сүзләр,
Тыңла әйткән сүзен инешнең.

Инеш әйтер: «Түкмә күз яшеңне
Һәм елама өздем гөлне дип.
Ул яшәрер, бәлки, чәчәк атар,
Өзгән кешене син гафу ит...»

*1978*

## ТУЙ БҮЛӘГЕ (ТЕЛӘГЕ)

Туегызга мине чакырдыгыз.
Шат күңелле йөзләр күренә.
Бәхет теләп кояш нурын сибә
Сез утырган өйнең түренә.

Озын гомер, бәхет телим сезгә,
Авырлыклар читләп үтсеннәр.
Киң күңелле дуслар юлдаш булсын,
Юлыгызда гөлләр үссеннәр.

Гомер буе сезгә елмайсын яз,
Бер-берегезне тиң дип таптыгыз.
Төнбоеклар кебек саргаймагыз,
Тюльпан кебек чәчәк атыгыз!

*1979*

## БАТЫРЛАР

Язмыш җиле безне еракларга –
Буа якларына ташлады.
Салкыннарга түзеп, авырлыкны җиңеп,
Яшь артистлар алга атлады.

Ачык машинада, пычрак арбаларда
Атлар җигеп юлда йөрдек без.
Татар сәнгатенә тап төшермәс өчен,
Авыр газапларны күрдек без...

Кышкы салкын, февраль бураннары,
Бозау асрый торган фатирлар.
Клуб идәнендә ач йоклаган чаклар
Куркытмады сезне, батырлар!

*1979*

## АРТТА КАЛДЫ СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫ

Биш ел буе бишле трамвайда,
Биш сызыклы нота юллары...
Юлдаш булды думбра, балалайка,
Баян, аккордеон моңнары.

Мәктәп сукмаклары, училище юлы –
Унҗиде ел булды. Санадым.
Консерватория – бишьеллык вуз –
Синдә үтте, синдә, Казаным.

Авыр булды унҗиде ел уку,
Ләкин ике диплом кесәдә.
Үкенмимен барлык гомеремнең
Егерме дүрте укып үтсә дә.

Дошманнарым һәрчак аяк чалды,
Көнләшкәннәр астан кистеләр.
Астан кисеп өстән ямаучылар
Янган утка бензин сиптеләр.

Бензин сибү яхшы булгандырмы,
Төшенмәдем, аңлый алмадым.
Алар үзенекен итте, ә мин – үземнекен,
Катыргыны алмый калмадым!

Укыган чакта каравылда тордык
(Студентка акча бик кирәк).
Өйдән переводлар, туйга чакырулар,
Стипендияләр булды бик сирәк.

Барысын да язу кирәк түгел,
Студент булганнар аңларлар...
Шаһит булсын бушаткан вагоннар,
Каравылда аттырган таңнар!..

*1979*

## БӘЛКИ, ОЧРАШЫРБЫЗ...

Тау белән тау гына очрашмый.
*Татар халык мәкале*

Күз карашың миңа текәлгәч тә,
Мәҗбүр булдым борылып карарга.
Залда булган халык арасыннан
Сине, иркәм, эзләп табарга.

Эзләп таптым. Күзем күзләреңнән
Алалмыйча озак карадым...
Әйталмадым гашыйк булуымны...
Аэропортка китеп барамын...

Концерт беткәч, коридор буйлап киттең,
Борылып-борылып миңа карадың...
Хәзер үкенәм оялуым өчен,
Ник яныңа үзем бармадым?!

Очрашмыйлар тау белән тау гына,
Миндә әле сүнмәс өмет бар.
Йөрәк яна утлар сүнсәләр дә,
Әйтерсең лә синсез дөнья тар.

Күзләр күрештеләр, сөйләштеләр,
Үзебезгә туры килмәде...
Бәлки әле, безне очраштырыр,
Кавыштырыр тормыш җилләре!..

*1979*

## АНДЫЙ ДУСЛАР КИРӘК ТҮГЕЛЛӘР

Эх, дусларым, сезнең белән
Күтәрелә һәрчак күңелләр.
Ялгыш уйлыйм: кесә калын чакта
Килгән дуслар дуслар түгелләр.

Махмыр чакта, башым ярылганда,
Төшләремдә сыра сузасыз.
Өндә чакта, танымаган булып,
Мин юк яктан урап узасыз...

Ач чагында сездән акча сорыйм.
«Юк бит», – дисез, сәбәп табасыз.
Гөнаһсыз сабый бала кебек,
Күзләремә карап багасыз.

«Дус» сүзендә, дустым, шуны аңлыйм:
Суны бирсен сусыз инешең.
Авыр чакта һәрчак ярдәм итсен
Һәм ишетсен йөрәк тибешен.

Кайбер «дуслар» якын итмәсә дә,
Белеп килә акчаң булганын.
Җилгә каршы бер дә төкермичә,
Бергә көтә унбер тулганын.

Андый дуслар миңа кирәк түгел,
Андый дуслар дуслар түгелләр.
Аңласын ул сине, син дә аны,
Сердәш, тиңдәш булсын күңелләр!

*1979*

## ӘЙТ ДӨРЕСЕН!

Сөйләштек тә, серләштек тә,
Аңламадым кем икәнеңне.
Һаман көтәм: «Сине генә сөям
Йә кыралмыйм», – дип әйткәнеңне.

Начар уйламыйм мин синең хакта,
Ә күңелдә никтер шигем бар...
Шуңа сорыйм: киләчәк тормышта
Булмасын дип ызгыш, талашлар.

Ник әйтмисең: «Ялгышасың, дустым,
Дөрес уйламый, – дип, – күңелең».
Фикерләрең ялгыш, шикләнүләр,
Кимсетүләр кирәк түгелен.

Ихлас күңелдән әйт, яшермичә,
Туры карап минем күземә.
Кыенсынма, әйт син чын йөрәктән,
Ачуланмам туры сүзеңә.

Алдашканны һич тә гафу итмим,
Гафу итми аны яшь йөрәк.
Сикәлтәле тормыш сукмагыннан
Барыр өчен пар канат кирәк.

Йөзәр өчен диңгез дулкынында
Ватылмаган кораблар кирәк!..

*1979*

## БӘЛКИ, МИНДЕР СИНЕҢ ЭЗЛӘГӘНЕҢ?

Бик акыллы, уйчан, зирәк, эшчән
Һәм ягымлы булып күрендең.
Шушы көннән керсез йөрәгемә
Үрмә гөлләр булып үрелдең.

Карашларың миңа канат бирә,
Елмаюың – кояш яктысы.
Әйткән сүзең һәрчак илһам өсти,
Йөзләреңдә – сөю чаткысы.

Теләр идем: үзеңә тиң булган
Тормыш дустын эзләп табарга.
Сикәлтәле тормыш сукмагыннан
Абынмыйча бергә барырга.

Яшь чагында кызлар ялгышалар,
Матур сүзләр аны алдыйлар...
Тормышларын тиз өзелә торган
Нечкә җепләр белән ялгыйлар.

Тышкы чибәрлеккә кызыкма син,
Күңеле киң булсын кешенең.
Нәтиҗәсе булсын әйткән сүзнең
Һәм эшләгән барлык эшенең.

Бәлки, миндер синең эзләгәнең
(Булмаса да күрсәткән эшем).
Кайнап торган тормыш диңгезендә
Бергә йөзә алырлык кеше.

*1979*

* * *

...Яшьлек үтә. Көннәр, айлар, еллар
Сиздермиләр мине сүткәнен.
Күңел сине көтә,
Гомер тиңсез...
Кайда, кем син, өзелеп көткәнем?..

## ҮТТЕ ЯШЬЛЕК

Чирек гасыр үтте төшүемә,
Газиз әнкәй, синең бишектән.
Язмыш мине ундүрт яшьтә чакта
Алып чыгып китте ишектән.

Киткән чакта күзгә яшьләр килде,
Еламадым, түздем, чыдадым.
Тормыш миңа үзе күрсәтте
Тирә-юньдә дошман, дус барын.

Авыл таңы. Гөлҗимеш җыюлар,
Сөяк сату, чана тартулар.
Сазлыкларда урлап печән чабу,
Сыер җигеп батып ятулар...

Бу көннәрне һич тә онытмадым,
Ятим бала кебек йөрмәдем.
Кайнап торган тормыш диңгезендә
Мин сүнмәдем, яндым, дөрләдем.

* * *

Ник соң болай үтте минем яшьлек?
Яшьлек дәвам итә! Үтмәгән!
Ел ярымны чирек гасырдан соң
Ватанымны саклап үткәрәм!

*1979*

## АРЫСЛАНГА – КУЯН ПАСПОРТЫ

*(Мәсәл)*

Җәнлекләр патшасы Арысланга
Бирделәр бит Куян паспортын.
Бер хайван да хөрмәт итми аны,
Килеп чага хәтта бал корты.

Монда мораль шундый:
Куян паспорты белән
Арыслан булып булмый.

*1979*

## КУЯН БЕЛӘН БҮРЕ

*(Мәсәл)*

Яр буеннан вак-вак атлап,
Ашыкмыйча Бүре уза.
Суга баткан Куян күреп,
«Коткарам» дип кулын суза.

Бу мәсәлнең моралеи
Үзең уйлап карале.

*1979*

## ХӘЙЛӘКӘР ТӨЛКЕ

*(Мәсәл)*

Хәйлә кора Төлке,
Әйтмә уен-көлке,
Эшчәннәрне күзли –
Тормыш дустын эзли.
Ә үзе бик ялкау,
Зиһеннәре таркау,

Уттай яна күзе,
Әйтә башлый сүзен:
«Загска бармабыз, – ди, –
Имза куеп тормабыз, – ди, –
Курыкма син өйләнүдән,
Чит-ятларга сөйләнүдән».
Ә исәбе – өйләндерү,
Башкаемны әйләндерү.

Мораль монда ачык:
Хәйләкәр Төлкедән
Ераграк качыйк!

*1979*

## «МАТУР АПА»

Ял йортыннан китеп барган чакта
Яшеллекләр, гөлләр арасы...
Чәчәкләрнең хуш исләрен исним,
Ерак әле, ерак барасы.

Алга, артка, уңга, сулга карыйм,
Шундый матур, шундый күңелле!
Бер кыз күрәм: гомерем буе
Эзләгәнем шушы түгелме?

«Мөмкинме?» – дип аннан сорадым да,
Җавап бирде: «Утыр янымга».
Шундый күркәм, шундый чибәр үзе,
Күзләремнең нуры алына.

Кем уйлаган очратырмын дип,
Сүнеп барган яшьлек таңымда.
Танышкачтын... дүрт яшьлек малае
Йөгереп килде аның янына.

...Аңлашылды... Улың да бар икән.
Син барыбер күркәм, ягымлы.
Бирер идем «матур апа»га
Бар нәрсәмне, хәтта җанымны.

Шундый матур, карап туймаслык син,
Гашыйк булдым сиңа мәңгегә.
Гыйшык акыл куша уйланырга,
Ярсыган йөрәк – өйләнергә.

Нишләргә соң, инде нишләргә?
Оныта алмыйм «матур апа»ны.
Акыл яки йөрәк хәл итәрме
Туар таңның ничек атканын?

Бик сагындым, түзәр хәл калмады,
Кыска булсын озын юлларым.
Сине күргәч, сабый бала кебек,
Итәгеңә ябышып еларм‌ын!

*1981*

## СИН ГЕНӘ БИТ МАЯК ЮЛЫМДА

Якынайтып ерак араны,
Йөрәктәге әрнү, яраны,
Кил син, дустым, сөюемне тоеп,
Эшләреңне читкә куеп.
Кил син, дустым, кил син яныма,
Мәхәббәтнең алсу таңына,
Таныш моңнар сине сагына.

Ялгызлыктан ярсу яшь йөрәк
Һаман тиңен эзләп юксына.
Алдагысы – үткән көн сыман,
Үткәннәре – кара төн сыман.
Кара көннәр әйтерсең томан,
Күрер өчен һәрчак талпынам,
Тигез җирдә никтер абынам,
Сине генә, сине сагынам.

Син генә бит маяк юлымда,
Син бит кайгым, син бит шатлыгым.
Күңелем белән сиңа атлыгып,
Тоеп җирнең бөтен шатлыгын,

Тайпылмыйча тормыш юлында,
Язмышымны бирәм кулыңа.
Язмышымны бирәм кулыңа,
Тик син генә маяк юлымда!

*1982*

## ТОРМЫШ ЧАКЫРА

Гомерем буе сине эзләгәнмен,
Бәхетемнең шушы яртысын.
Йөзәр өчен тормыш диңгезендә
Тагын шундый кеше бармы соң?

Кайда идең бу көнгә кадәр,
Ник каршыма килеп чыкмадың?
Сине эзләп иртән таң атканда
Таптап йөрдем үлән чыкларын.

Ник килмәдең, ник соң әйтмәдең
Барлыгыңны миңа шул чакта?
Утыз елга якын тик берүзем,
Мин ялгызым яндым учакта.

Урмандагы кошлар сайравында
Ишетә идем синең тавышны.
Елмаюың – еллар истәлеге,
Карашларың – тормыш агышы.

Сулышыңда – язгы җил җылысын,
Тавышыңда кошлар сайравын
Тоеп, иркәм, мәңге синең белән
Алып барыйк Тормыш Байрагын!

Зур дулкыннар аның диңгезендә,
Юлларында яки таш кына.
Җиңел булмас, ләкин барыйк әле,
Безнең күңел шунда ашкына!..

*1982*

## ҖАВАП КӨТӘМ

Йөрәгемне нидер тырный,
Күңелемне моң баса...
Сине сөю, сагынудан,
Бары юксынудан лабаса.

Кош сайравын, чишмә чылтыравын
Тоймыйм хәзер: син юк янымда.
Ышан, дустым, алда тирән упкын
Яки сүнгән учак янымда.

Мин юк хәзер синең өчен,
Яшь күңелең миннән сүрелгән.
Мәхәббәтең башка берәүгә
Үрмә гөлләр булып үрелгән.

Яратасың, үпкәлисең аны,
Назлап, сөю хисен бирәсең.
Белмисең лә, иркәм, януымны,
Һәр төн саен төшкә керәсең.

Синсез үтә инде яшь гомерем,
Сөяр чагым, яшьлек елларым.
Өмет итәм сузар әле дип
Мәхәббәттә чиста кулларын.

Аңла, иркәм, чын йөрәктән әйтәм,
Бары сине генә яратам.
Чәчләремә инде чал керде бит,
Мин аларны буяп каралтам.

Гомеремнең соңгы яртысында
Кавышу минуты килерме?
Әллә язмыш безне «шаяртып»,
Мәңге шулай әче көләрме?

Әйтче, иркәм, синең мәхәббәтең
Минем тормышымны бизәрме?
Әллә җилләр, тынга каплаңып,
Гел каршыга гына исәрме?

*1983*

## ҖИР АСТЫННАН ЮЛЛАР ЮК

«Җир астыннан юллар юк», – диеп
Әйтә идең исән чагыңда.
Якын итеп ерак араны
Тагын кайттым, әнкәй, яныңа.

Газапланыш сихри тынлыкта,
Басып торам синең яныңда.
«Җир астыннан юллар юк», – диеп
Кабатлыйсың кебек тагын да...

*1990*

## МАМЫК МЕНДӘР ҺАМАН ЧЫЛАНА

Урта мәктәп. Егет гашыйк була,
Газаплана, сыкрый, сызлана.
Мәхәббәтен күпме аңлатса да,
Төкереп тә бирми кыз бала.

Ана күңеле сизә...
– Ярый инде, улым, елама.
– Юк, еламыйм, әни...
Ут сүнгәчтен, үксеп елый егет,
Күз яшеннән мендәр чылана...

Армиядән кайта. Кыз – кияүдә...
Егет кеше тагын моңлана.
Ялгыз калмасын дип ана кызгана.
Ул өйләнә кем теләде шуңа,
Үстерәләр хәзер кыз бала.
Йоклап киткәч, кызын төштә күрә:
– Ярый инде, әти, елама.
Мамык мендәр тагын чылана.

Инде хәзер оныкүстерәләр...
Җитмеш яшьтә бабай – аксакал.

Яшьлек яры күз алдыннан китми,
Көн туса да, кояш батса да.

Юрганыннан тартып оныклары
Уяталар аны йокыдан...
– Ярый инде, ярый, елама...
Чынлап елый сукыр бабай,
Мамык мендәр һаман чылана...

Бабай китте безнең арадан,
Язмышы бит булды бик әче.
Инде беркайчан да кипмәс төсле
Мендәрдәге тозлы күз яше...

*2008*

* * *

Катлаулы бер зур хуҗалык
Тоттырылды Ишәккә.
Аның белеме, сәләте
Алынмады исәпкә.

* * *

Кыр үрдәкләре очар, күлләр тонар,
Без киткәч, башыгыз тынар.
Без китте дип сөенмәгез,
Бездән гайре усаллар туар...

# КЫРЛАРЫМ, БАСУЛАРЫМ

*Шамил Маннапов* сүзләре

*Әнвәр Бакиров* көе
*Кирам Сатиев* эшкәртүендә




14
-га - та йө - рә - гем яр - су - ла -
М
7
М
18
рын. Бай кыр - ла - рым
f
Б
7
М
22
сез, моң - жыр - ла -
Б
Б
Б
25
рым сез. И - ген - че - нең
Ик - мәк бул - са,
8va
mf
М
Б
7
7







Иң беренче аяк баскан
Кырларым-басуларым.
Яшел дулкыннар кузгата
Йөрәгем ярсуларын.

К у ш ы м т а:
Бай кырларым сез,
Моң-җырларым сез.
Игенченең иҗат эше
Җирдә икмәк үстерә.
Икмәк булса,
Җыр да була –
Икмәк Илгә көч бирә.

Яшьлегемдә шунда күрдем
Алсу таң атуларын.
Иң беренче мәхәббәтем –
Кырларым-басуларым.

К у ш ы м т а.

Кайткан чакта балаң итеп,
Сагынып каршыладың.
Язмыш сездән аермасын,
Кырларым-басуларым.

К у ш ы м т а.

# ШҮРӘЛЕ, ШҮРӘЛЕ...

*Нәҗибә Сафина* сүзләре *Кирам Сатиев* көе




Җен дә түгел, җил дә түгел
Күренеп йөри торган.
Шүрәлене саклап тора
Татарда кара урман.

Такмак әйтү:
Шүрәле, шүрәле,
Син Айгөлне күр әле!
Үзе бии, үзе җырлый –
Куллар чабыш тор әле!

Бер мөгез дә, койрык бер.
Кети-кети уйный ул.
Кием-салым кими ул,
Балаларга тими ул.

Такмак әйтү:
Шүрәле, шүрәле,
Син Газизне күр әле!
Җырга оста – җырласын.
Һич оялып тормасын.

Шүрәле урманнары,
Заманның узганнары.
Карурманнар – Җир-ананың
Ямь-яшел юрганнары.

Такмак әйтү:
Шүрәле, шүрәле,
Гамиләне күр әле!
Якты аның йөзләре,
Бардыр әйтер сүзләре.

Шүрәле ул беләдер,
Ул белгәнгә көләдер.
Пышылдый җил искәндә,
Рәхәт безгә үскәндә.

Такмак әйтү:
Шүрәле, шүрәле,
Безнең янга кил әле!
Уртага чык та бие –
Килешеп тора көе.

## НИГӘ ОНЫТТЫҢ?

*Әхәт Гаффар* сүзләре һәм көе *Кирам Сатиев* эшкәртүендә






Ник оныттың, ник оныттың соң син
Ироннәрнең пышылдауларын?
Безне кочак җәеп каршы алган
Арышларның кыштырдауларын.
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Чеме белән җиләк җыйганны?
Ак кар яткан яфрак астында
Соңгы чикләвекне җуйганны.
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Каен себеркесе исләрен?
Нигә соң мин, нигә соң мин ялгыз
Мәтрүшкәләр исен иснәдем?!
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Безнең тургай булган чакларны?
Без түгелме кыңгыраулар итеп
Чыңлатканнар иртән чыкларны?
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Ташуларны ерып барганны?
Сизденме бер авыр булган чакта
Егылганны, хәлсез арганны.
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Баланнарның кызыл тамчысын?
Мөлдерәмә пешкән чияләрнең
Күз яшедәй татлы ачысын.
Ник оныттың, ник оныттың соң син
Яшьлекләрнең кире кайтасын?
Соң мәртәбә таңнар атканда
Кайда идең, кайда идең соң?!
Ник оныттың, ник оныттың соң син?!

# СИН ГЕНӘ

*Зәки Нури* сүзләре — *Кирам Сатиев* көе




Күңелем тәрәзәсен мин
Ачып куйдым киң итеп.
Кил син җил булып исеп кер,
Якын итеп, тиң итеп.

К у ш ы м т а :
Тәрәзәм төбе гөл генә,
Ул ерактан күренә.
Там яңгыр булып килеп, там
Гөлле күңел түремә.

Сине сагыну хисләрем
Тулып ташып түгелә.
Тургайлар булып очып мен
Якты күңел күгемә.

К у ш ы м т а .

Юлыңа гөлләр сибәрмен,
Кил генә син, кил генә.
Кояшым итеп көткәнем
Син генә бит, син генә!

К у ш ы м т а .

# ҖЫРЛАР ӨЙРӘН КУШ КАЕННАН

*Госман Садә* сүзләре

*Кирам Сатиев* көе




Кара кашлы карурманны
Моң чорнаган, моң чорнаган.
Алка-алка кар коела
Күк чормадан, күк чормадан.

Ак манзара һәр тарафта –
Акланнарда, акланнарда.
Куш каеннар канат җәеп
Үсә анда, үсә анда.

Куш каеннар... Гүя кызлар –
Игезәкләр, игезәкләр.
Урман җанын мәңге алар
Мәңге бизәр, моңга бизәр.

Ак моң ага кышкы урман
Кочагыннан, кочагыннан.
Кер урманга, өйрән җырлар
Куш каеннан, куш каеннан.

# ЙОКЫ

*Ренат Харис* сүзләре *Кирам Сатиев* көе




Йокы керде күземә,
Тынгы бирми үземә –
Ачтыра да яптыра,
Тик утырам аптырап.

Аннан керде авызга –
Кара син бу явызга:
Ачтыра да яптыра,
Һава гына каптыра.

Тагын бер тапкыр кергәч,
Мин йокыны алдадым –
Авызымын яптым да
Кирегә чыгармадым.

Бигрәк дөрес иткәнмен,
Йоклаганмын-киткәнмен...

# КИЛДУРАЗЫМ

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре *Кирам Сатиев* көе

**Күңелле, уртача тизлектә**



Килдураз авылы кайда? –
Зөя буе тугайда.
«Килдураз туган җирем» дип
Сайрый анда тургай да.

К у ш ы м т а :
Кайтсын сиңа, адашмасын,
Кошларың, Килдуразым!..
«Килдураз! Килдураз!» диеп
Кычкырадыр кыр казың.

Кайтмады тик кыр казлары,
Ямансу килде бу яз...
Яудан кайтмаган улларын
Һаман көтә Килдураз.

К у ш ы м т а .

Иделләргә аксын Зөя,
Сулары саекмасын.
Сулары саекты дип,
Килдураз боекмасын.

К у ш ы м т а .

Көтәсең микән мине дә,
Кайтам сиңа, Килдураз.
Исән-саулар
кайтмый калмас –
Килдуразга килде яз!..

К у ш ы м т а .

## СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ

*Ринат Нуруллин* сүзләре *Кирам Сатиев* көе



Көз яшьләрен түкте көн саен,
Аның яшьләрендә коендым.
Йокыга талдың син, ак каен,
Мин яфрагың булып коелдым.

К у ш ы м т а :
Гомерем буе сине эзләдем,
Нигә башкага карый
күзләрең?

Син җил булдың, карлар өерттең,
Булдың кышның әче салкыны.
Синең өчен саклап йөрттем
Йөрәктәге сүнмәс ялкынны.

К у ш ы м т а :
Гомерем буе сине эзләдем,
Башка юлларга илтә эзләрең.

Йөрәк әрни, күңел сызлана,
Очрашмабыз микән яңадан?
Мин судагы балык булганда,
Син кош булып очтың һавада.

К у ш ы м т а :
Гомерем буе сине эзләдем,
Нигә башкага карый күзләрең?

## ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРӘСЕҢ

*Фәнис Яруллин* сүзләре *Кирам Сатиев* көе






Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда чәчәкләр бәйләме.
Каядыр ашыккан җиреңнән
Карыйсың әйләнеп-әйләнеп.

Карыйсың, кулларың изисең,
Юлларга чәчәкләр коела.
Йөзеңдә ниндидер үпкәләү
Һәм сагыш бар сыман тоела.

Нәрсәдер әйтәсең каерылып,
Тик җилләр өзгәли сүзеңне.
Юлларга коелган чәчәкләр
Үбәләр җирдәге эзеңне.

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда яшьлекнең гөлләре.
Гөлеңне йолкыйлар кулыңнан
Тормышның аяусыз җилләре...

## КЕЧЕ ЧЫНЛЫ, ЯРАТУЫҢ ЧЫНМЫ?

*Кирам Сатиев* сүзләре һәм көе

**Ашыкмыйча, хис белән**















Кем сокланмас мондый табигатькә,
Җәйрәп яткан басу-кырларга.
Туган авылым Кече Чынлы дәшә,
Тургайлары кушыла җырларга.

К у ш ы м т а :
Ашкынып, сагынып кайтам.
Авылым Кече Чынлы,
Яшермичә әйт дөресен,
Яшермичә әйт дөресен
Яратуларың чынмы?
} 2 тапкыр

Асфальт юллар, заманча таш күпер,
Яңа мәчет – изге зур бина.
Гөрләп тора мәдәният йорты,
Туган авылым, бүләк ул сиңа.

К у ш ы м т а .

Күңелләргә бәхет, нур өстәлде,
Һәрбер өйдә зәңгәр ягулык.
Бергә-бергә тату гаилә булып
Яшик әле, дуслар, сау булыйк!

К у ш ы м т а .

# ХИМБАТ ТАҢНАРЫ

*(Вальс)*

*Кирам Сатиев* сүзләре һәм көе




Оныталмам: кар, буранда,
Җилләрдә, томанда, яңгырларда,
Автоматны иңгә асып
Өзелеп сагынганда...

К у ш ы м т а :
Ике ел үтте үтүен...
Ләкин калдырды ярасын
Чәнечкеле чыбык арасы.

«Отбой», «подъем»
һәм нарядлар,
Противогаз кию таң атканда,
Марш-бросоклар булмас инде
Төшләр күреп ятканда.

К у ш ы м т а .

Шинель кырмас муенымны,
Киң каеш бумас инде билне.
Ял ит, солдат, арыгансыңдыр,
Саклadың Туган илне.

К у ш ы м т а .

Мәңге китәм... Чәнечкеле
Чыбык арасында таң атмасын!
Башка кермәм, аяк басмам
Бу химбатның капкасын.

К у ш ы м т а :
Ике ел үтте үтүен...
Ләкин калдырды ярасын
Чәнечкеле чыбык арасы.

# АКБАШ ТУГАЙЛАРЫ

*Урал Уралов* сүзләре *Кирам Сатиев* көе




Әдел тавы мине озатып калды
Яшьлегемнең моңлы таңында.
Кемнәр сагыныш каршы алыр икән
Авылыма кайткан чагында?

К у ш ы м т а:
Акбаш тугайлары бигрәк ямьле,
Баланнары чәчәк атканда.
Нигә шулай уйландыра икән
Шул тугайга кире кайтканда?

Димескәйнең матур
ярларында
Югалмаган яшьлек эзләре.
Ерактан ук мине каршы ала
Әниемнең моңлы күзләре.

Кушымта.

Яшьлегемә кайткан кебек
булдым,
Гомер көзем килеп җитсә дә.
Авылымны ташлап китмәм
инде,
Нинди җилләр чакырып
иссә дә...

Кушымта.

## ИЛСӨЯР

*Олег Вәлиев* сүзләре *Кирам Сатиев* көе




Төнбоеклар үскән күл буена
Ник килмисең бүген, Илсөяр?
Әгәр йөгереп килсәң,
«Сөям, бәгърем» дисәң,
Төнбоеклар сиңа баш ияр.

Сандугачлар
сайрамыйлар бүген,
Сине көтә алар, Илсөяр.
Әгәр йөгереп килсәң,
«Сөям, бәгърем» дисәң,
Сандугачлар җыр бүләк итәр.

Яннарыма әгәр син килсәң,
Иңнәреңнән назлап җил сөяр.
Бик сагыныш көтәм,
Килче, кил син, иркәм,
Аңла йөрәгемне, Илсөяр...

## СӨЮЕМ ХАКЫНА

*Равилә Мөбарәкшина* сүзләре *Кирам Сатиев* көе




Яшьлегем гөрләгән,
Күңелләр дөрләгән
Бер таңда килдем мин Иделгә.
Килдем дә Иделгә,
Сикерим дидем дә
Сикердем дулкыннар иркенә.

Сулар диң, утларга
Төшкәнмен ул таңда –
Янсын ла, көйсен лә, сөйсен лә.
Йә үзең тартып ал,
Бер сөю татып кал,
Бу язлар янсын ла, көйсен лә.

Дәрьялар ярамын,
Мин сиңа барамын,
Мин киләм ашкына-ашкына.
Юлларым яз гына,
Карачы аз гына,
Өзелеп сөюем хакына.

## КИТЕП БАРДЫҢ

*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре | *Кирам Сатиев* көе




Күңелемдә гөрләп гөлләр үсә!
Син аларны никтер күрмәдең.
Китеп бардың,
Хәтта хушлашмадың –
Җилфердәде җилдә күлмәгең.

Китеп бардың...
Ә мин карап калдым,
Югалганчы күздән күлмәгең...
Алан шаһит:
Кайнар яшем белән
Яфракларын юдым үләннең.

# ГОМЕР ҮТӘ ИКӘН
# УЙ УЙЛАП

## АФОРИЗМНАР

* Уйнаганда уйлау кирәк; уйлаганда уйнау кирәк микән?

* Буш амбарга тычкан керми.

* Биргәнгә бирәләр; бирмәгәнгә дә бирәләр, һәм киресенчә. Кемгә, күпме, нәрсәне – анысы башка мәсьәлә.

* Югары уку йортыннан түбән белем алып чыкты.

* Әгәр кеше этне өзелеп ярата икән, димәк, анда кешелек сыйфатлары түгел, ә этлек сыйфатлары күбрәк.

* Май белән су кушылмый.

* Сөйрәлергә туган оча алмый. Очарга туган сөйрәлә ала.

* Татар булыр өчен, татар булудан котылырга кирәк.

* Һәр кешене туган җире тарта, диләр. Ир кешене туган җире күбрәк тарта, дисәк, дөресрәк булмас микән?

* Зурлар янында кечкенә булудан кечкенәләр янында зур булу хәерле.

* Дөрес юлга басты, ләкин кайсы якка барырга соң дип гомер буе уйлады...

* Бар акыллы (умный) кеше; бар зирәк (мудрый). Аерма нәрсәдә? Акыллы ясаган хатасын төзәтә белә, ә зирәк хата ясамый.

* Үзен яратмаган кеше башканы ярата алмый, диләр. Дөрес түгел. Үзен генә яраткан кеше башканы ярата алмый.

* Гомере кыска булды: теле озын иде.

* Йомыркадан җөй эзләмә.

* Тере балык кына агымга каршы йөзә.

* Бөркет берүзе оча, көчсез кошлар – төркеме белән.

* Тәхет, бәхет, ләхет... Бу сүзләрдә тирән мәгънә, шом һәм эзлеклелек бар кебек.

* Иң авыр таш – кабер ташы, иң авыр көрәк – зират көрәге. Ә иң авыр җәза – ялгызлык.

* Мәктәп: белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп.
Тормыш: ярату гөнаһ түгел, яратмау гөнаһ.

* Катнаш урман була, катнаш агач булмый.

* Сәхнә тулы йолдыз. Ә залда? (Кемнәр?)

* Татар телендәге өч хәрефле сүзләрнең берсе генә дә начар түгел. Мәсәлән: әти, әни, әби, бал, май, иш, тоз, кыз, бот, тот һ.б.лар.

* «Син кайдан?» дигән сорауга дөрес һәм төгәл җавап бирде: «Мин дә шуннан».

* Тумаган кеше үлми.

* Сарык тиресенә төренгән бүредән бүре тиресенә төренгән сарык куркынычракмы?.

* Ике хакыйкать: мәчетне яшен сукмый, бакага ревматизм булмый.

* Эшләмәгән тимер тутыга, ышкылмаган урынга йон үсә.

* Бака сайрый, диләр. Бака кычкыра, диләр. Икесе дә дөрес түгел. Бака бакылдый.

* Хәерчеләр дус була алмый.

* Дантес Пушкинны атып үтерде. Җиңде. Ләкин һәйкәлне җиңелүчегә – Пушкинга куйдылар.

* Мәктәп: дәрескә кергәндә кыңгырау шалтырый. «Соңга каласыз. Ярамый. Звонок сезнең өчен бирелә», – ди. Дәрестән чыкканда: «Утырыгыз, кыңгырау сезнең өчен түгел, укытучыга җыенырга бирелә», – ди. Укучы әйтә: «Кайсы дөрес?» – «Син күпне белергә телисең. Ерак китәрсең, туктатмасалар», – ди укытучы.

*Тирән елга тын ага...

* Сөтне сыер бирә, ә орденны колхоз рәисенә тагалар.

* Хакыйкать дөреслектән аерыламы? Аерыла. Хакыйкать (истина) – мәңгелек. Дөреслек (правда) бүген дөрес, иртәгә дөрес түгел. Шуның өчен урыслар: «Истина дороже», – диләр.

* Армиядән кайткач, миңа колхоз рәисе: «Синең үз фикерең бар, яшәү авыр булачак», – дигән иде... Ул хаклы булган!

* Күзәтү нәтиҗәсе: артист була алмаган кеше режиссер була да артистларны өйрәтә башлый, режиссер була алмаса, депутат була; депутат була алмаса, милициягә эшкә килә. Куылгач, авылга китеп колхоз рәисе була. Булдыра алмаса, шәһәргә кире килеп, зиратка кабер казучы булып эшкә керә. Һәм бер кабер казый... Үзе өчен...

* Бервакытта да циркта бүре күрмәссең. Ул дрессировкага бирелми. Сарык та юк, чөнки нык аңгыра, аңлатканны аңламый.

* Закон бозар өчен языла. Булмаган законны бозып булмый. Аны йә бозалар, йә урап узалар. Башка юл юк.

* Төрмә – акыллыны түрәдән аерып торучы дивар (стена).

* Син ялгышма, ныклап кара: күлмәге ак, йөзе кара...

* Көтүче бозау булса, бүре дә тук, сарыклар да исән була.

* Елан кабыгын алыштыра, ләкин елан булудан туктамый.

* Бүре ачтан үлсә үлә, ләкин кибәндәге печәнне ашамый.

* Баланы хатын-кыз дөньяга тудыра, ләкин ул атасының исеме белән йөри.

* Талантлы кешенең дуслары булмый.

* Хатын-кызны өч нәрсә бетерә: исерек ир, елак бала, чи утын.

* Моңлы булуның сәбәбе ике: матур табигать һәм хәерчелек.

* Җиңел җиңүләр булмый (легких побед не бывает).

* Вөҗданлы кеше ота алмый (честный не выигрывает).

* Тормыш бит ул: баш идерә үзеңнән түбәннәргә.

* Ир-ат: өйләнде, ялгыз яшәде. Тәне ятты, күңеле ятмады.

Хатын-кыз (киресенчә): кияүгә чыкты. Башка ир белән яшәде.

* Тимергә тимер белән сугарга кирәк.

* Ялгыз агачны яшен суга.

* Дөньяда иң зур ачыш ясаучы – Тәгәрмәч уйлап тапкан кеше. Фикер йөртеп карагыз: бүгенге көндә Тәгәрмәч булмаса, Кешелек Дөньясы ни эшләр иде микән? Ә иң надан кеше – уңны һәм сулны бутаучы. (Шулар аркасында күпме кеше юлда үлә...)

* Тамчы ташны тишә. Көчле тамуы белән түгел, еш тамуы белән.

* Россияне таркалудан ике әйбер тотып тора: 1) татарның куркып, ялагайланып, җиң сызганып урыска хезмәт итүе; 2) еврейларның урыс булып кылануы.

* Гомер озынлыгы өч төрле була: 1) яратмаган кеше озак яши; 2) яраткан кеше яраткан кешесен тапса, озак яши; 3) яраткан кеше яратканын таба алмаса, озак яшәми. (Яшәсә дә, яшәве җан саклау гына була.)

* Кем белә – шул эшли. Кем белми – шул өйрәтә. Кем өйрәтә белми – шул җитәкли.

* Дөреслек (күпчелек) өч җирдә җиңә: әкияттә, төштә һәм кинода.

* Тормыш тәҗрибәсе. Хатын-кызга дошман буласың килмәсә, өч әйберне эшләмә: картайгансың димә, акча сорама һәм баласын әрләмә (ачуланма).

* Кеше баласын ташлый, хайван ташламый. Нәтиҗә: хайван кебек кешелекле хайван юк яки хайван кешедән кешелеклерәк.

* Күп сөйләде, ләкин бернәрсә дә әйтмәде.

* Кешелеклелек: күргәне – күрмәде, күрмәгәне – күрде.

* Кеше хайваннан үз фикерен әйтә алуы белән аерыла.

* Ашыктыру ашыктыручы файдасына төгәлләнә.

* «Тавык алданрак барлыкка килгәнме, әллә йомыркамы?» дигән сорауга әле беркемнең дә төгәл җавап бирә алганы юк.

* Гаҗәп, ләкин факт: рульне уңга борсаң, машина алга барганда да, артка барганда да уңга таба борыла.

* Сынамыш: артист фатирга кергәндә ишегалдында эт өреп тормаса, өендә гармун булса, димәк, син яхшы хуҗаларга эләктең.

* Елан чакса, табиб коткара ала, хатын чакса – үләсең.

* Елан җылы урында яши.

* Үгезне – сөзәргә, балыкны – йөзәргә, Илһамны – җырларга, Кирамны уйнарга өйрәтмиләр.

* Ике кул белән (бияләйне салып) күрешүнең мәгънәсе – кулымда салкын корал юк дигәнне аңлата. Баш киемен салу да шуннан алынган булса кирәк.

* Чәкештереп эчү: ул миңа агу салган булса, чәкештергәч, минем чәркәдәге агу аңа күчә, һәм ул да агуланып үлә. (Элек, талон системасы булмаганда, хәмер-виноны тутырып салып эчкәннәр.)

* Аллаһы Тәгалә мөселманнарга (мөселман илләренә) нефть (кара алтын) биргән. Татарстанда бар, Марида юк; Башкортстанда бар, Удмуртта юк; Кавказ – Әрмәнстан, Грузиядә юк (алар тәреле); ә Азәрбайҗанда нефть бар, Чечняда бар, Кувейтта бар, Израильдә (җәбрәй илендә) юк. Исемлекне тагын дәвам итәргә була...

* Катнаш никахка мөнәсәбәтем: бу никахтан бала татар булмый. Катнаш никах татарны бетерер өчен эшләнә. Урыстан – Иван (Имам түгел), үзбәктән үзбәк туа... Бер акыллыбаш миңа, катнаш урман була бит, диде. Катнаш урман була, катнаш агач булмый. Асты имән, өсте чыршы булган агачны кайсыгызның күргәне бар? Кыскасы, май белән су кушылмый. II һәм III группа каннар да шулай.

* «Нәрсә ул бәхет?» дигән сорауга минем җавабым: теләгеңә ирешү.

* Бай ярлыга бармый, ярлы байга килә. Әңгәмә беткәч, бай ярлыны озата чыга: ихтирам йөзеннән түгел, ә әйбер урламасын дип күзәтчелек итә һәм, ярлы чыккач, бай, капканы ябып, кире кереп китә.

* «Укырга, укырга һәм укырга...» сүзләрен өч тапкыр язганчы, «аңлап, яратып укырга...» дисәң, хәерлерәк булмас иде микән?

* Күп ялган сөйләр өчен дөреслекне күп белергә кирәк. (Һәрвакыт уңышлы ялганнар өчен беркемнең дә хәтере җитми.)

* Иң кешелексез кеше – атасын, анасын үтергәч, «мине кызганыгыз, мин ятим бит» диюче.

* Ике упкынны бер сикерүдә чыгып була, ә бер упкынны ике сикерүдә чыгып булмый.

* Кешелек сугышны туктатмаса, сугыш кешелекне туктатачак.

* Мин аз сөйләшәм: надан икәнемне белми калалар.

* Даһи булырга өйрәнеп тә, өйрәтеп тә булмый.

* «Дөньяның чиге бармы?» дигән сорауга җавап эзләү – иң куркыныч нәрсә.

* Көндез күңелдә йөргән, төнлә төшендә күргән.

* Кайгыны кайгы белән төзәтмә.

* Ирек бирүчеләр күбәйгән саен, ирektә йөрүчеләр азая.

* Хакыйкатьне табуга караганда хатаны табу җиңелрәк.

* Хәерчеләр дус була алмый; бай белән хәерче – хәерче белән бай да шулай ук. Ә бай белән бай дус була яки дус булып кылана ала.

* Кеше булмаган урында да кеше булырга кирәк.

* Буш йөзле тамашачыларга караганда буш урындыкларга карап уйнау хәерле.

* Ютәл буа башлагач, бик әзе – табибка, ә күпчелек театрга бара.

* Чөйне чөй белән бәреп чыгаралар; көчле чирне – көчле дару белән.

* Концертка тамашачы күп йөргәндә, җырчы, күкрәк сугып: «Мине яраталар», – ди. Халык җыелмаса, администратор гаепле: «Ул оештырмаган», – дип оран сала.

* Зирәк кеше һәрнәрсәгә гаҗәпләнә.

* Акыллы өйрәнә, җүләр өйрәтә.

* Бөекләр өч төрле була: беренчеләре бөек булып туалар, икенчеләре бөеклекне яулап алалар, өченчеләргә бөеклекне көчләп тагалар.

* Үзең курыккан кешене һәм синнән курыккан кешене яратырга кирәкми!

* Көлми торган кешеләр өч төргә бүленәләр: явыз, хәерче һәм битараф.

* Талантны – Ходай Тәгалә, ә калганын Алтын балык бирә.

* Канәгать калган кеше оныта, рәнҗетелгәне хәтерли.

∗ Коллыкны кимсетү дип кабул итмәгән халык кол булыр өчен яралган.

∗ Буйсындыра алмасаң, хатын-кыз җиңә, буйсынса, җиңүчегә үзенең шартларын куя башлый.

∗ Егет чакта кыз биеде, тынмады гармун чыңы,
Өйләнешкәч, биюче кыз биетә гармунчыны!

∗ Дуслык һәм тигезлек арасына һич икеләнмичә = (тигезлек билгесе) куяр идем.

∗ Күпләр ашаганда түгел, ә эчкәндә чама хисен югалта.

∗ Иң җиңеле – үз-үзеңне алдау, иң авыры – үз-үзеңнән качу.

∗ Дошманыма әйттем: «Мин үлгәч, каберемә чәчәк китер, үз гомереңдә бердәнбер яхшылыгың булыр». Ул кырт кисте: «Юк, китермим». «Алайса, мин синекенә китерермен», – дидем.

∗ Иң зур җинаять – китапларны яндыру, ә аннан да зуррагы – китапларны укымау.

∗ Күп вакыт аңлатулар акланулардан тора.

∗ Кешеләрнең яртысы төрмәдә утыра, ә икенче яртысы төрмәдә урын бушаганны көтеп тора.

∗ Ир кеше хакимлек итәргә, ә хатын-кыз буйсындырырга тели.

∗ Ике әйберне сатып алып булмый: сәламәтлекне һәм бәхетне.

∗ Дуслары күп булган кешенең дуслары булмый.

∗ «Үзең юкта сине бик каты сүгәләр», – дигәч, «Кыйнасалар да риза», – дип җавап биргән бер акыл иясе.

∗ Барлык җан ияләреннән кеше генә көлә белә. Ә ат? Ат көлми, ат ыржая (кешни).

∗ Секс – яхшы тегелгән костюм кебек: үлчәмнәре тәңгәл килсә генә әйбәт нәтиҗә бирә.

∗ Төшемдә хезмәт хакым турында Аллаһы Тәгаләгә сөйләдем. Ул башта шаркылдап көлде, аннары үксеп елады.

∗ Бәхет артыннан кумасалар, нинди мөлаем булырлар иде хатын-кызлар!

∗ «Чибәр хатын-кызлар серле һәм мәкерле булалар», – дигән бер акыл иясе. Икенчесе: «Салкын һәм ахмак», – дигән. Кайсы күбрәк хаклы?

∗ Кояшка якынаям, җылынам дип, тау башына менәм. Ә анда... салкын...

∗ Иблисне алдау гөнаһ түгел.

∗ Байлыгы зурайганга карап кешенең намусы артмый.

∗ Иң кыйммәткә төшкән әйбер – ирешелмәгән бәхет...

* Ир кешене хатын-кыз зур эшләргә рухландыра һәм аларны тормышка ашырганда комачаулык ясый.

* Бәхәстә җиңүнең бер генә ысулы бар: ул – бәхәскә кермәү.

* Буш вакыты күп булган кеше, гадәттә, буш вакыты булмаган кеше янында, буш сүз сөйләп, буш вакытын уздыра.

* Тарих бернәрсәгә дә өйрәтми: ул бары тик тарих дәресләрен белмәгәнгә җәзасын бирә.

* Гел җүләрләр арасында йөреп, акыллыланып бетте.

* Яшь чакта аларны идән берләштерде, картайгач – түшәм.

* Шаккаткыч нәрсә: арзан музыканың көче нинди мул!

* Бурычка акча сораучыга йөрәгемне тәкъдим итәм.

* Туй маршлары, хәрби маршлар кебек үк, көрәшкә чакыра.

* Тормыш тәҗрибәсе: бай кеше уңышка ышанмый.

* «Әче!» («горько!») дип кычкыруның мәгънәсе: элек яшь-яшь кызларны өлкән яшьтәге байларга димләп (ярату буенча түгел) кияүгә биргәннәр. Күз яшен агызуын тыя алмаган киленнең хәлен аңлап, туйдагылар «горько!» дип кычкырганнар. Кыз кызып китеп, үзен-үзе белештермичә нәрсәдер әйтеп ташлавын сизенеп, кияү аның авызын тупас төстә кул белән түгел, ә авызы белән, иреннәре белән каплаган... Бу гореф-гадәт шул дәверләрдән безгә кадәр килгән...

* Хатын-кыз – мәхәббәтнең мәгънәсен, ә ир кеше бәясен белә.

* Аккош кызыл булмый.

* Гаепleләр булмаса, аларны билгелиләр.

* Бер рус әйтте: «Я не пью, и жена в рот не берет».

* Ялган юлда (юнәлештә) дөрес адым.

* Нәрсәдер белер өчен аңа кадәр нәрсәдер белергә кирәк.

* Профессор студентларга: «Беркем укымый, укыса – аңламый, аңласа – оныта», – дип әйтергә ярата.

* Әгәр берәү, зурдан кубып, мин фәлән-төгәнне беләм, без бергә аның белән... дип сүз башласа, аны тыңламау хәерле, чөнки ул юк кеше.

* Кайберәүләрне гомер буе алдап була, күпмедер вакыт барысын да алдарга була, ләкин барысын да гомер буе алдап булмый.

* Өч мал: берсе кәҗә тәкәсен сава, өченчесе иләк тотып тора.

* Бөтен бәла дә шунда: һәр көн диярлек «бөтен бәла дә шунда» сүзләре белән башлана.

* Мине, үлгәч, тәмугка кертегез. Шунда, рәхәтләнеп, гөнаһлы байларның, түрәләрнең, безне кол итүчеләрнең тәмугта януларын күрәсем килә.

* Минем хәтерем начар, шулай да нәрсәне онытырга кирәген яхшы истә тотам.

* Без тезләнеп торган өчен генә алар бөек (биек) күренә.

* Сугыш башлангач түгел, башланганчы уйларга кирәк.

* Син көн саен эшкә барасың. Ә кайчан акча эшлисең? Эшкә бармаган, ягъни ял көннәрендә.

* Ялгызлык – начар; өйләнү – үзеңне (күпмедер дәрәҗәдә) коллыкка кертү. Кайсы начар? Икесе дә.

* Олыгайган саен, җил көчлерәк була һәм ул гел каршыга исә...

* Җәзалау, җәза борынгыдан килгән (калган), үз-үзен аклаучы тәрбия чараларының бер ысулы. Балалар бакчаларында, мәктәптә – почмакка бастыру, мәдрәсәдә – аркага сыек чыбык, армиядә – гауптвахта, гражданкада – төрмәгә утырту.

## ФОНОГРАММА ҺӘМ ЗАМАН

Соңгы елларда сәнгать өлкәсендә фонограмма турында күп сөйлиләр: кемдер уңай фикер әйтә, ә кайсылары кирегә сукалый.

Башта фонограмманың үзе белән якыннанрак танышыйк әле. Кем ул? Нәрсә ул? Үзен генә ашыйлармы аның, әллә ипигә ягыпмы? Стаканга салыпмы? Кибеттән алыпмы?

Телефон, саксофон, микрофон... Һәр өч сүздә дә «фон» катнаша. Фон – тавыш, аваз дигән сүз. Ә «грамма» язуны аңлата. Мәктәп елларын искә төшерик: грамматика – матур һәм дөрес язу фәне бар иде. Кыскасы, фонограмма – «фон» – тавыш, «грамма» – язу, ягъни тавыш язу дигән сүз. Бераз читкәрәк тайпылып, шунысын да әйтеп узыйм: телефон, телеграмма, телефонограмма сүзләрендә өч «тел» сүзе бар. Татар сүзе, безнең сүз. Тел белән әйтелгәннең (телефонограмманы күздә тотып әйтүем) тавышын язып кую. Телеграмма да шулай бит: язылган текстны тел белән әйтеп (телефон аша), кәгазьгә язып (грамма), почтальон адресатка шул кәгазьне илтеп, кулына тапшыра.

Фонограммага кире әйләнеп кайтыйк. Ул кирәк диючеләр бар, кирәкми диючеләр күп. Аны бетерергә, туктатырга... кебек фикерләр дә шактый. Кемдер әле аны сәнгатькә зур зыян китерә дип фаразлый. Ә чынлыкта ничек? Хакыйкать нәрсә ди? Бер фонограмма турында мең сорау бирергә була. Ә мең сорауга бер сүз белән җавап бирәм: акча! Фонограмманың килеп чыгуы турыдан-туры акчага бәйле! Әйтик, Казанда җыр конкурсы уздырыла. Ә менә ерак Себердән килгән конкурсант 50–60 кешелек

оркестрны алып килә алмый. Сәбәбе – акча юк! (Акча бар ул, ләкин сәнгать өчен түгел.) Нишләргә кала? Оркестрның уйнавын ул («фон»ын, тавышын) магнит тасмасына язып ала да Казанга жюрига җибәрә. Ә җырчы, үз чиратында, конкурска килгәч, шул аккомпанементка кушылып җырлый. Менә бу инде «минус» дип атала. Ә инде аккомпанемент та, солистның тавышы да бергә язылган очракта «плюс» була. «Плюс» стадионда, спорт сарайларында, йә булмаса ачык һавада (мәсәлән, сабан туйларында) чыгыш ясаганда кулай. Чөнки ике тавышның көчлелеген, балансын тигезләп торасы булмый.

Фонограммага кушылып җырлауны кайбер тамашачылар өнәп бетерми. Араларында хәтта үпкәләүчеләр дә бар. Моңа бераз ачыклык кертеп узыйк: әгәр дә мин үз язмама (фонограммага) үзем кушылып уйныйм, җырлыйм икән, туры китерә алам икән, бу начар күренеш түгел. Ул бит минем хезмәтем! Түккән тирем, йокысыз төнем, эштә үткән көнем. Ә инде кеше язмасына авызымны ачып, сәхнәдә басып торып, аның «эш агачы биргән җимешен» кесәмә салып йөрим икән, бу инде зур гөнаһ һәм олы хата булыр иде.

«Фонограмма зыянлымы» дигән сорауга җавабым мондый: гел «авыз ачып» кына «җырлап» йөрсәң, тавыш утыра, диапазон кечерәя, тавышның көче кимегәннән-кими бара.

Күптән түгел мине матбугат бәйрәме уңаеннан газета хезмәткәрләре кунакка чакырды. Бардым. Бик теләп бардым. Уйнадык, биедек, җырладык, күңел ачтык... Ике җырчы чакырганнар иде. Егет җырчының тавышы гөрләп тора. Ә менә кыз җырчы, гел фонограммага авызын ачып торып, бөтенләй тавышсыз калган. Янымда басып җырлап тора, мин аны ишетмим. Инде баянның тавышын бөтенләй (мөмкин кадәр!) киметтем. Барыбер баянны гына ишетәм. Юк, колагыма аю баскан өчен түгел. «Сеңлем, – мин әйтәм, – син үзең өчен генә җырлама. Мәҗлес булса да, бу – концерт. Сәхнә. Синең тавышың үзеңә, миңа гына түгел, 5,12,17 нче рәткә дә ишетелсен», – дим. 2–3 җыр җырлады да (мырлады дисәк дөресрәк булыр) тагын каядыр җырларга – үзен һәм тамашачыны газапларга ашыгып китеп барган булды... Менә сиңа фонограмма!.. Әгәр дә спортчы көн саен шөгыльләнмәсә, күнегүләр ясамаса, ул спортчы булудан туктый (ышкылмаган урында йон үсә, эш кылмаган тимер тутыга...), аны җиңелүләр көтә... Сәнгатьтә дә нәкъ шулай. Әйтик, берничә көн баянда уйнамасаң, бармаклар ката, диләр. Юк, бармак бармак инде ул. Бармак катмый. Зиһен җыю, фикер туплау, уйның йөгереклеге, сәләте кими.

Әйткәнемчә, фонограмманың барлыкка килүе акчага бәйле. XX гасырның 70–80 нче елларында Татарстан сәнгать осталары иҗат-хисап концертлары белән Мәскәүгә еш баралар иде. Монда Татарстан дәүләт симфоник оркестры, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, дистәләгән солистлар, алып баручылар, оригиналь жанр... Һәм һәрбер концерт куючы үз ансамблен, үз баянчысын ала иде. Бүгенгедәй хәтеремдә: без өчәр баянчы – Рәшит Мостафин, Рамил Курамшин һәм мин – сәхнәгә бергә чыгыш уйный идек. Чөнки акча бар иде. Ә кая соң хәзер ул акчалар? Математикада «кире пропорциональ» дигән төшенчә бар: берсе зурайганда, икенчесе шулкадәр үк кечерәя. Моның белән шуны әйтмәкче булам: музыкант-башкаручыларны әзрәк алсаң, акча күбрәк була һәм киресенчә. Юк, булмый ул алай. Һәркем, һәрнәрсә үз урынында. Оркестрны бернәрсә белән дә алыштырып булмый. Бу «тере организм»ны акча ишәйтү уе белән синтезатор һәм баянга алмаштыру – зур гөнаһ һәм олы хата, сәнгатьне артка сөйрәү; оркестрны уйлап тапкан һәм аны бар иткән акыл ияләреннән көлү, аларны мыскыл итү. Катырак кагылган, тупасрак әйткән булсам, гафу итегез. Ләкин бу шулай. Моның белән күпләр килешер дип уйлыйм. Алдарак Себердән конкурска бер башкаручы килүе турында язган идем... Бар шундый әсәрләр – алар яки оркестр, яки фортепиано аккомпанементы белән генә үзенең дөрес, тиешле һәм лаеклы яңгырашын таба. Сүз классик композиторларыбызның иҗат җимешләре турында бара. Ә инде халык көйләрен баян-гармун аккомпанементында башкару отышлырак булыр.

Әлбәттә, һәркемнең, һәрнәрсәнең, һәр әсәрнең үз урыны. Фонограмманы гел хурлау һәм, киресенчә, гел зурлау гына да дөрес булмас иде. Бу – заман таләбе. Берәү дә аны кемгәдер яхшы яки начар булсын өчен уйлап чыгармаган. Әгәр дә фонограмма сәнгатькә зыян гына китерсә, аны җитәкчеләр күптән тыяр, туктатыр иде. Тыймыйлар, димәк, шулай кирәк. Кайчан да булса өстәгеләр ниндидер указ, приказ яисә карар чыгарса – анысы инде икенче мәсьәлә. Алга таба күз күрер. Һәрнәрсәнең уңай һәм тискәре ягы була. Бизмәнгә салып үлчәсәң, кайсы ягы күбрәк тартыр – әйтүе авыр. Савытына күрә капкачы, диләр. Монда да шулай: заманы нинди, таләбе дә шундый. Үз тавышлары белән җырлый торган артистларыбыз санаулы гына калды. Исемнәрен атап тормыйм. Алар үзләре белә. Мин дә аларны беләм. Фонограмма җырчылары да миңа үпкәләмәсен. Кыскасы, кемнедер, кемнәрнедер үпкәләтмичә-рәнҗетмичә генә «Нәрсә ул фонограмма?» дигән

четерекле сорауга биргән җавабым хөрмәтле укучыларымны канәгатьләндерсә, мин бик шат булыр идем.

Күңелем сизә, «Авторның фонограммага шәхсән мөнәсәбәте нинди соң?» диярләр. Кистереп җавап бирәм – тискәре. Сәхнәне күз алдына китерегез. Концерт бара. Бастырып куялар. Кыска кереш музыка (проигрыш) дип уйныйсың, ул озын була һәм... киресенчә. Еш кына туры да килми. Газапланып басып торасың. Ә менә үзең уйнаганда, курыкмыйча, гарьләнмичә, хурланмыйча хезмәтеңне башкарасың. Эшләп ашыйсың. Җыр, моң, сәнгать. Тамашачының рәхмәте, ихтирамы. Чәчәкләр, алкышлар. Әле рухи ләззәт дигән төшенчә дә бар бит. Куян кебек куркып, алга китмәсәм ярар иде, артта калмасам ярар иде дигән газаплы уй белән җәфа чигеп басып торуы бик тә кыен нәрсә ул. Иң олы җырчыларга рәттән сәгать ярым, икешәр сәгать уйныйм, ләкин мескен булып «под фанеру» басып тормыйм. Тормыш бит ул катлаулы – басып торырга да туры килә...

Биючегә, сөйләүчегә, фокусчыга, оригиналь жанр остасына... фонограмма юк. Алар – «живьем»! Җырчыга бар. Ә баянчыга... барыбер. Ул шулай ук баян күтәреп, басып, уйнап, тартып тора. Бөтен серләрне, барлык карталарны ачып салу, бәлки, кирәк тә түгелдер. Ләкин, нишлисең, шуннан да кимрәк язсам, фонограмманың чын йөзе ачылмас иде дигән фикердә калам...

*«Мәдәни җомга», 2006, 23 июнь*

## 13 САНЫ ИНСАНЫ

Бүген айның 13 нче көне. Йокымнан сикереп торып, юынып-кырынып, кызыбызны 13 нче гимназиягә укырга озаттым. Хатынны уятып, аның җыенганын сәгать ярым чамасы көтеп, дога кылып, юлга чыктык. Ул эшкә бара, ә мин – уйнарга: Көнбатыш Себердәге бер шәһәр юбилеена – гастрольгә. Такси көтеп торганда, 13 нче трамвай килеп җитте. Утырдык. Күпмедер барганнан соң, тукталышта төшеп калдык. Ул да булмады, бер танышым машинасы белән килеп туктады. Номеры 13 тә 13 иде. Ул безне театр бинасы каршына, Горький урамы, 13 нче йорт янына илтеп куйды. Үзем куркам, үзем йолкам дигәндәй, күңелем тыныч түгел. Сиздермәскә тырышам. Театр янында төялеп, аэропортка юнәлдек. Арадан бер артист «Мәдәни җомга» газетасын укып утыра.

Ни күрим: 13 октябрьдә басылган 13 нче сан. Иртәдән үк, мин әйтәм, гел 13 саны, нәрсә булды соң, нәрсә ярамады?

Ниһаять, 13 ендә басылган 13 нче санлы «Мәдәни җомга» минем дә кулга эләкте. Кызык өчен генә 13 нче биткә күз салдым. Касыйм ага Тәхауның шигырьләре белән танышып утырам. Юри генә саныйм: барысы 13 куплет!

Сургут шәһәре безне яхшы каршы алды. Алмаска соң, бүген бит 13 е! 13 ләр күренмәсен дип, автобуста күзләремне йомып утырам. Ачып җибәрсәм, «Столовая, ул.Магистральная, 13» дип язылган.

...Инде күңелемнән кунакханәнең дә 13 нче бүлмәсенә урнаштырырлар дип уйлап торам. Юк, булмады. Анда башка мосафирлар урнашкан икән инде. Ул бүлмәне даулап йөрмәдем. 13 санын яратучылар дөньяда мин һәм Каспаров кына түгелдер... Әнә аның бөтен язмышы 13 белән бәйләнгән.

Дөньяның 13 нче чемпионы да ул бит.

Әйе, кемгә ничек, 13 саны ул, кем әйтмешли, кешесенә карап туры килә. Йә уңасың, йә туңасың. Әнә бит патша Русиясенең 1913 елын әле хәзер дә сагынып искә алалар. Димәк, лаеклы ул аңа. Минем әткәм дә шул елны дөньяга килгән. Нәкъ 13 елдан соң әнкәм туган. Тукаебызның үлгән елы да 13 нче ел...

...Миңа, ятим балага, моңсу да, ямансу да булып китте. Күзләрем яшьләнде... Аларның якты истәлегенә, рухларына багышлап дога кылыр өчен, Сургут мәчетенә таба атладым... Менә шул, мин – 13 санының инсаны...

*«Мәдәни җомга», 1995, 10 ноябрь*

## АВЫЛ, МӘДӘНИЯТ, БЕЗ...

...Клубы юк. Ә нигә соң
Акча түли колхоз Солтанга?
Ник культура артта кала диеп
Бәйләнсәләр, кемгә сылтарга?..

Көлкеме? Көлке. Әйе, бу беренче карашка шулай. Ә ныклабрак, төптәнрәк уйласак? Бу – фаҗига...

Бер танышым сөйләп торды:

– Безнең авылдагы клубны бер түрә, сүттереп, утынга туратып, күрше авылга алып китте. Шуның белән вәссәлам. Яңасын салдырырга уйламый да, хәерсез.

Күрәсез, шигырь юллары белән дустым сөйләгәннәрдә уртаклык бар. Бар гына да түгел, һәр икесе бер үк нәрсә турында сөйли.

Байга авыл клубы, мәдәният учагы кирәкми. Таң атканнан кояш баеганга кадәр ул гел үзе, байлыгы турында гына уйлый, аның аңы акча белән томаланган. Менә шул культура сарайларының бөтенләй булмавы яки булып та халыкка тиешенчә хезмәт күрсәтмәве наркоманиягә, токсикоманиягә (авыл җирендә бит), эчкечелеккә этәрүче төп фактор булып әверелде. Күз алдына китерегез әле. Авыл. Ямь калмаган. Телиме- теләмиме, кеше шешәгә ябыша, үзенә ниндидер юану табарга тырыша. Ә бит алдарак искә алган мәдәният йортын шәхсән мин үзем яхшы хәтерлим: берничә ел элек шул бинада без, Казан артистлары, булачак депутатны яклап концертлар куйган идек. Хәзер ул клуб юк! «Җимергәнсең икән, яңасын сал! Булдыра алмыйсың икән, тотынма! Ярап тора иде бит әле ул...» – диярмен мин, юлларымда теге түрә очраса.

Соңгы вакытларда, ни кызганыч, авылларда сирәк булырга туры килә. Ә сәбәбе гап-гади: акча. Билет бәясен заманча куйсаң, тамашачы концертыңа килми, ә арзан итеп билет сатсаң, җыелган акча транспорт белән кунакханәгә дә җитми. Шулай итеп, тамашачы белән артист арасында «төртсәң дә аварга тора торган стена» түгел, ә бульдозер белән эттереп тә кузгата алмаслык калын һәм биек дивар барлыкка килә. Җимереп кара син аны! Ә төп сәбәбе болайрак. Казаннан ерак түгел бер районда мәдәният бүлеге мөдире белән озак кына фикер алышып утырдык. Мин аңа мондый сорау бирдем:

– Ни өчен авыл халкы концертка йөрми? Тамаша сыйфаты начармы? Әллә халыкта сәмән бөтенләй юкмы?

– Бу сорауның беренче өлеше дөрес, – диде мөдир. – Теләгән кеше яраткан артистын карарга анлык кына акча таба ул...

Бу – район мәдәниятен җитәкләүче фикере иде. Һәм ул хаклы дим мин. Чөнки үземнең дә яраткан артистларым бар. Шуларның берсе – Мәскәү артисты, юмор остасы Михаил Задорнов. Югары белемле музыкант, опера, симфонияләрне өйрәнгән, дөнья классикасын белә торган кеше буларак, минем өчен милли төсмер юк. Бар бер нәрсә: чын сәнгать һәм күз буяу (халтура), кеше көлдерәм дип көлкегә калу. Задорновның күзәтүчән һәм нәтиҗә чыгаручан булуын, тормышны бик белеп, аңлаган хәлдә аның кимчелекләреннән көлеп, аларны фаш итүнең чын остасы икәнлегенә сез дә игътибар итәсездер. Юморескаларымны урысчага тәрҗемә итеп, чәчәк тотып, сигез йөз сумга билет алып... бардым мин аның концертына. Кабат килсә, тагын барам әле, Алла боерса.

Инде хәзер, күктән җиргә төшеп, үземне мәңге борчыган әйберләр турында да языйм әле. Алар мине генә түгел, күпләрне хәвефкә саладыр. Кайсыдыр мәдәният йортына килеп керәсең. Сиңа кирәк өч әйбернең өчесе дә юк. Беренчесе – баян куярга урындык. Икенчесе – элгеч. Өченчесе – көзге. Ярар, көзгене кесәдә дә йөртеп була. (Өч мәсьәләнең берсе хәл ителде.) Урындык сорасаң, башны җүләргә салып, сорауга сорау белән җавап бирәләр. Ник кирәк сиңа урындык? Син барыбер басып уйныйсың ич! Нәрсә дисең инде җавап итеп мал хөкемендәге шушы бәндәгә? Соң, баян куймасаң да, кунак ике-өч сәгать буена басып тора алмый бит инде. Ул бит, артист булса да, бүген бу авыл кунагы! Китә шуннан эт – эткә, эт – койрыкка. «Хәзер... Авыл советында бар, алып киләбез». Китә... югала.

Күпләр беләдер, күргәннәре бардыр – соңгы вакытта мин гармунчы-солист буларак та чыгыш ясыйм. Гармуннарым шактый. Шуларны матур итеп, татарның мәшһүр заты Гали абый Җәмлиханов кебек, сәхнәгә тезеп куяр өчен өстәл сорыйм. Тагын сорауга сорау: «Болай гына ярамыйммы, тегеләй генә итмисеңме, урындыкка гына куймыйсыңмы?» – кебек тозсыз сораулар яудыра башлыйлар... Син өстәл китер! Мин бит үзем белән өстәл-урындык ташып йөри алмыйм лабаса. Концертларда «Сайрат, Кирам!» дип язылган яшел (мөселман) төсендәге эскәтерем гел үзем белән йөри. Гел-гел бер үк хәл: берәү авыл советына йөгерә, икенчесе китапханәчене эзләп өенә китә. Өстәл дә юк, урындык та. Халык кул чаба, концертны башларга кирәк... Һәм 43 ел буе шулай!..

Инде килеп элгеч мәсьәләсе. Авылда ул булмады һәм хәзер дә юк. Гади генә тимердән өч аяклы итеп эшләп куярга да була бит аны. Монда әллә ни зур акыл да, күп көч тә кирәкми. Андый элгечләрне кайбер клубларда күргәнем булды. «Нишләп шушы элементар әйберләр юк?» дигән сорауга җавап һәрвакыт мондый:

– Акча юк бит, агайне. Акча бирмиләр!..

Һәм ул тотына җитәкчеләрне сүгәргә.

Тукта, сабыррахман. Сүкмә. Булдырырга теләгән кеше чыгу юлын эзли, ә булдырырга теләмәгәне сәбәп таба. Сорый белеп сорасаң, бирәләр ул...

Клублар (мәдәният йортлары) элек тә, хәзер дә ике категориягә бүленә. Бар начарлары, бар яхшылары. Хуҗадан тора. Үз эшен яратып, җан атып, булсын дип йөргән мөдирнең (директорның) бинасы ерактан ук үзенең культура-агарту, мәдәният учагы икәнен «кычкырып» тора. Май чүлмәге тышыннан билгеле, диләр.

Күптән түгел туган авылым Татар Ямалыда Кирам Сатиев

музее ачылды, һәм Кирам Сатиев исемендәге гармунчылар фестивале булды. Бу чаралар миңа «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелү уңаеннан үткәрелде. Мәдәният йорты – чын мәгънәсендә мәдәният йорты. Чиста. Пөхтә. Яңа урындыклар. Идәннәр алыштырылган. Сәхнәдә дә, тамаша залында да яңа пәрдә, чаршау. Акча тапканнар бит.

Быелгы гарасат безнең Актаныш районында зур зыян салды, югалтулар күп булды. Давыл өй түбәләрен каерып ташлады, каралты-кураларны, мал абзарларын җимерде. Шуңа да карамастан кул кушырып утырмыйлар безнең якта. Конкрет эш башкаралар. Фестиваль оештыру һәм музей ачу – шуларның бер дәлиле. Рәхмәт җитәкчеләргә, оештыручыларга, «кара эш» башкаручыларга.

Әйтергә онытa язганмын: бездә китапханә эшли, гармунчылар һәм җырчылар ансамбле, бию түгәрәге бар. Бар да җитеш. Димәк, хуҗалар бар. Ә кемнәр соң алар? Совхозны – Хәмзә Гыйльметдинов, җирле үзидарәне – Мулланур Салихҗанов, мәдәният бүлеген Дәвир Галиев җитәкли. Буталчык яңгыраса да әйтим әле – тырышкан табар, ташка кадак кагар, һәм кактылар да: нәкъ 39 ел элек үзем мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы»н уйнап кергән мәдәният йортында минем музеемны ачтылар. Рәхмәт. Ул бинаның кирпечләрен дә үземә ташырга туры килгән иде. Киләсе елга, Алла боерса, шушы бина ачылуның 40 еллыгын да билгеләп узарбыз!

...Элек авыл клубларында (мәдәният йортларында) бильярд бар иде. Кайда алар хәзер? Кем сараенда тузан җыялар? Шашка-шахмат ярышлары уздырыла иде. Штанга, гер күтәрү, бокс секцияләре, спорт заллары бар иде. Ә волейбол уены һәр авылда күркәм бер ритуал иде. Һаман иде дә иде... Ни өчен үткән заманда? Теге шәп еллар спорты хәзер юк дәрәҗәсендә. Аларны яңартасы, кабат торгызасы иде бит, әй, кешеләр! Мин моны наркомания, токсикомания, эчкечелек кебек афәтләрдән яшь буынны, киләчәкне йолып алуның бер ысулы дип исәплим, һәм күпләр бу фикерем белән килешерләр дип фараз кылам.

Авыл бетә, мәдәният учагы сүнә, дип лаф оручы күп, ә конкрет гамәл кылганнар аз. Һәм тагын бер нәрсә: һәр түрә үз урынында түгел. Кайберәүләр гомер буена үз урынын таба алмыйча, анда кагылып, монда бәрелеп, бутап-буталып йөри. Авылга кайтып савымчы яки тракторчы булса, аннан үзенә дә, халыкка да файда булыр иде. Ә ул монда бутала. Үз урынында утырмый. Кулыңнан килгәнчә файда китер син. Үз һөнәрең белән шөгыльлән. Менә шул чагында «авыл бетә, мәдәният бетә»ләр үзеннән-үзе бетәр.

Холкым-фигылем белән мин оптимист кеше. Беркайчан да йомыркадан җөй эзләгәнем булмады. Яхшыны күрергә, яхшыга охшарга тырыштым, яхшыга таба омтылдым. Авылны, мәдәниятне, аның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген һәммә яктан яхшы булыр дип күзаллыйм...

*«Мәдәни җомга», 2007, 23 ноябрь*

## БЕЗ ДӘ ТӨШЕП КАЛМАДЫК...

Бу китапны мин шактый озак эзләп йөрдем. Аны иң элек атаклы баянчыбыз Владимир Федотов кулында күргән идем, хәзер ул менә Казанда ким дигәндә ике кешедә бар. Мәскәүдәге «КИФА-РА» нәшрияты 2003 елда бастырып чыгарган «Баянное и аккордеонное искусство» исемле бу мәҗмуганың кыйммәте шунда: анда дөньяның иң танылган баянчылары турында мәгълүмат тупланган. А.Басурмановның профессор Н.Чайкин редакциясендә нәшер ителгән әлеге китабында дөньякүләм конкурсларда җиңү яулаган баянчылар турында әтрафлы мәгълүмат бирелгән. Күз алдына китерү өчен, берничә илдә узган халыкара конкурсларны һәм кайбер баянчыларның исемнәрен атап үтәм: Ивент Орнер (Франция) – 1948 елда Швейцариянең Лозанна шәһәрендә узган конкурста җиңүче; Давид Анзаги (Италия) – 1950, Милан (Италия); Андре Ари (Бельгия) – 1953, Копенгаген (Дания); Фринц Доблер (ГФР) – 1954, Штутгарт (ГФР); Курт Хойссер (Швейцария) – 1955, Брайтон (Англия); Джон ла Падула (АКШ) – 1956, Биль (Швейцария); Джона Рид (Канада) – 1962, Прага (Чехословакия); Хенни Лангевельд (Һолландия) – 1966, Версаль (Франция); Юрий Вострелов (СССР) – 1968, Люстер (Англия); Кристина Росси (Монако) –1987, Арнем (Һолландия); Гарвина Баллерди (Испания) – 1988, Троссинген (Германия)...

Әйтергә теләгәнем шул: бу белешмә-китапка дөньякүләм танылган, халыкара конкурсларда җиңгән шәхесләрнең исеме генә кергән. Әмма иң шатландырганы һәм горурландырганы – дөньяга таралган шушы белешмә-китапка безнең утыз биш баянчыбызның исеме теркәлүе. Мин моны татар баянчыларының зур бер уңышы дип саныйм. Ә менә «Татар баянчылары» китабы әлеге «Баянное и аккордеонное искусство» белешмә-китабына ничек барып кергән – монысы билгесез. Әмма шунысы хак: баянчылар турында чыккан бу китапны әлеге белешмә авторлары күреп алган һәм баян музыка сәнгатендә зур бер адым дип санаган. Аңла-

ешлырак булсын өчен әлеге белешмә-китапның 264–265 нче битләреннән бер өзек китерәм. Аны ничек бар, шулай, русча язам: Татар баянчылары (Баянисты Татарстана). Сост. К.Сатиев, Н.Акмалов, Казань, изд-во «Магариф», 1996. На тат. языке. В сборник включено 35 очерков об известных баянистах Татарстана (цифры означают номера очерков): К.Сатиев – 1. Файзулла Туишев, 15. Ильяс Шарипов, 16. Ганс Сайфуллин, 17. Рафкат Гумеров, 20. Фанис Гильмутдинов, 23. Анатолий Шутиков, 33. Рустем Валеев, 35. Абузар Файзуллин; Г.Ягудин – 2. Гани Валиев; Р.Сафиуллин – 3. Рокыя Ибрагимова, 4. Габдулла Халитов, 8. Мухтар Ахмадиев; Р.Курамшин – 5. Фәйзи Садыйков, 6. Минжамал Мазунова, 11. Рифкат Лутфуллин, 24. Рафаил Бакиров; Н.Акмалов – 9. Сафьян Ибрагимов, 26. Алмаз Имаев; Р.Халитов – 10. Раис Сафиуллин, 14. Геннадий Шаронов; И.Сафин – 12. Насих Вильданов; Р.Ильясов – 18. Рэгъдэ Халитов; М.Разов – 19. Флера Хурматова; М.Нигметзянов – 21. Сайдаш Гарифуллин; М.Миншин – 22. Рашит Мустафин; Ф.Башир – 25. Фаил Исхаков; И.Кадыйров – 27. Харис Нигметзянов; С.Хабибуллин – 28. Рамиль Курамшин; Р.Курбан – 30. Фарит Хатыйпов; Ф.Муслимова – 32. Кирам Сатиев; М.Макаров – 34. Максат Гумеров; без указания автора – 7. Эзгир Абдуллин, 13. Марс Макаров, 29. Шагадэт Нуриев.

Менә шундый хикмәтле китап керде минем кулыма. Безгә хәзер «Татар баянчылары»ның яңа, тулыландырылган басмасын әзерләп чыгару мәслихәттер. Әнә бит, татар гармунчыларын һәм баянчыларын дөнья күләмендә хупшыйлар.

*«Мәдәни җомга», 2007, 15 июнь*

## КЫЗЛАР ИСЕМЕ БЕЛӘН АТАЛГАН ҖЫРЛАР

Соңгы елларда җырга, гомумән җыр сәнгатенә аеруча зур игътибар бирелә башлады. Татарстан Мәдәнияткм министрлыгы һәм Татарстан Дәүләт теле-радио компаниясе тарафыннан даими рәвештә уздырыла торган «Бөтенсоюз татар җыры», «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен», «Яңа елда – яңа җыр», «Җырым синңа, Татарстан» дип исемләнгән конкурслар моның ачык дәлиле.

Җөмһүриятебездә чагыштырмача кыска вакыт эчендә берничә җыр китабы бастырып чыгарылды. Шуларның кайберләрен атап узам: «Җырларыбыз», «Җырлап ачыла күңел» (төзүчесе З.Мансуров), шагыйрә Г.Зәйнашева сүзләренә иҗат ителгән «Илле җыр»,

«Сез яраткан җырлар» (төзүчесе Р. Газизов), «Су буенда учак яна» (Н. Касыймов), «Җырлыйк та, биик тә» (төзүчесе М. Кәшипов) һ.б. лар.

8 Март – Халыкара хатын-кызлар бәйрәме якынлаша. Газиз әниләребез, апа-сеңелләребез хөрмәтенә аларның исемнәре белән аталган җырларны бер җыентык (китап) итеп бастыра алсак, бездән, ир-атлардан, аларга иң яхшы бәйрәм бүләге булыр иде.

Әйдәгез, ирләр, шушы изге эшне башкарып чыгыйк әле. Быел өлгертә алмасак, безне гүзәл хатын-кызларыбыз гафу кылып, киләсе язга кадәр сабыр итсеннәр. Сабыр төбе – сары алтын, ди мәкаль. Ә җыентыкны «Без, без, без идек, Без төгәл йөз кыз идек»... дип атарга дигән тәкъдим бар.

Хәзер йөз кыз белән танышыйк, барысы да лаеклы микән?

Ал Зәйнәбем
Асылъяр
Асия
Алсу
Аңла, Таңсылу
Ай ли, Гөлбикә
Ай йолдызым
Әлфия
Әпипә
Әнисә
Әкълимә
Банатым
Бибинур
Бибкәй матур
Болгар кызы Айсолтан
Болгар кызы Ләйлә
Гайнавал җыры
Гайнифәрхат
Галиябану
Гөлмәрфуга
Гөлнәзирә
Гөлшаһидә җыры
Гөлҗамал
Гөлмәрьям
Гөлсинә
Гөлчирәкәй
Гөлшат җыры
Гөлкәй-Гөлгенә
Гөлнурым
Гөлсирәнең сөйгәне
Гөлгенәгә хатлар килде
Гөлгайшә җыры
Галимә җыры
Гөлнарым
Гүзәлия җыры
Диләфрүз
Дилбәр
Җәмилә
Зәйтүнәкәй
Зөбәрҗәт
Зөләйха
Зөлхиҗә
Зиләйлүк
Зөһрә җыры
Зөһрә йолдыз
Зәлилә
Зәйнәбем
Зәйтүнә
Зилә
Зөлфия
Зәлифәкәй
Зөлхәбирә
Зимфирәкәй
Исеме Зифа икән

Их, Роза, нечкәбил
Колхоз кызы Мәчтүрә
Комсомолка Гөлсара
Ләйсән
Ләлә
Лира җыры
Люция
Мәдинәкәй
Мәдинәм, гөлкәем
Миләүшә
Менә сиңа Миләүшә
Миңлебикә
Миңнурый
Мөхтәрәмә
Мәйсәрә
Наза
Нәсимә
Нәсимә каеннары
Наилә җыры
Нурия
Өммегөлсем
Рәйхан
Рәзинәкәй
Рәмзия җыры
Резидәкәй
Рушаниям, бәгырем
Саҗидә
Сания апа
Саҗидә җыры
Сәлимәкәй
Сәрия
Сәрвиназ
Сөембикә
Сөмбел
Тәзкирә
Фатыйма
Фирдәвескәй
Фәүзия җыры
Фәйрүзәкәй
Халисә
Хафизәләм, иркәм
Хафизәкәй
Хәмдия
Хәлимә
Хәтирә
Янбикә

*«Мәдәни җомга», 1994, 4 февраль*

## АРХАНГЕЛЬНЕҢ ҮЗ РИМЕ БАР

Беренче тапкыр мин Архангельск шәһәрендә 2000 елда Татарстанның рәсми делегациясе составында булган идем. Биредә сабан туеның «нигез ташлары»н салуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин, Казан шәһәре башлыгы К.Исхаков белән бергә катнаштым. Ул чакта Архангельск шәһәре тарихында сабан туе беренче мәртәбә уздырылды. Аны оештыруда шунда яшәүче милләттәшебез Рим Кәлимуллин да зур көч куйды.

Инде Рим Кәлимуллинның үзе белән якыннанрак танышыйк. Тумышы белән Башкортстанның Бакалы районы Балыклы авылы егете ул. Армиядә хезмәт иткәннән соң, Архангельск шәһәренә барып чыга, анда эшкә урнаша һәм, гаилә корып, шунда төпләнеп кала. Еллар уза... Бала чактан җыр-музыкага, милли моңнарыбызга гашыйк булган Рим узган гасыр азагында Казанга «Татар җыры»

бәйгесенә килә. Менә шул чакта К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында таныштык без аның белән. Конкурсның жюри рәисе Илһам Шакировның хәер-фатихасы белән бәйгенең «Тамашачы мәхәббәте» дигән номинациясендә җиңде Рим. Ләкин бу талантлы егет моның белән генә чикләнмәде, Русия һәм БДБ илләренең байтак авыл-шәһәрләрендә чыгышлар ясый башлады. Санкт-Петербург, Калининград һ.б. шәһәрләр дә алкышлады үзен. Аның җырлавын тамашачы чын йөрәктән кабул итте. Татар егете Адыгей Республикасында да уңышлы чыгыш ясады. Хәзерге көндә Рим Кәлимуллин – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Адыгей Республикасының мәртәбәле бүләге иясе.

Рим Кәлимуллин – Архангельск шәһәре һәм өлкәсе татарлары милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе. Өстәвенә ул әле уңганбулган эшмәкәр дә. Кыскасы, күпкырлы талант иясе безнең Римебез. Әле күптән түгел безгә Рим белән тагын бергә чыгыш ясарга туры килде. Монысы инде Түбән Новгород шәһәрендә булды. Анда безне Илһам Шакиров үзе алып барды. Үзе үк Римне сәхнәгә дә алып чыкты, аны тамашачыларга да үзе тәкъдим итте. «Илһам Шакировның үзе белән бер сәхнәдә чыгыш ясадым бит мин!» – диде Рим, концерт тәмамлангач.

Хәер, Архангельскида яшәп, татар әдәбиятына, сәнгатенә, халкыбызның милли мирасын анда яшәүче милләттәшләребезгә һәм башка халыкларга пропагандалауда үзеннән зур өлеш кертүче Рим Кәлимуллин үзе дә ихтирамга лаек шәхес. Татар сәнгатендә Римнең үз урыны, үз йөзе бар.

*«Мәдәни җомга», 2007, 9 февраль*

# ЮМОРЕСКАЛАР

## БЕДНЕҢ МӨГЕДЛӘР

Алдан ук кисәтеп куям, беренче урын, кыйммәтле бүләк һәм иң күп гонорар миңа булса гына язам, чөнки беднең районны шаккатыргыч исемнәр буенча бер генә төбәк тә уздыра алмый. Ни өчен дигәндә, Җир шарындагы бөтен континентларның иң кәттә исемнәре җыелган бездә. Әле ниндиләре генә! Джон – бездә, Робсон – бездә, Америка! Луис – Көньяк Америка исеме – анысы да бездә.

Европага күчәбез. Долорес Ибарруриның да исемен «беднекеләр» кушкан: җырчылар, шагыйрьләр, сәнгать әһелләре. Азиянең Индиралары да бездә Һиндстанның үзендәгедән күбрәк. Африка гына читтә калмасын дип, күпләр теге вакытта Патрис исеме куштылар, чөнки Лумумба сүзен әйтергә уңайсызрак иде. Тагын нинди континент калды? Ә!.. Австралия. Аннан җүнле исем таба алмагач, кайбер акыллы башларның кызлары Көнгерәгә әверелделәр. Биш континент исемнәре генә җитмәде, безнекеләр адәми зат яшәми торган Арктика һәм Антарктидадан да кеше исемнәре эзли башладылар. «Олень» белән «тюлень»не татарчалаштырып, бераз башкорт акценты кушып, Алинә, Түлинә дигән исемнәр модага кереп китте. Җир шары бетте!

Киттеләр шуннан Марс, Венерага. Ә менә Кояш апаның безнең районнан булмавы күпләрнең эчен пошырды, кәефен кырды. Шулай да шагыйрәнең кояштай кызу әсәрләрен яратып укыдылар.

Революция исемнәре белән артык вакланып тормадылар. Алар белән татар дөньясы тулган иде. «Беднекеләр» тагын «мөгед» чыгарды, исем кушуның яңа ысулларын уйлап тапты. Яңа атамаларны, күктән җиргә төшеп, тимер-томыр, калай-колай, арыш-бодай арасыннан эзли башладылар. Таптылар. Тапмый ни!

Бөек торгынлык елларының олы гигантлары үсеп чыккан чорда безнең күрше малае Камазның атасы Белаз исемле иде. Ни өчен иде? Күптән түгел генә «КамАЗ» машинасына тапталып үлде. Ярамады микәнни аңа Билал гына булып йөрсә?! Хәзер күршем инде малай-шалай түгел, ә зур нәчәлник. Үз исеме белән аталган заводта эшли. Кабинеты ишегенә зур хәрефләр белән «Камаз Белазович Уазов» дип язып куйганнар.

Ә монысын миңа бер танышым сөйләде. Камаз Белазовичның якын дустының исеме аныкыннан кәттәрәк икән – Карбюратор Аккумуляторович Генераторов. Сызыкча аша «Трансформатор»-ны да фамилиясенә ялгаса, үзе әйтүе буенча, конгениальный, федерально-лидеральный кеше килеп чыгар иде.

Актаныштан гайре тагын кемнең кайда һәм кайчан ишеткәне бар шундый исемнәрне: Баян-гармуннарны, Лимон-әфлисуннарны – ашау-эчү, күңел ачу әйберләрен; Энгельс, Мельс, Феликсларны, кычытмаган җирне кашыта торган Экземалар, Дездемалар...

Күршедә Диларис бар иде. Кем инде аның Долорес икәнен белсен? Без бәләкәй малайлар, аны «Беларус» дип, тракторга охшатып йөри идек. Тагын берсе – Дәвәрис дигәне – безгә кунакка килде. Хатын: «Ник олы кешене мыскыллыйсың, дөрес әйтеп сөйләш», – дип, мине сүгеп ташлады. Аның чын исемен ул Дворец абый дип уйлаган икән.

Диларис-Беларус дигәннән, нигә соң әле юл атамалары белән шәп исемнәр кушмаска? Мәсәлән, Асфальт, Тротуар, Бардюр, Бульвар, Сквер, Марс, Венера исеме кушканнар, ә Сатурннар, Нептуннар, Плутоннар юк. Хуҗалык кирәк-яраклары, йорт җиһазларын да онытмаска иде. Мәсәлән, «унитаз» сүзе Гөлназ, Илназ кебек яңгырый. Ә үскәч Унитаз Илназович була. Звучит! Азат, Азот исемнәре янына Кислород, Водород, Денатуратларны да өстәп була.

Ярты халкының исеме «мулла» белән башлана торган бер авыл бар. Муллашәех, Муллагали, Муллаяр, Мулланур, Муллаян, Мулләхмәт... Ә бер оешмада гел «ат»лар иде: Ринат, Азат, Марат, Бринат, Илфират, Фердинат, Рафинат. «Ат»ка «мулла»ны кушасың да, менә дигән өр-яңа исем килеп чыга: Акмулла бар, Хатмулла бар. Ә Атмуллалар беркайда юк. Менә күрәсезме, районыбызга тагын бер яңа исем өстәлде – Атмулла.

Революцион сүзләрне татарчага яраклаштырып, бераз шомартып, Вәликасыйм дип исем кушканнар бер абзыйга. Ул ВЛКСМ булып чыкты.

Ә исем җисеменә туры килә: алма агачыннан ерак төшми. Ни чәчсәң, шуны урырсың һ.б. Авылларының исемнәре нинди – кешеләрнең дә шундый. Тагын кайда бар «беднеке» кебек шәп яңгырашлы авыллар: Куян, Әтәч, Бурсык, Тыңламас, Күткире, Мәчти... Йә, әйтеп карагыз!

*2007*

# МИКРОФОННЫ ТОТА БЕЛМИСЕЗ

Элек мин зур артист идем. Ә хәзер гади бер тамашачы. Залда концерт карап утырам. Шәп җырлыйсыз, сүз дә юк. Ләкин микрофонны тота белмисез!

Учлап тотма! Син бит доярка түгел, артист! Микрофон ул сыер җилене түгел. Аны бармак очлары белән генә тотарга кирәк. Культурно итеп.

Хәзер инде нинди ераклыкта тоту мәсьәләсен хәл итик. Авызга якынрак булган саен, микрофон тавышны көчәйтә, сизгерлеге арта. Ләкин аны, кайбер җырчылар кебек, авызга тыкмаска кирәк. Микрофон ул авыз гармуны түгел.

Авыздан чыккан ят тавышлар – гыжлау, чапылдау һ.б лар микрофонга кермәсен өчен, аны ераграк тотарга киңәш бирәм. Микрофон ераграк булган саен, тавыш та чистарак була.

Кулны арытмас өчен, микрофонны куеп торырга да рөхсәт ителә. Моның өчен махсус җайланма – стойка бар. Ул булмаса, урындыкка да, өстәлгә дә куярга була. Ләкин микрофонны идәнгә сузып салырга һич кенә дә ярамый, куйганда, алганда кулга шыршы керүе ихтимал.

Соңгы вакытта сатуда пластмасс микрофоннар күренә башлады. Бу бик яхшы, чөнки элеккеге тимердән эшләнгәннәре ягылмаган клубларда кулны өшетә иде. Ләкин аларны тагын да камилләштерергә дигән тәкъдим бар, боларга тире чорнарга кирәк. Заводтан ук микрофонны чын тиредән ясап чыгарсыннар иде. Урысча әйткәндә, натуральный кожадан. Беренчедән, бу сәламәтлеккә файдалы, икенчедән, кулны өшетми, өченчедән, тотарга рәхәт. Чын тире кыйммәт тора торуын. Ләкин моңа акча кызганмаска кирәк. Ясалма тиредән эшләнгән микрофон сәламәтлеккә зыянлы. Аның шулай икәнен озаграк, күбрәк, ешрак тоткан саен ныграк тоясың.

Инде бу җайланмаларның зурлыгы турында да аңлашыйк. Кайберәүләр зуррак булган саен яхшырак дип уйлыйлар. Хикмәт аның зур булуында түгел, ә сыйфатында. Кечкенәсе белән дә көчле тавыш чыгарырга була һәм киресенчә.

Һәркемнең үз микрофоны булырга тиеш. Беренчедән, үз әйберeңне саклап, кадерләп тотасың, икенчедән, Сәламәтлек министрлыгы шулай куша, чөнки теләсә кем тоткан әйбер чиста булмый.

Микрофонның чукмары зур булмасын иде. Бәлки, ул шулай яхшырактыр, ләкин тамаша залыннан караганда ифрат дәрәҗәдә

ямьсез күренә. Ә төсе кызыл булсын иде. Ут сүнгән очракта ерактан ук күренеп торсын өчен.

Соңгы елларда шнурсыз (киндерәсез) микрофоннар пәйда булды. Болары депутатлар өчен бик уңайлы. Урыннан тормый гына сөйлисең дә микрофонны күршеңә тоттырасың. Күршең дә күршесенә суза.

Микрофонны кайсы кул белән тоту хәерле? Ничек тә ярый. Кушылучыларның урыннарын алыштырудан сумма үзгәрми. Ә менә бер егет бу җайланманы ике кул белән тота. Концерт беткәч, түзмәдем, сорадым. «Нигә, – мин әйтәм, – син аны ике кул белән тотасың?» – «Ничек телим, шулай тотам, анысы минем эш», – диде дә грим бүлмәсенә кереп югалды. Ә чынлап та ике кул белән тотарга ярыймы соң? Ярый. Тотарлык урыны булса.

Беркөнне сәхнә артында яшь артисткалар кызып-кызып бәхәсләшәләр, микрофонның нинди яхшы, диләр: нечкә озынымы, әллә юан кыскасымы? Бик озак тарткалаштылар. Түзмәдем, кистереп җавап бирдем: «Эшли торганы», – дидем.

*1995*

## АРТИСТЛАР ИТ ЯРАТА

– Ипи белән аша.

– Юк, мин ите белән ашыйм.

– Энем, ипи белән аша!

– Юк, мин ите белән ашыйм әле.

– Энем, сиңа әйтәм, ипи белән аша!

– Юк, авылда ит күп ул. Мин ите белән ашыйм.

– Ишетәсеңме, ипи белән аша, диләр сиңа!!!

– Мин ит яратам, ите белән ашыйм...

Шул вакыт чыгырыннан чыккан салмыш абзый буяуга каткан артлы урындыкны күтәрде. Уйлап, анализлап торырга вакыт юк. Үземне – ләхеттән, хуҗаны төрмәдән алып калуның бер генә юлы бар иде: качып котылу. Яшен тизлеге белән чыгыш йөгердем. Каршыма верандадан кереп килүче дустым очрады. Кулларын юып, ит ашарга кереп барышы икән.

Эшнең нәрсәдә икәнен аңламаган фатирдашым тиз генә сорау биреп өлгерде:

– Син кая, корт чактымы әллә?!

– Әй, сорама, – дидем дә, уктай атылып, капкага таба юнәлдем.

Кызулыгымнан ата каз талаганны да, усал эт тешләгәнен дә, нәсел үгезе сөзгәнен дә сизмәгәнмен. Урамга чыктым да бер өй аркылы урнашкан фатирдашларыма кереп бикләндем.

Ничәдер секундтан яңа фатирыма иске дустым да килеп керде. Йөзе агарынган, чәчләре үрә каткан, сүзләрен әйтә алмый. Бераздан тотлыга-тотлыга сөйли башлады:

– Ке-ее-ердем... Абый белән и-и-и-исәнләштек. Ул миңа усал итеп карады. Аннары: «Бу нинди өрәк тагын? – диде дә, ипи белән аша, дип, урындык күтәрде. Ми-и-ин ба-а-а-шта ша-а-аярта дип уйладым. Нинди шаярту булсын. Петр патша вакытында ясалып, Никулай заманнарыннан исән калган, буяуга каткан бу урындык... Әйтергә куркыныч... Ярый, Алла саклады...

Кич җитте. Клубка киттек. Концерт карарга фатир хуҗасы иң алга – нулевой рәткә үк кереп утырган. Әйтәсе сүзләремне онытам. Тигез сәхнәдә дә абына башладым. Сүзләремне оныткан саен, «ите белән» дип кыстырам. Ә залдан теге абзый, пышылдап, «ипи белән» дип төзәтә. Мин һаман «ите белән» дип кабатлыйм. Фатир хуҗасының кулына төреп тоткан гәзите күземә ике көпшәле мылтык булып күренә башлады. Тагын ялгыштым. Абый, ниһаять, «ите белән» дип кычкырды. Ә мин «ипи белән» дип каршы төштем. Рольләрне алмаштык. «Мин дә ит яратам», – дип кычкырды абзый һәм куш көпшәле мылтыгын миңа төбәде!.. Бер-бер артлы ике тапкыр «Ите белән, ите белән» дигән ату тавышы яңгырады. Салкын тиргә батып, уянып киттем.

*1995*

## ҮЗЕШЧӘН КОНДУКТОРЛАР

*(Була язган хәл)*

Автобусның арткы ишегеннән кереп, кондуктордан билет сатып алдым да алга таба уздым. Каршы якта тагын бер кондуктор күренде. Селедка балыгы кебек бер-берсенә ябышкан халыкны аера-аера, ул миңа таба шуыша иде. Урысчалатып: «Возьми билет», – диде дә миңа усал һәм салкын итеп карады. Әле генә алган билетымны аңа күрсәттем.

– Каян, кемнән алдың? – дип төпчеnә башлады. «Әнә, – мин әйтәм, – кондуктордан». «Монда мин кондуктор», – диде кипкән шүкә кебек ябык ир-ат.

– Син үзешчән кондуктордыр әле, – дип, сыра мичкәсе кебек юан ханым аңа ташланды.

Кемнең үзешчән, кемнең профессиональ билет сатучы булуы турында бәхәс башланды. Якалашу озак һәм нәтиҗәле дәвам итте. Кондукторлар иске танышлар булып чыкты.

– Күрсәт, – диде юан ханым.

Әллә чынлап, әллә юри, ир телен чыгарып күрсәтте.

– Телеңне түгел, ниеңне күрсәт, – диде ханым һәм тиешле сүзне таба алмыйча азапланды. – Документыңны күрсәт,– диде ул, тотлыга-тотлыга. – Син үзешчән кондитердыр әле.

Бу акча кортлары кондукторны кондитердан, кафены кофедан, аптеканы оптикадан аермасалар да, тапкырлау таблицасын белә иделәрме- юкмы, ләкин акчаны оста саныйлар иде. Ызгышу кызганнан-кыза барды.

– Җитте, ыслушай. Тукта. Югыйсә мин синең яманатыңны сатам. Халык алдында хур итәм.

– Сат. Курыкмыйм. Сүзем туры, юлым коры. Синең үзеңнең гөнаһларың да буа буарлык. Атаң кулак иде, бабаң, мәрхүм, аклар яклы булып сугышты. Үзең, сугышка бармыйча, дезертир булып йөрдең. Фашистларның җиңүен теләдең. Алар җиңгән булса, без бик яхшы яшәр идек, дип әле сөйләп тә йөрисең. Сугыш вакытында Казанда ит чаптың. Кичләрен салган баштан «Даешь Берлин!» дип кычкырып йөрдең. Сугыштан соң Мәскәүдә сыра саттың. «БАМда тирлим» дип шигырь яздың. Инде кабат монда буталасың. Кеше талаучы син, аферист. Синең бит сатып алган зоотехник дипломың бар. Авылда гына яшәргә иде. Теге вакытта, ялгыш укол кадап, колхозның утыз тугыз бозавын үтердең. Синең башыңны төрмәдә черетергә кирәк!

– Җитте, канымны кыздырма!

Ир-ат кондукторның адресына хатын-кыз кондуктор тагын берничә кило пычрак атты. Ачу-ярсудан ата алиментчының кан басымы күтәрелде. «Алай да төрмә, болай да төрмә, – дип уйлады ир-кондуктор. – Колхоз бозауларын үтергән өчен дә, унсигез ел буе алименттан качып йөргән өчен дә, үзешчән кондуктор булып халыкны талаган өчен дә төрмә... Беткән баш беткән, бу хатынны да пычракка буярга кирәк. Ул гына фәрештә түгел».

– Ә син гомерең буе кияүгә чыга алмадың. Уйнаштан ике бала таптың. Кызыңны детдомга биреп, типтереп яшәдең. Малаеңны, кемгәдер яраклашып, үзең теләп Чечняга җибәрдең. Ә алимент акчаларын комсызлыгың аркасында «Хопер-инвест»ка биреп «яндырдың». Үзең тапкан мал түгел, ирләрнеке җәл түгел! Егерме җиде тапкыр аборт ясаттың.

Кешеләр айлар буе хезмәт хакы ала алмыйча интеккәндә, шәһәр кырыенда өч катлы йорт салдырдың. Рэкетирлар ут төртеп яндырмаган булса, синнән аны барыбер кемнәрдер, кайчандыр талап алырлар иде. Казандагы пляжда шешә җыеп кына йөрсәң ярамый идемени сиңа?

– Үзеңне бел! Миңа ябышма! Син үзең үзешчән кондитер. Әй, кондуктор!

...Шул вакыт автобуска милиция хезмәткәре килеп керде. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач, милиционер акчаны халыкка кире кайтаруларын таләп итте. Бу әмерне хупламаган үзешчән кондукторлар икәүләп хокук сакчысына ташландылар.

– Син безгә акыл сатма, тәртип саклавыңны бел. Кругом фатир басалар, кеше үтерәләр. Кая карама көчләү, алдау, талау. Югал моннан!.. Ә, туктале, син үзешчән милиционердыр әле! Ну-ка, күрсәт документыңны. Күрсәт диләр сиңа!

Һәм ул чыгарып күрсәтте. Ә документның тышына «Удостоверение многодетной матери» дип язылган иде. Яшь милиционер каушаудан ялгыш күрше кесәсенә кергән икән. Ә бу кеше хатынының документы белән сәяхәт итүче пассажир булып чыкты.

Халык кабат шаулаша башлады. Ыгы-зыгы купты. Кычкырыш-талашларга, сүгенүләргә түзә алмыйча, автобусның запас тәгәрмәче шартлады. Шәһәр транспортына ут капты, паника башланды... Кем ишектән, кем тәрәзәдән, кем түбәдәге люктан урамга ыргылды. Ә үзешчән кондукторлар, суга төшкән балта кебек, төтен эченә кереп югалдылар.

## АШЫЙСЫ КИЛӘ, ЯШИСЕ КИЛӘ

Имештер, Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләдән: «Халык бик азынса, ничек һәм нәрсә белән тыярбыз микән?» – дип сораган һәм мондый җавап алган: «Ачлык белән».

Ачлык... Моннан да кыенрак, моннан да әшәкерәк нәрсә бар микән бу дөньяда?! Ачның ачуы яман, диләр. Ач кеше тукка ышанмый, диләр.

Бала чагымда бик ялкау идем. Эшкә кулым бармады, юньләп укый алмадым. Шулай үстем. Бердәнбер яратып башкара торган эшем бар иде – аннан да бер сәбәпсез, «сокращение» дип кудылар. Инде нишләргә? Кая барырга? Ничек ачтан үлмәскә? Анда барам, монда сугылам. Эш юк, диләр. Эш юк дип әйтү – үзе юк сүз. Безнең тирәдә бер мунча да, мәдәният йорты да юк. Монысы дөрес.

Ярар. Мать якасына, кем әйтмешли. Мин дә кайберәүләр ке-

бек җиңел кәсеп белән генә яшәп карыйм әле дидем дә зиратка киттем. Мәет күмәргә. Дүрт кешедән оркестр оештырдык. Нота белмәү сәбәпле, тәлинкә (чаң) сугу вазифасын үз өстемә алдым. Берне сугасың да өчне ял итәсең, берне сугасың да тагын өчне ял итәсең. Яхшы бит, ә?! Ләкин монда да акча урынына натуралата түлиләр икән. Хәзер балконымда дүрт чардуган, алты кабер ташы һәм тугыз венок ята. Сатар идем, алмыйлар. Конкуренция көчле. Кемдер, әллә шаярып, әллә чынлап, хезмәт хакын хәзер мәетләтә бирәчәкләр икән, дигәч, тиз генә башка эшкә күчтем. Артист булып эшли башладым. Монда да рәхәт тормыш юк икән...

Шаулап-гөрләп узган концерттан соң акча урынына унитазлар бирделәр. Ни ашап булмый аларны, ни сатып булмый. Кухняга табуретка урынына тезеп куйдык аптырагач.

Ит комбинаты һәм кошчылык фермасы концертны алмады. Ә менә бер концертыбыз зоопаркта булды. Җырчыларга – аю, ә калганнарга берәр маймыл бирделәр. Миңа, маймыл җитмәү сәбәпле, ишәк эләкте. Шәригать кануннары буенча, ишәк итен ашарга ярамый икән.

Шуннан соң без авылга юл тоттык. Халык безнең концертны бик ошатты. Ә түләү ит белән булырга тиеш иде.

Сөйләшенгән вакытка итне алырга авылга кабат юнәлдек.

– Сезгә түгел колхозчыларга бирергә дә ит юк, – диде колхоз рәисе. – Телисез икән, тиресләтә бирәм. Сез бит аны барыбер сатып аласыз. Трусиклар бар, мендәр тышы, хатын-кыз колготкилары, куян бүреге... Аның өчен ким дигәндә дүрт-биш концерт куярга кирәк булыр.

Авыр тынлык урнашты. Шулай тып-тын аңлаша торгач, рәис зоотехникны чакырды.

– Тәк... болай. Менә ике егет килгән. Концертның бәясе билгеле. Акча юк. Сыерны йә тагып алып китсеннәр, йә суеп бир. Булды. Эшем күп. Давайте, егетләр...

Уф, эчкә җылы йөгерде.

Казан урамнары буйлап «Жигули»га сыер тагып кайту бик килешмәс дип уйлаштык та суеп бирүләрен үтендек.

– Мин суючы түгел бит, – диде зоотехник.

– Ә кем суя?

– Бригадир.

– Ә ул кайда?

– Аръякта.

– Киттек.

Бригадир бик каты махмырдан иде.

– Пычагыгыз да юкмыни? – диде ул, ярым карлыккан тавыш белән.

– Без суярга түгел, суелганны алып китәргә килгән идек.

– Пычак табылды, инде буламы?

– Юк.

– Нигә?

– Баш авырта. Аракы кирәк.

– Ә аракы кайда бар?

– Түбән очта.

...Кибеттән чыкканда бу сәрхушкә тагын берничә бәндә ияргән иде.

– Бер кеше генә суя алмый, ярдәм итәрбез, – диде арадан берсе.

– Ярар. Ә сыер кайда?

– Фермада.

Кеше саен кырлы стакандагы аракыны тозлы кыяр белән бастырып куйгач, егетләр гайрәт чәчәргә тотынды. Ике аяклы маллар дүрт аяклы малны куа башлады. Кайбер суючылар дүртаяклаnып йөри башлады. Кем кемне тота, кем кемне суя, һич кенә дә аңлашылмый. Менә хәзер инде элеккеге ике аяклы маллар белән дүрт аяклы маллар бер хөкемдә – барысы да дүрт аяклы иде.

Озак кудылар. Айнык мал айнык инде. Тоттырмый.

– Юк, егетләр, булмый. Әйдә Ришатны суябыз, – диде берсе.

– Нинди атны? Безгә бит сыер суярга куштылар.

– Атны димим, Ришатны!

– Тәүбә диген. Кеше суеп гөнаһлы булыргамы?

– Соң, сыер тоттырмый бит!

Теге сәрхуш үзенекен сукалады:

– Артистларга барыбер түгелмени? Барыбер ул артистлар берберсен ашап яшиләр...

Әүмәкләшү, сүз көрәштерү, бәхәсләшү озак дәвам итте. Ике аяклы маллар дүрт аяклы малны тәки тота алмадылар. Үзебезгә тотарга туры килде. Караңгы төшкәч, машинаны авылда калдырып, урман-кырлар, елга-күлләр аша шәһәребезгә җәяүләп юл тоттык...

## КЫРГЫЙ УТРАУ

Сакаллы башкисәр автоматын командирның маңгаена терәде:

– Самолетны мин әйткән урынга алып бар! Чит илгә! Аңладыңмы?

Пилот ризалашырга мәҗбүр булды.

Озакламый алар Тын океан өстеннән очалар иде. Кайсы илгә бару турында бәхәс купты. Берсе – анда, берсе монда тарткалады. Сүз көрәштерү озак һәм нәтиҗәсез дәвам итте. «Тимер кош»ның ягулыгы бетте, һәм ул «необитаемый остров»ка – кыргый утрауга мәтәлеп төште.

...Мат-перемат башланды. Чакырылмаган кунаклар шулхәтле әче итеп сүгенделәр, утраудагы пальмалар корыды, чәчәкләр һәм тропик үсемлекләр шиңде, океандагы вак балыклар үлде. Хурлануга түзә алмыйча, кояш болытлар арасына кереп югалды. Китлар, акулалар кыргый утрауга кыргыйлар килүен исләре китеп карап тордылар. Одеколон, лосьон һәм самогон исе тынга капланды, кошлар очудан туктады.

Утрауда кеше яшәмәгәнен белгәч, күктән төшкән хуҗалар үз законнары белән яши башладылар.

Самолет калдыкларыннан самогон аппараты ясадылар.

Көне-төне рәхәтләнеп эчтеләр. Кайберләрендә «белая горячка» башланды. Башта вак-төяк җанварларны тотып ашадылар. Аннары чират зурларына җитте. Моны сизенгән арыслан-киекләр, юлбарыс ишеләр куркудан өнсез калдылар һәм ничек кенә булса да кыргыйлар яныннан качу ягын карадылар.

Фахишәлек массакүләм төс алды.

Алимент түләүдән качучылар һәм төрмәгә керергә өлгермәүчеләр өчен бу чын мәгънәсендә оҗмах иде. Чөнки монда милиция юк: закон –тайга, аю – хуҗа. Бу кадәр вәхшилектән соң утрау чынчынлап кыргый утрауга әйләнде: урманнар янып-көеп бетте, чишмәләр корыды. Утрауны сәер караңгылык чорнап алды.

Ачлыктан һәм махмырдан шешенгән сәрхушләр киңәшмәгә җыелдылар. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә – ашау-эчү мәсьәләсе иде. Алар Берләшкән Милләтләр Оешмасына хат яздылар. «Белая горячка»дан интегүче ике иптәшнең берсе Сталинга шылтыратты, икенчесе Бериягә телеграмма җибәрде. Арадан берсе ни өчендер Робинзон Крузоны искә алды. Беркөнне утрау янына пиратлар корабле якынайды. Аларның исәбе тегеләрне талау иде. Ә утрауда таларлык түгел, яларлык та әйбер калмаган. Ул гына да түгел, бу кыргыйлыкны, вәхшилекне күргәч, пиратлар моннан тизрәк таю ягын карады. Кыргыйларның һәм кыргый утрауның кайчан һәм ничек пәйда булуы һәркемгә дә аңлашыла иде. Ләкин «чакырылмаган кунак»лар үзләрен чын хуҗалар кебек хис иттеләр. Алар өчен «кыргый» дигән төшенчә гомумән юк, фәкать «яңа»сы гына – Яңа Зеландия, Яңа Җир утравы һәм... яңа дуслар гына бар иде...

# ӨЧ БОРЫНГА КЕРҮ

1 апрель көнне хатын, мин һәм кыз өчәүләп музейга бардык. Кердек. Карыйбыз. «Өч дуңгыз баласы» рәсеме эленеп тора. Ләкин икесе – Наф-наф белән Ниф-ниф юк. Язу калдырганнар: «Без киттек. Син үпкәләмә, Нуф-нуф. Мәхәббәттә өченчебез артык». Яшь дуңгыз баласы Нуф-нуф, дуңгыз булганчы эчеп, ләх исереп, гырлап йоклап ята.

Алдарак тагын бер рәсем. «Аккош, Чуртан һәм Кысла». Өчәүләп бер йөкне тарталар, ә йөк бармый... «Сәбәбе, – дип язылган, – Чуртанны Иванушка исерткән, Аккошның канатын кискәннәр, ә Кысла гел арт турында гына уйлый».

Тагын бер сурәт: «Өч егет». Астында аңлатма: «Патшаның булган өч улы, өченчесенең күте кычулы». Кемгәдер бу ошамаган һәм ул аны төзәткән: «Патшаның булган өч улы, икесе акыллы, берсе – Себердә», – дигән. Аны да сызып, өстенә тагын язганнар: «Патшаның булган өч улы, икесе акыллы, өченчесе артист». Васнецовның «Өч баһадир» рәсемендә ике генә батыр ясалган. Өченчесен – Алеша Поповичны – көмешкә алырга күрше авылга җибәргәннәр.

Әнә алдарак тагын «Өч аю» рәсеме. Аюлар өчәү, ә кашыклар икәү. Аста язу: «Ата-аналары бәләкәй аюны, артык кашык дип, кашыгын тартып алып, заман таләпләренә туры китереп, детдомга тапшырырга алып баралар».

Аю дигәннән, тагын бер рәсем карадык. Дөресрәге, шигыре бар, сурәте ясалмаган, авторы да билгеле түгел.

Аю, бүре һәм мәче
Өч борынга кермәкче.
Барысы да уйга талган:
Акчалары өйдә калган.

Мораль: тарал!

Бар иде өч борынга кергән заманалар. Кибет артларында качып-посып йөргән чаклар. Шул дәвернең бер мәзәге искә төште. Бер ир нык исереп өенә кайта. «Бу хәтле дуңгыз булганчы кайда эчтең?» – ди хатыны. Ире җавап бирә: «Өч борынга кердек». «Соң, шулкадәр исереп буламыни?» – ди хатыны. Ире көч-хәл белән аңлатып бирә: «Өч борынга керүчеләрнең икесе килмәде бит».

Тагын бер мәзәк. Хәзерге заман мәзәге. Ике кеше, бер ярты алып, хәрчәүнәгә керә. Стаканнарга салып чәкештергәндә, бер

сәрхуш килеп керә дә, шатланып: «Мин өченче булам», – ди. «Юк,– ди тегеләр. – Син дүртенче буласың». «Ничек», – ди ул. «Ничек булсын. Койрыкка утырырга теләүче өч кешене без өч хәрефкә озаттык инде. Кит, дидек без аларга».

## КИРАМ САТИЕВ КЫТЫКЛАРЫ

### Эчтеңме әллә, энем?

Илһам Шакировның – яшь, Кирамның әле бик яшь чаклары. Дөресрәге, Кирам әле җырчы абыйсы белән беренче репетицияләргә генә йөри. Илһам абыйсына гел «сез» дип, зурлап-олылап эндәшә: «Илһам абый, сез...»

Шулай бер репетиция вакытында, бик тә җитди җырны өйрәнгәндә, Илһам Шакиров як-ягына аптырап карап-карап куя да әйтә:

– Бу бүлмәдә әллә тагын берәр кеше бармы соң? – ди. – Күзеңә ике булып күренәмме әллә, энем? Эчтеңме әллә син?..

### Мәҗлес җырлары

2004 ел. Кемнеңдер юбилей кичәсе. Кирам Сатиев кичәдә уйнала торган җырларның исемлеген аерым папкага салган. «Өстәл янында җырлана торган җыр текстлары» дип язылган. Бу язу артист Фирая Әкбәровага бик ошый. Янәшәдә тагын бер папка бар икән. Һәм ул папка тышына «астында» дигән сүзне дә өстәп куя. Шулай итеп, Кирам Сатиев репертуарында «Өстәл астында җырлана торган җыр текстлары» да пәйда була.

### Озату

«Мәдәни җомга» газетасы редакциясе. Бүлмәдә – Илдар Юзеев, Нияз Акмал, Кирам Сатиев. Сүз тәмамлангач, Илдар ага китәргә кузгала. Н.Акмал белән К.Сатиев аны аягүрә баскан килеш озатып кала.

– Шулай, егетләр, ятып калуга караганда басып калу әйбәтрәк ул, – ди Илдар Юзеев.

## Түләүсез концерт

Коеп яңгыр ява. Тукталышта автобус көтеп Рамил Курамшин басып тора. Борчыла. Нияз Акмал белән Кирам Сатиев үтеп баралар. Нияз, Рамил аганың баянын рюкзак дип белеп: «Бакчагамы?» – дип сорый. Р.Курамшин, ялгыш ишетеп: «Акчага түгел шул, бушка уйнарга барам, шефский концерт», – дип җавап бирә.

## Пычрак кул

Акчаның буталчык чагы. Әлфия Авзалова – концерт бригадасында үзе җырчы, үзе администратор. Авыл җирендә гастрольләр. Әлфия Авзалова афиша һәм концерт билетларын, бернинди документ-фәлән сорап тормыйча, авылдан килгән бер тракторчы егеткә биреп җибәрә.

Йә, хуш. Авылга килеп төшәләр. Афиша да юк, билетлар да. Тракторчы егет тә юкка чыккан. Концерт иртәгә була дигән көнне авылга юл тоталар.

– Әлфия апа, исеңә төшер әле, зинһар, кем алып китте соң билетларны? – дип өзгәләнә халык. – Кем иде? Кыяфәте, килешкилбәте,сакалы, мыегы, миңе, күзлеге юк идеме?

– Аларын төгәл хәтерләмим, – ди Әлфия Авзалова. – Куллары гына кара, майлы, пычрак иде...

Китәләр өченче авылга. Авылда өч тракторчы бар икән. Эштән кайтып, кулларын юып ашарга гына утырган болар.

Китәләр дүртенче авылга, пычрак куллы тракторчыны эзләргә...

## Тизлек кирәк, тизлек

Җырчы Зөфәр Сафин филармония залында узачак концертка әзерләнеп йөри. Кирам белән репетицияне баянчының өендә үткәрергә килешәләр. Зөфәр билгеләнгән вакытка соңлабрак килә.

– Ачуланма, 170 белән килгән идем, соңгарак калдым бугай, – ди.

– Ничек?! 170 белән йөреп буламы Казан урамында? 170 белән килеп тә соңардыңмы?! – ди Кирам.

– Әйе, 170 нче автобуска утырган идем, урады да урады, – ди Зөфәр.

## Илһамга ничә яшь?

Сарманда зур концерт бара. Илһам Шакировка 70 яшь тулган. Концертны Алмаз Хәмзин алып бара.

– Илһам абый, син бик яшь күренәсең, сиңа 70 не биреп булмый, – ди Алмаз.

– Миңа 150, – ди Илһам.

– Һай, анысы грамм бит аның, Илһам абый! – ди Алмаз.

## Уфа вакыты

Артистлар Питрәч ягына чакырылган. Әсхәт Хисмәт – тамада, Кирам – баянда. Иртәнге 9 га сөйләшенгән автобус сәгать 7 гә үк килеп җиткән.

– Нәрсә, нишләп болай бу? Ике сәгатькә иртә килгән, ә! Әллә Питрәчтә Уфа вакытымы соң, Кирам?! – дип бик гаҗәпләнгән Әсхәт Хисмәт.

# КИРАМ – СӘХНӘ ӨЧЕН ТУГАН ТАЛАНТ

*Илфак Ибраһимов*

## АФӘРИН, ЯКТАШ!

Танылган баянчы һәм гармунчы Кирам Сатиев минем якташым, Актаныш районының Татар Ямалы авылы егете. Халкыбызның яраткан җырчысы Әлфия Авзалова да минем якташым. Алар икесе бер төркемдә озак еллар буе концертлар куеп йөрделәр. Бөтен дөньяга сибелгән милләттәшләребезгә татар моңын җиткерделәр. Халык артисты исемен йөртүче дистәләрчә сәнгатькәрләр арасында алар – Әлфия апа һәм Кирам – Илһам Шакиров, Рәшит Ваһапов, Фәридә Кудашева, Фәйзулла Туишев кебек халыкка иң якын торган, халык белән иң тыгыз аралашкан, халык мәхәббәтен казанган шәхесләр.

Кирам Сатиевның иҗаттагы уңышларына мин ихластан сөенәм һәм горурланам. Кирам туып үскән Татар Ямалы авылы минем туган оям Чалманараттан биш чакрым ераклыкта гына урнашкан. Сатиевлар һәм Ибраһимовлар гаиләләре безнең районда күптәннән билгеле булды. Һәр гаилә башлыгы – сугыш һәм хезмәт ветераны, һәр гаиләдә өй тулы бала-чага.

Район газетасының 60–70 нче елларында чыккан басмаларын актарганда, Татар Ямалыдан Сатиевлар гаиләсенә кагылышлы мәкаләләргә еш юлыгасың. Өлкәннәре совхозда җиң сызганып эшлиләр, балалары укуда алдынгылар, барысы да үзешчән сәнгатьтә, җыр-музыкага хирыслар.

Кирам Сатиевның бертуган апасы Асия апа минем укытучым да әле. Ул безгә, бер ел гына булса да, рус әдәбиятыннан дәресләр бирде. Аның үз-үзенә һәм укучыларга булган таләпчәнлеге аеруча истә калган. Кирам Сатиевның бөтен татар дөньясына танылган музыкант булып җитлегүе ата-ана тәрбиясеннән, апа-абыйларының үрнәк йогынтысыннандыр да әле бер уйласаң.

Кирам Сатиев гармунчы булмаса, бәлки, язучы булып китәр иде. Тырышлыгы, үҗәтлеге белән генә түгел, ана сөте белән күчкән миллилеге, хислелеге, күңеленең зурлыгы белән ул әдәби иҗатта да үз урынын табар иде. Аның соңгы вакытларда кулына каләм

алуы, милләтебезнең бай хәзинәсе булган баянчыларыбыз турында китаплар язуы – моның ачык мисалы.

Мин аның белән очрашканда һәрчак: «Хәлләрең ничек, якташ?.. Күреп торам, белеп торам, булдырасың, афәрин!» – дим.

Озак еллар шулай дияргә язсын иде.

*2009*

*Кадим Нуруллин*

## ФИЛАРМОНИЯ ГОРУРЛЫГЫ

Кирам Сатиевның 50 яшьлек юбилеен Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында зурлап 2005 елның 30 ноябрендә уздырдык. Беренче очрашканда ук мин аңа бөтен чыгымнарны: афиша ясау, билетларны сату, концерт залы белән (бушка) тәэмин итү... һ.б.ларны үз өстемә алам, дидем һәм биргән вәгъдәмне намус белән үтәп чыктым. Кирам Сатиевның юбилее шаулап-гөрләп узды. Мин аны кеше буларак та, директор (җитәкче) буларак та хөрмәт итәм. К.Сатиев аңа лаек, бик тә лаек. Дөрес, ул да башкалар кебек үк йөз процентлы бәндә түгелдер, ләкин хезмәтләре белән йөздән дә артадыр. Ул гади бер музыкант. Башкаручы. Язучы түгел, китаплар авторы; композитор түгел, «Баян һәм оркестр өчен концерт» язып, үзенең юбилей концертында А.И.Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры белән үзе башкарды.

2007 елда К.Сатиев туган авылы Татар Ямалыда (Актаныш районы) үзенең музеен ачты, һәм аның исемендәге гармунчылар фестивале булды. Транспорт мәсьәләсен без хәл иттек. Саный китсәң... Санап тормыйм. Ул язган «Татар баянчылары» һәм «Ак баян» исемле китапларны укысаң, шул җитә.

*2008*

*Рәшит Мостафин*

## КИРАМ САТИЕВ – «ЭШ АТЫ»

Моннан берничә ел элек Чистай районының Яуширмә авылында Гаяз Исхакый укулары уздырыла иде. Менә шунда мин Кирам Сатиев белән якыннан таныштым – аның сәхнәдә беренче тапкыр эреле-ваклы концерт гармуннарында уйнавын күрдем һәм ишеттем. Чыгышын тәмамлагач, Кирам минем янга килде дә:

«Рәшит абый, макталырга теләмим, җитешмәгән урыннарын әйт, хаталарын төзәт», – диде. Һәм минем бәям шулай булды: «Ниһаять, безнең янга тагын бер музыкант өстәлде. Моңа бик сөенәм, татар гармунының дәвамы бар, сине арабызга алабыз», – дидем. Без өч гармунчы, өч халык артисты (дөрес, ул вакытта әле мин атказанган идем): Рәшит Мостафин, Рөстәм Вәлиев һәм юбиляр Кирам Сатиев Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында чыгыш ясадык. Бу 2005 елның 30 ноябре иде. Шуннан без Кирам белән «Пирамида»да (аны шаярып «Кирамида» дип тә әйтәләр) икәүләп тә, 30 августта, Рөстәмне кушып, өчәүләп тә чыгышлар ясадык.

...Кирамга күз күрмәгән, колак ишетмәгән канатлар үсеп чыкты. Аннары: «Рәшит абый, ярты Җир шарын үзенең моңнары белән әсир иткән синең данлыклы оркестрың белән чыгыш ясыйсым килә», – диде. Мин бик теләп риза булдым. Төрле милләт көйләренә нигезләп язылган клавирдан партитура ясап, без аны Татарстан радиосына яздык. Һәм бу әсәр хәзер төрле концерт мәйданнарында яңгырый.

Кирам Сатиев – эш аты, «трудяга». Татар гармуннарын барлауда, милли моңнарыбызны халкыбызга җиткерүдә үзеннән шактый өлеш кертә.

*2008*

*Зилә Сөнгатуллина*

## КОНСЕРВАТОРИЯ ШӘКЕРТЕ

...Хәтер йомгагымны сүтеп утырам. Егерменче гасырның 70 нче еллар азагы. В.В.Куйбышев исемендәге «Тасма» производство берләшмәсенең клубында чыгыш ясарга туры килде. Ни өчендер мин анда эшләүче легендар баянчы Рифкать Гомәровка түгел, ә яшь кенә егеткә мөрәҗәгать иттем. Казан дәүләт консерваториясе студенты Кирам Сатиев белән танышуым да, беренче тапкыр аның белән концертта чыгыш ясавым да шул көнне, шул клубта булды. Яшь башкаручы булуына да карамастан, аның үзенә генә хас булган башкару алымнары, җырчыга игътибарлы һәм ихтирамлы булуы миңа бик тә уңай йогынты ясады, һәм тамашачы безне алкышларга күмде.

Концерттан соң Кирамга: «Синнән шәп музыкант чыгачак, киләчәгең бар, тырышып укы, үз өстеңдә эшлә», – дип, хәер-фатихамны бирдем. (Дөрес, әле ул вакытта мин үзем дә әллә ни зур

эшләр майтарган Зилә түгел идем, шуңа да карамастан җыр сәнгатендә, әдәбият-сәнгать өлкәсендә бераз тәҗрибәм һәм үз урыным бар иде.)

...Бер-бер артлы еллар уза торды. Кирам, консерваторияне тәмамлагач, Совет Армиясендә хезмәт итеп кайтты да Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләвен дәвам итте. Һәм... моннан утыз еллар чамасы элек әйтелгән сүзләремне аклады: чын мәгънәсендә зур музыкантка әверелде. Ул хәзер – филармониянең, гомумән бөтен татар халкының талантлы баянчыларыннан, оста гармунчыларыннан берсе. Моның шулай икәненә мин тагын бер кат 2006 елның декабрь аенда ышандым, шаһит булдым.

Без Үзбәкстан башкаласы Ташкентка Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрен уздыруда катнашырга бардык. Татар моңнарына, чын сәнгатькә сусаган тамашачы безне чәчәкләргә, алкышларга күмде. Әлбәттә, бу концертның югары профессиональ дәрәҗәдә узуында Кирам Сатиевның да роле зур булды. Эреле-ваклы гармуннарда башкаруын аеруча яратып, сәхнәгә кабат-кабат чакырып уйнаттылар.

Музыка өлкәсендә, җыр сәнгатендә мондый төшенчәләр бар: «культура звука», «ведение звука», «культура исполнения», «характер исполнения». Тиешле вакытында мех (күрек) алыштыру, җырчыны тою-сиземләү, аның белән бергә сулыш алу... Менә болар инде шактый чыныгу алган музыкант Кирам Сатиевка хас булган нәрсәләр.

Кыскасы, мин ялгышмадым, ә Кирам Сатиев, үз чиратында, ышанычымны аклады: бүгенге көндә ул – Татарстанның халык артисты, өч тапкыр лауреат, «Татар баянчылары» һәм үзе турында үзе язган «Ак баян» исемле китаплар авторы. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендәге артистлык хезмәтен Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында укыту белән бергә алып бара...

*2007*

*Фәнүс Моратов*

## ЯКТАШЫМ КИРАМ

Кирам Сатиевның музыкант һәм баянчы булуы турында инде күп язылды һәм языла. Анысы белгечләр эше. Мин ул турыда язучылар, журналистлар кебек матур, тирән итеп яза да алмаган бу-

лыр идем. Бу фикеремне язганда мин иң беренче Рабит Батулланың «Ак баян» китабындагы язмасын күздә тотам.

Без Кирам белән якташлар, аның якташ икәнен мин инде күптән белә идем, ә инде танышканнан соң, без тиз генә дуслар булып киттек. Бу табигый хәл булды, чөнки безне бик күп уртак әйберләр берләштерә. Икебез дә күп балалы гаиләдән, авылларыбыз Татар Ямалы һәм Татар Суыксуы арасы да ун чакрым гына. Иҗат өлкәсендә дә уртак эшләребез бар. Бер-бер артлы китапларыбыз басылып тора, аннан соң мин үзем дә, Кирам кебек үк булдыра алмасам да, баянда уйнап маташам. Менә шулай бер-беребезнең уңышларына куанып, кулдан килгән кадәр ярдәм итешеп яшибез.

Кирам искиткеч гади, чиста күңелле кеше. Аның белән аралашуы да бик җиңел һәм бик рәхәт. Ә инде мәҗлестә Кирам була икән (гастрольдә булмаганда, әлбәттә инде, ул безнең белән), табын янындагы кешеләрнең аңа шатланып, сокланып һәм ләззәтләнеп утыруларын күрәм, мин үзем дә һәрвакыт куанам һәм горурланам. Кирам Сатиевны халык бик ярата, шул ук вакытта шунысы куанычлы: ул республика җитәкчелеге игътибарыннан да читтә калмый, аның 50 яшь тулу уңаеннан булган юбилей кичәсе Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе залында бик зурлап уздырылды. Кирам Сатиевка «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Бу мактаулы исемгә, бу хөрмәткә Кирам артист буларак та, кеше буларак та, әлбәттә, лаек. Без, якташ дуслары, аның өчен бик шат, аңа киләчәктә дә күпкырлы иҗатында яңадан-яңа уңышлар, озын гомер һәм нык сәламәтлек телибез.

*2007*

*Вера Минкина*

## МАРСЕЛЬНЕҢ ИҢ ЯРАТКАН БАЯНЧЫСЫ

2001 елның 15 феврале иде. Илһам Шакировның чираттагы туган көн концерты безнең Г.Камал исемендәге театрның кече залында булды. Кичәне язучы Рабит Батулла алып барды. Концерт беткәч, Марсель Хәкимович, Кирам Сатиевка мөрәҗәгать итеп: «Тукта, әйтер сүзем бар, – диде. – Син бүгенге көндә Татарстанның, бөтен татар халкының иң зур, иң оста баянчысы...» Кирам Сатиев, оялып кына: «Иң оста баянчыларыннан берсе дисәгез дөресрәк булмас микән», – дип әйтергә батырчылык итте. Мар-

сель: «Мине бүлдермә, һәрвакыт уйлап сөйлим, үз сүзләрем өчен җавап бирәм: син – иң оста баянчы. Мин моны Марсель Сәлимҗанов буларак, әдәбият-сәнгатьне бераз аңлаган кеше буларак әйтәм. Бүген синең Илһам Шакировка уйнавыңны концертның башыннан азагына кадәр игътибар белән, йотылып, онытылып тыңладым...» Һәм СССРның халык артисты Марсель Хәким улы Сәлимҗанов Кирам Сатиевның кулларын кысып, аңа иҗат юлында уңышлар теләде...

...Һәм... кем уйлаган. Күп тә үтми Марсель Сәлимҗанов арабыздан мәңгелеккә китеп тә барды. Аның бу сүзләрен мин һәм минем янымдагы берничә кеше ишетеп торды. Бөек шәхесебезнең бу фикерләрен киләсе китабыма ничек кертик икән дип, Кирам Сатиев миңа мөрәҗәгать итте. Мин инде ялган сөйләмим, ничек бар, шулай яздым. Марсель Сәлимҗанов өчен имзамны куйсам, гөнаһ булмас һәм сез дә, кадерле укучыларым, минем белән килешерсез дип уйлыйм.

*2007*

*Миңгол Галиев*

## «БАЯНЫҢ ҺӘРЧАК ЧЫҢЛАП ТОРСЫН»

Егерменче гасырның 70 нче еллар азагында Казан шәһәренең Бауман урамы, 60 нчы йортта урнашкан Татарстанның хор җәмгыятендә миңа җаваплы секретарь булып эшләргә туры килде. «Сәрвиназ» вокаль-ансамблендә (җитәкчесе Мәсгут Имашев) концертмейстер вазифаларын башкаручы Казан дәүләт консерваториясе студенты Кирам Сатиевны безгә методист булып эшләргә тәкъдим иттеләр. Без бик теләп риза булдык. Аның белән радиога җырлар яздык. Ул вакытта хор җәмгыятендә композитор, скрипкада уйнау остасы Әнвәр Бакиров та эшли иде. Без өчәүләп концертларда катнаштык, яшь буынның киләчәген кайгыртып, аларда музыкага мәхәббәт тәрбияләп, мәктәпләрдә, тулай торакларда, балалар бакчаларында чыгышлар ясадык. Ә 1978 елның февраль аенда (Кирам ул вакытта консерваториянең бишенче курс студенты) Пермь өлкәсендә гастрольләрдә булдык. Пермь шәһәренең үзендә дә берничә концерт куйдык, һәм йомгаклау концерты цирк бинасында булды. Профессиональ сәхнәдә Кирам беренче адымнарын безнең белән башлады. Һәм мин яшь музыкантның истәлекләр дәфтәренә мондый сүзләр яздым: «Пермь циркында беренче мәртәбә Татар опера һәм балет театры артистлары соста-

вында концертта катнашш пермьлеләр белән таныштым. Алкышларны рәхәтләнеп сиңа бүләк итәм. Баяның һәрчак чыңлап торсын. Ихтирам белән, иҗади уңышлар теләп, Миңгол Галиев».

*1978*

*Халит Фатыйхов*

## ДУСТЫМ, ИҖАТТАШЫМ

Беренче мәртәбә Кирам Сатиев белән кайда һәм кайчан очрашканбыздыр – хәтерләмим. Ә менә соңгысы (соңгысы булмасын, Аллам сакласын) 2007 елның 23 ноябрендә булды. Без улым Айнур белән, Ә Кирам Рөстәм Вәлиев белән Мәскәү шәһәренең Кремльдәге Съездлар сараенда чыгыш ясадык. Бу концерт Г.Заволокин исемендәге «Играй, гармонь» дип аталган Россия үзәгенең юбилее уңаеннан булды. Без – Башкортстанның, ә Кирам белән Рөстәм Татарстанның данын якладык һәм республика җитәкчеләренең ышанычын акладык.

Яхшы гармунчылар Кремльдә (урамда), ә бик яхшылары Съездлар сараеның фойесында, ә инде бик тә осталары (ягъни без, мактану булмасын) сәхнәсендә чыгыш ясадык. Концертта барлыгы утыз алты номер иде. Без – уникенче, ә Кирам белән Рөстәм дуэты егерме икенче булып уйнадык. Концертта катнашкан берничә данлыклы коллективны атап узам: Кубаньнан казаклар хоры, Чечнядан «Вайнах» дип аталган Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Якутия (Саха) Республикасы артистлары, Урал, Себер, Мордовия, Удмуртиядән һәм Россиянең төрле өлкәләреннән килгән талантлар, Молдавиядән һәм Украинадан артистлар катнашты. Алты меңлек тамаша залы шыгрым тулы иде. Концерт югары профессиональ дәрәҗәдә «на ура» узды...

Нәрсә бәйли соң безне Кирам Сатиев белән? Иң беренче – сәнгать. Икенчесе – без якташлар. Безне Агыйдел елгасы гына аерып тора, бәлки, «аера» сүзе дөрес тә түгелдер, ул безне берләштерә торгандыр. Мин – Башкортстанның Илеш егете, ә Кирам – Татарстанның Актаныш районыннан. Икебез дә үз республикаларыбызның халык артистлары.

Берничә ел рәттән без, Башкортстан әдәбият-сәнгать осталары, җәйге ял вакытында теплоходта Татарстанга сәяхәт кыла идек, су корабын Изге Болгар җирендә туктатып, Татарстан артистлары белән теплоход эчендә дуслык концертлары күрсәтә идек. Тугандаш ике республиканың бу изге гамәле әле һаман да дәвам итә

һәм итсен иде. Ут күршеләр белән дус һәм тату мөгамәләдә яшәү үзе нинди зур бәхет! Җырларыбыз, моңнарыбыз уртак, телләребез дә бер-берсенә бик якын. Бу изге һәм файдалы сәяхәтләрдә катнашкан әдәбият-сәнгать осталарының (әһелләренең) исем-фамилияләрен язып тормыйм, чөнки ул болай да аңлашыла... Сүз башым шүрәле дигәндәй, язмам Кирам Сатиев турында.

Кирамның иҗатын һәм тормыш юлын яктыртып озын һәм нәтиҗәле итеп язарга була һәм кирәктер дә. Ләкин, кыскалыкта – осталык дигән принциптан чыгып, сүземне кыска тотам һәм язмамны йомгаклыйм. Кирам Сатиевка – иҗади дустыма, якташыма, коллегама – зур уңышлар һәм корычтай нык сәламәтлек телим. Киләчәктә дә безне берләштергән Агыйделдә генә түгел, ә әдәбият-сәнгатьнең диңгезләрендә, океаннарында бергә йөзик... Амин!

*2007*

## МӘСКӘҮ КРЕМЛЕНДӘ – ТАТАР МОҢНАРЫ

Виртуоз баянчыларыбыз Кирам Сатиев белән Рөстәм Вәлиев Мәскәү Кремленең Съездлар сараенда тамашачыны татар моңнарына әсир итте. Алар Геннадий Заволокин исемендәге «Играй, гармонь» дип аталган тапшыруның юбилей концертына барганнар иде. Анда элеккеге Советлар иленең төрле төбәкләреннән гармунда уйнау осталары җыелган булган. «Играй, гармонь» тапшыруы эфирга чыга башлавының 20 еллыгы безнең филармониянең 70 еллыгы көннәренә туры килде. «Без сәнгатькәрләргә бу хакта да әйтеп үттек, һәм бик күпләр безнең филармония эшчәнлеге белән шактый ук таныш булуларын, җырчылар, баянчылар осталыгын олы бәяләүләрен җиткерделәр», – дип шатлыгын уртаклашты Кирам Сатиев.

*«Ватаным Татарстан», 2007, 12 декабрь*

*Айрат Бариев*

## КИРАМ САТИЕВ МУЗЕЙЛЫ БУЛДЫ

27 октябрьдә Актаныш районының Татар Ямалы авылы клубында Татарстанның халык артисты, танылган гармунчы Кирам Сатиев музее ачылды. Ул – үзе исән вакытта музее булдырылган дүртенче татар.

Музей ачу тантанасына Казан, Актаныш, күрше авыллардан кеше күп җыелган иде. Кунакларны «Чиялек» ширкәте җитәкчесе Хәмзә Гыйльметдинов, авыл советы башлыгы Мулланур Салихҗанов, урта мәктәп директоры Марат Гыйльметдинов, авыл мәдәният йорты директоры Дәвир Галиев хөрмәт, якты йөз белән каршы алды. Алар музейны оештыруда күп көч куйган кешеләр. Дәвир Галиев әлеге эшне башлап йөргән, музей өчен авылдан әйберләр җыйган.

Музейга Кирам Сатиевның концерт костюмнары, баяны, гармуннары куелган. Шулай ук төрле елларда басылган концерт афишалары да зәвык белән эленгән. Кирам әфәнде музейда авыл тарихын, сугышта Ватан азатлыгы өчен һәлак булганнарны һәм башка кешеләрне дә яктырткан бүлек ачу турында хыяллана.

Музей ачылышыннан соң Кирам Сатиев исемендәге гармунчылар фестивале башланды. Ул җыр-бию, юмор-сатира белән үрелеп барды. Һәр гармунчыны халык гөр килеп каршы алды, алкышлады. Кирам ага үзе дә төрле гармуннарда, баянда уйнап, тамашачыны куандырды. «Гармунда Казанда да, чит илдә дә уйнарга була. Ә минә туган авылың сәхнәсендә уйнавы иң авыры. Чөнки монда сине якыннан беләләр», – диде ул соңыннан.

Бәйрәм ахырында Кирам Сатиев Президентка, Актаныш районы хакимиятенә һәм мәдәният бүлегенә, авыл халкына зур рәхмәтен җиткерде. Шулай итеп Татар Ямалыда Кирам Сатиевны гына түгел, татар гармунын, гармунчыны хөрмәтләгән беренче музей үз ишекләрен ачты.

*«Ирек мәйданы», 2007, 9 ноябрь*

*Хәлим Гайнуллин, Габделбәр Ризванов*

## ЛЕНИНГРАДТА – ТАТАР ҖЫРЛАРЫ

Татарстан сәнгать осталарының герой-шәһәр Ленинградтагы гастрольләре зур уңыш белән узды.

...Музыкаль оформлениене Татарстанның атказанган артисты Рәшит Мостафин, яшь композитор Фәрит Хатыйпов, баянчылар Кирам Сатиев, Нәсих Вильданов һәм «Идел киңлекләре» инструменталь ансамбле членнары югары дәрәҗәдә башкардылар...

*«Социалистик Татарстан», 1983, 3 июнь*

*Габделбәр Ризванов*

## СУРГУТ КАЙНАРЛЫГЫ

*(Төмән өлкәсенең Сургут шәһәрендә Татарстан мәдәнияте көннәре)*

Үткән атнада Сургут шәһәрендә Татарстан мәдәнияте көннәре үткәрелде.

Ул шәһәрнең меңнән артык тамашачысына исәпләнгән «Энергетик» мәдәният сараенда «Җырлыйк әле, биик әле дуслар күңеле булганчы» дип исемләнгән концерт-тамаша белән башланып китте.

Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева, Рафаэль Ильясов, Кирам Сатиев, Резеда Төхвәтуллина һәм К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының күренекле артистлары өч сәгать дәвамында тамашачыга моң, дәртле бию, сатира-юмор әсәрләре бүләк иттеләр...

*«Ватаным Татарстан», 1995, 27 октябрь*

*Марат Әхмәтов*

## МОСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ

Без – Себерне, Себер безне җылытты.

...Танылган баянчыбыз Кирам Сатиев та концертның гүзәл бер бизәге булды. Кирам әфәнде, җырчының тавышына, һәр хәрәкәтенә оста ияреп, матур, төгәл ансамбль тудыруга иреште. Мин үзем дә, аның белән бергә сагыш-моң тулы борынгы «Тәфтиләү»не халыкка җиткергәндә, Кирамның гаҗәеп сизгер музыкант икәненә тагын бер кат ышандым...

*«Мәдәни җомга», 1997, 31 гыйнвар*

*Илдус Илдарханов*

## САЛКЫН ДИҢГЕЗ БУЕН ҖЫЛЫТУ

Казанлылар үткән якшәмбедә, меңьеллык тарихыбызда беренче тапкыр буларак, Архангельск сабан туенда катнашты. ...Баянчы Кирам Сатиевка кушылып, бу якларның сәхнә йолдызы Рим Кәлимуллин җыр сузды...

*«Шәһри Казан», 2000, 5 июль*

*А.Александров*

## СӘХНӘ ӨЧЕН ТУГАН ТАЛАНТ

...Раушания Сәүбәнова концертына килгәч, тамашачының күп булуын күреп гаҗәпләндем. Ник дисәң, Раушания – районыбызга моннан бер ел чамасы элек кенә килгән кеше. Шуңа да карамастан җыр-моң сөючеләрнең күңелен яулап өлгергән икән бит. Яратып, үз итеп килгән халык.

Виртуоз башкаручы Кирам Сатиев, олы баяннан алып уч төбенә сыярлык уен коралларында төрле җырлардан тезмә башкарып, тамашачыны шаккатырды. Бар бит дөньяда сәләтле шәхесләр!

*«Алга» (Питрәч), 2002, 25 декабрь*

*Зарина Нигметова*

## САБАНТУЙ ВМЕСТЕ С «ОТАНОМ»

Впервые столица стала центром празднования республиканского Сабантуя... Поздравить соплеменников приехали гости из Казани. Народные артисты Татарстана Резеда Галимова, Георгий Ибушев и Кирам Сатиев подготовили интересную концертную программу...

*«Казахстанская правда», 2004, 6 июля*

*Гөлүсә Закирова*

## ТАТАРНЫҢ МОҢЛЫ БАЛАСЫ

...Күптән түгел генә җырлы-моңлы Актаныш төбәгендә, Кирам абыйның туган авылы Татар Ямалы авылында гармунчылар фестивале булып үткән. Үзе дә сәхнәләрдә биеп тамашачы күңелен яулаган район башлыгы Энгель Фәттахов баянчыга Кирам Сатиев исемендәге гармунчылар фестивален уздырырга тәкъдим итә. Баштарак юл ераклыгыннан аптырабрак калган баянчыга филармония директоры Кадим Нуруллин ярдәмгә килә, транспорт белән тәэмин итеп канатландырып җибәрә.

Актанышта Кирам Сатиевны бик зурлаганнар икән бит. Фестиваль үткән көннәрдә туган авылы Татар Ямалыда аның исемендәге музей да ачылган. «Ак баян» исемле китабы, концертларының егермеләп афишасы, Советлар Союзы буйлап гастрольдә йөргәндә төшкән истәлек фотолары урын алган анда.

– Исән чакта кешегә музей кирәкме икән дип әйтергә телисезме? Бу хакта мин дә уйландым, – ди Кирам Сатиев. – Сибгат ага Хәким үзе исән чакта туган авылы Күлле Кимедә музее эшли иде инде. Аннары Илһам ага Шакировның да Яңа Бүләк авылында музее бар. Апас төбәгендә (Бакырчы авылы) Шәүкәт абый Галиев музее эшли бит.

– Безнең күчеш чорлары күп булды, татар халкы яшәгәндә, моң үлми, моң яшәгәндә, татар халкы яшәячәк. Моң безнең милләтебезне саклап килде.

*«Мәгърифәт», 2007, 10 ноябрь*

*Илнар Хөснуллин*

## ТӨРКИЯДӘ

Сабантуйны милли дип атасак та, ул инде халыкара бәйрәмгә әйләнеп бара. Хәзер ул, Татарстан һәм Россия төбәкләре кысаларыннан чыгып, чит илләрдә дә оештырыла башлады. Милләттәшләребез белән бергә сабантуйда башка халыклар да катнаша. Быел мондый бәйрәмнәрнең беренчесе Төркиянең иң зур шәһәре Истанбулда үтте.

...Әмма ничек кенә булмасын, бу бәйрәм Татарстан ярдәменнән башка үтә алмый. Быел да республикабыздан Төркия сабан туена бер төркем сәнгать осталары, ТР мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров җитәкчелегендә җырчылар Резеда Галимова, Айдар Габдинов, биючеләр Рәйсәнә Насифуллина, Рамил Шәйдуллин һәм танылган баянчы Кирам Сатиев та барып кайтты. Алар, андагы бәйрәмне тагын да ямьләндереп, милләттәшләребезне сөендерделәр.

Истанбулда үткән сабантуйда Төркиядәге Россия һәм Украина илчелекләре вәкилләре, Россиянең Сәүдә вәкиллеге хезмәткәрләре, Татарстанда эшләүче төрек ширкәтләре җитәкчеләре дә катнашкан. Бәйрәмдә исә Татарстанның Төркиядәге Сәүдә һәм икътисади вәкиллеге оештырган сабантуйда Татарстаннан тагын бер

хөрмәтле кунак – ТР Диния нәзарәте рәисе, мөфти Госман хәзрәт Исхакый да катнашкан.

*«Ватаным Татарстан», 2004, 12 июнь*

*Мәсгут Имашев*

## ТАЛАНТЛАР КАНАТ ЧЫГАРГАН УКУ ЙОРТЫ

Мәшһүр композитор Фәрит Яруллин исемен йөрткән Әлмәт музыка училищесы күптән түгел үзенең 40 еллыгын билгеләп үтте.

Ләкин һәр уку йортының эш нәтиҗәсе – аның укучыларының югары үрләр яулавы. Әлмәт музыка училищесының данын арттыручы шәкертләреннән берничәсен генә атап китү дә аның 40 ел дәвамында ничек эшләвен күрсәтеп тора. Алар арасында ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлагач, 10 елдан артык шушы үзе укып чыккан училищеның директоры булып эшләгән, халыкара конкурслар лауреаты, ТРның атказанган артисты, Казан консерваториясе доценты Әбүзәр Фәйзуллин; ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Әлмәттәге 1нче балалар музыка мәктәбе директоры, композитор Рәис Нәгыймов; баянчы, композитор, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Илгиз Закиров; җырчы, ТРның халык артисткасы Галина Казанцева; композитор, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Вәсим Әхмәтшин; баянчы, ТРның атказанган артисты, Фәйзулла Туишев исемендәге бүләк лауреаты Кирам Сатиев.

Мәдәният һәм сәнгать университеты укытучылары арасында да әлеге уку йортын тәмамлаучылар күп. Бу мәктәптә укып чыгучылар арасыннан мәдәният өлкәсендә җитәкче булып эшләүчеләр дә аз түгел. Шуларның берсе – «Яңа Гасыр» радиосының студия директоры Ләйлә Монасыйпова.

40 ел дәвамында училище 1400 дән артык яшь музыкант тәрбияләп чыгарган. Бүген анда 52 укытучы белем бирә. 1964 елда яңа училищеда белем бирергә дип безне, шушы елны Казан консерваториясен тәмамлаган 6 студентны, Әлмәткә җибәрделәр. Аларның исемнәрен дә атап китим: Диләрә Әлимбәк (фортепиано), Ольга Говрова (музыка белгече), Мәсгут Имашев (вокал), Тамара Тимошина (хор дирижеры), Ильяс Шәрипов (баян), Виктор Чепкасов (хор дирижеры). Хәзерге вакытта училище Татарстанның Кама аръягында музыкаль мәдәният, музыкаль мәгърифәт үзәге булып үсә. Ул концертлар, фестивальләр, конкурслар, семинар-

лар, конференцияләр – ел саен йөзәрләгән музыкаль чаралар үткәрелә бирелә. Киләчәктә дә шулай булсын, яшь талантлар табылып торсын.

*«Шәһри Казан», 2004, 23 апрель*

*Ривкат Азиханов*

## ПЕСНИ, МОНОЛОГИ, СТИХИ...

На днях любители татарской песни в Ташкенте и Гулистане имели возможность встретиться с замечательной певицей из Казани Вафирой Гиззатуллиной. Ее пригласило Постоянное представительство Татарстана в Узбекистане. Народная артистка Татарстана и Каракалпакстана, лауреат различных международных конкурсов, певица не раз бывала в нашей республике. В 1980 году она принимала участие в Декаде культуры и искусства Татарстана в Каракалпакстане – присвоение ей там почетного звания говорит само за себя.

Нынешние концерты, которые прошли в Ташкентском государственном музыкальном театре имени Мукими и Гулистанском музыкальном драматическом театре имени Алима Ходжаева были тепло встречены зрителями.

Аккомпанировал им известный казанский баянист, заслуженный артист Республики Татарстан, лауреат премии имени Файзуллы Туишева Кирам Сатиев. Он не только большой мастер игры на этом музыкальном инструменте, но и автор книги «Татарские баянисты», которая выпущена в свет Таткнигоиздатом в Казани.

*«Правда Востока» (Ташкент), 1995, 14 июля*

*Рафаэль Җаббаров*

## КУРАМША, КИРАМША ҺӘМ К⁰

*(«К» хәрефенә багышланган сүзләрдән хикәя)*

Курамша, Кирамша, күркәм концерт куйгач, «Кольцо»дагы кунакханәгә китәләр. Кунакханәдә кызыл катык кабалар. Курамша Кирамшага катыкның «катырагын» Камалга кереп кабарга кыстый. «Катысын» капкач, Курамша, Кирамша, Камал «Кыстыбый» кафесына керәләр. Кабан күлендә колачлап коеналар, коенгач, Кирамша Курамшаны кайтырга кыстый. Кайтып китәләр.

Кайтышлый «Казан» кунакханәсенә дә кагылалар. Кабарга каклаган каз. Кесәләре калын. Кунакханәдә «Кремлевская»ны кәгәләр. Кәгә-кәгә кызаргач, кайтканда, Кремльгә карап, Казансуга коенырга китәләр. Көймәләр күп. Күп күбен, кайсысына керергә? Килүче-китүчеләр күренми, күңелсез. Көймәгә кергәндә, Курамша «Карурман»ны көйли. «Карурман» көе Казансу кунакларын, Казан каласы кешеләрен куандыра. Курамша, Кремльгә карап, кырыс кына кычкырып куя: «Кирамша, кара, кайчандыр Казанда кан койган кан кардәшләребезне кырганнар. Күпме кешеләр кайгы кичергән. Кабат кан коелмасын. Корбаннар кабат кирәкми».

Курамшага Кичкетаңнан кунаклар килгән. Күрешкәч, күңелен күтәргәч кайтып китәләр. Кайтканда, кызлар күзләп кайталар. Кара куртка, кызыл колготкилар кигән кара күзле кыз-кыркыннар Курамшага, Кирамшага күз кысалар. Курамша, кыйгач каплы кызларны күрмәгәндәй кыланып, Кирамшаны кайтырга кыстый. Күңелсезләнеп кайталар. Кружкалары кулларда. Кабарга Кочкадан килгән каклаган казылык куелган. Курамша кеткелди: «Күтәрик кружкаларны кан кардәшләр».

*«Мәдәни җомга», 1996, 5 гыйнвар*

*Хәсән Сатиев*

## УЛ – ГАИЛӘБЕЗ ГОРУРЛЫГЫ

Татарстанның халык артисты, абыем Кирам Сатиев турында матбугатта күп мактау сүзләре язылды. Минем дә боларга өстәп бер-ике фикер әйтәсем килә. Ул – банкир да, бандит та (Аллага шөкер) түгел, ә гап-гади баянчы. Башка күп баянчылар кебек, менә утыз ел инде армый-талмый бөтен төрки халыкларына хезмәт итә. Минем үземә дә 1997–1998 елларда халкыбызның сөекле җырчысы Габдулла Рәхимкулов бригадасында администратор булып эшләргә насыйп булды. Бу бригадада талантлы җырчы Резидә Төхвәтуллина, алып баручылар Рәшит Шамкай, Равил Шәрәфи һәм, әлбәттә, баянчы-аккомпаниатор Кирам Сатиевлар белән Татарстанның төрле районнарында концертлар оештырып йөрдек. Әлеге шәхесләр арасында ярдәмче ролендә йөргән кеше буларак, нидер әйтергә хакым бар дип саныйм.

Кирамның оста һәм һәр җырчыга ярашлы итеп, яхшы дуэт ясап уйнавыннан тыш үзенчәлеге нәрсәдә соң? Иң беренчесе – чарага (ул репетицияме, җыелышып сөйләшүме яки концертның үземе)

соңга калмау, билгеләнгән урынга вакытында килеп җитү. Хәләл акчасын түләп ял итәргә килгән халыкны көттереп зарыктыру гафу ителмәслек гаеп дип саныйм мин. Кирамда бу әйбер юк. Моны миңа хәтле бер акыллы кеше инде әйткән булса да, сүз уңаеннан мин дә кабатлыйм: «Хөрмәтле артистлар, сез халыкка җыр бүләк итмисез, ә бәлки билет алып кереп утырган тамашачыга бурычыгызны гына түлисез». Менә шул бурычны Кирам Сатиев һәрдаим җиренә җиткереп кайтарырга тырыша.

Икенче ихтирамга лаеклы сыйфаты – ул даими рәвештә үз өстендә эшли. Хәзерге «ашыгыч» заманда ун-унбиш минут очрашкан арада, телефоннан (бигрәк тә кәрәзле телефоннан) сөйләшкәндә дә ул үзенең сәнгать күгендәниләр майтарып йөргәнен әйтеп калырга ашыга. Санап китсәң, аның бу өлкәдә эшләгән эшләре байтак, әмма мин үз тарафымнан аларны барлауны артык санап, тыйнаклык саклап калыйм әле.

Дөрес, сәнгатькә, һәм инде курыкмыйча әйтә алам, язу-сызу эшенә бирелгәнлек материаль яктан аңа зур керемнәр бирмәде, әлбәттә. Тиз кабынып сүнүче «йолдызлар» кебек, «өр-яңа» альбомнар (гәрчә тыңлаучының әле искесен дә ишеткәне булмаса да) да чыгармады.

Әмма музыка-моңга битараф булмаган татар җанлы кешеләр белән сөйләшкән-танышкан вакытларда күп очракта «Син атаклы баянчы Кирам Сатиевның бертуган энесеме?» дигән сорау миңа горурлык хисләре өсти. Менә шунда «әйе» дип җавап биргәндә, аның халыкка танылуы аркасында мине танулары яшәргә дәрт бирә.

Язмамны йомгаклап, Кирамга барлык туганнар исеменнән зур рәхмәтемне белдерәм. Аңа иҗатында яңадан-яңа уңышлар, тормышында исәнлек-саулык, гаиләсенә иминлек телим.

*2008*

*Җәмил Шәфигуллин*

## АК БАЯНГА МӘДХИЯ!

**С**атиулла иген иккән, дуга бөккән!
**А**ларда юк эш сөймәгән, киребеткән.
**Т**альян тарткан эштән бераз бушаганда,
**И**мән кебек нык тамырлы бу нәселдә
**Е**гетләрнең гаярьләре, шәпләре,
**В**акланмаган бит нәсел дә, син күр әле!

**К**ираметдин, син – нәселнең дәвамчысы,
**И**р-атның син пәһлеваны һәм солтаны,
**Р**әхмәт синең бабаңнарга, моңлы җаннар,
**А**к баянга аклык булып күчкән җаннар –
**М**әхмүт бабай, Нәбиулла, Шәйхиҗаннар!

**Ш**әҗәрәсен белгән нәсел мәңге яшәр.
**Ә**йдә, улым, уйна, өйрән дигәннәргә
**Й**әгез әле изге җаннар өчен дога.
**Х**әсәннәр дә бар нәселдә Туфан кебек,
**И**лһамнары, Хәнәвиләр, Әлфияләр
**Җ**ыр иленә алып кергән Туфан булып.

**А**ктанышның ал таңнарын, Агыйделен
**Н**асыйп булсын гел күрергә,
синдә калам туфрак булып!
**У**зып бара гомерләр дә, – инде көзгә!
**Л**әкин әле баян бар бит, варис безгә!
**Ы**шаныгыз, мин хезмәттә һаман сезгә!

## ШӘҖӘРӘ

Сатиулла,
Нәбиулла,
Зиммөхәммәт,
Бикмөхәммәт,
Мәхмүт,
Шәйхиҗан,
Кираметдин.

Ак баянда берәү уйный, –
Менә кайда чын сәнгать.
Ул моң аның әнисеннән,
Ә әнисе – Сәгадәт!

Шигърияттә мәйдан тоткан
Ап-ак чәчле Хәсән Туфан.
Җыр илендә ак баянлы
Сатиевлар, Хәсән туган.

# ТАТАР ГАРМУНЫ АМЕРИКАНЫ ЯУЛАДЫ

Күптән түгел бер төркем сәнгать әһелләре Америкада булып кайтты. Алар арасында Татарстанның халык артисты, күренекле баянчы Кирам Сатиев та бар иде.

*– Татарстаныбызга исән-сау кайтуыгыз белән сезне!*

– Рәхмәт. Дөрестән дә, аннан исән-имин әйләнеп кайтуны мин үземә күрә бер батырлык дип әйтер идем. Чөнки, үзегез беләсез, кайсыдыр штатны су баса, кайсындадыр янгыннар, гарасат, кайбер биек өйләргә самолетлар бәрелә...

*– Кайсы шәһәрләрдә булдыгыз?*

– Сан-Францискода, Вашингтонда, Нью-Йоркта.

*– Сәфәрегезнең максаты?*

– Югарыда аталган шәһәрләрдә концертлар куйдык, ә баруыбызның төп максаты – Сан-Францискодагы сабан туенда катнашу.

*– Америка җирендә бу беренче сабан туе диләр. Шул дөресме?*

– Дөрес. Хөкүмәт күләмендә, дөньякүләм уздырылган сабан туеның бу беренчесе. Ышанам, 2008 елның 13 июле тарихка кереп калыр.

*– Дөньякүләм дигән сүз ычкындырдыгыз...*

– Ычкындырмадым, уйлап әйттем, чөнки бу сабан туена бөтен Җир шарыннан килгәннәр иде: Япониядән, Кытайдан, Аурупа илләреннән, Африкадан, Австралиядән, Аргентинадан һ.б. кыйтгалардан.

*– Америка, белгәнебезчә, океан артында. Анда ике генә транспорт йөри: йә су, яки һава юлы. Самолетта озак очтыгызмы?*

– Океан аркылы – 11 сәгать. Атланта шәһәрендә икенче самолетка күчеп утырып, тагын 6 сәгать очтык, Сан-Францискога – Тын океан ярларына. Шторм булу сәбәпле, Атланта кабул итмәде, бер сәгать Америка өстендә очып йөрдек. Җил-давыл тынгач, төшеп утырдык. Җәмгысы 18 сәгать һавада булдык. Кыскасы, 10 көндә 5 самолетта очтык һәм ике океанда булдык, ә Тын океанда су коендык.

*– Курыкмадыгызмы?*

– Нинди генә каһарман булсаң да, океан өстеннән 11 сәгать очу шикләндерә.

*– Сабан туенда сезне ничек каршыладылар?*

– Ипи-тоз белән. Зурлап, олылап. Үзебезнең милләттәшләребез татарлар һәм шунда яшәүче башка милләт кешеләре.

*– Ә чыгышларыгызны ничек кабул иттеләр?*

– Ничек диләр әле, «на ура». Америка тамашачылары өчен татар гармуннары күтелмәгән һәм тансык уен коралы икән. Дөресен әйтим, сәхнәдән чыгармыйлар! Рөстәм Вәлиев белән алмашлап уйнадык һәм бергә дә: ул – баянда, мин – гармуннарда, мин – баянда, ул – гармунда...

*– Сез, Америкага барып, Татарстан һәм Русиянең данын яклап, җитәкчеләрнең ышанычын аклап кайттыгыз. Моның өчен зур дәрәҗәдә башкару осталыгы кирәктер бит...*

– Икебез дә Татарстанның халык артистлары; төрле елларда Ф.Туишев исемендәге конкурс лауреатлары. Өстәвенә без Рөстәм белән 2007 елда Мәскәү шәһәрендә, Кремльнең Съездлар сарае залында Бөтенрусия һәм БДБ күләмендә уздырылган Г.Заволокин исемендәге «Играй, гармонь» конкурсының юбилей концертында катнашып, «Иң оста ун гармунчы» дигән исемлеккә кереп җиңү яулаган идек. Ә инде сабантуйга татар баянчы-гармунчыларының баруы табигый хәл. Менә шушы ике күрсәткеч безнең татар моңнарыбызны океан артындагы ерак Америка континентында яңгыратырга мөмкинлек бирде.

*– Сезнең белән тагын кемнәр барды?*

– Җырчылар Георгий Ибушев һәм Резеда Галимова. Алар безнең белән бер сәхнәдә чыгыш ясадылар.

*– Әңгәмәбезнең ахырында традицион сорау бирәм: алдагы планнарыгыз нинди, тагын кайларга сәфәр кылырга уйлыйсыз?*

– Барырга урын калмады. Америка ул – Җир шарының башкаласы, диләр (столица мира). Айга менеп уйнасак кына инде. Яки башка берәр планетага...

*– Димәк, Кирам әфәнде, сез Рөстәм Вәлиев белән иң биек үрне яуладыгыз. Дөрес аңлаган булсам, сезгә, имеш, шаяртып, Американың атказанган артистлары, дип әйтәләр икән...*

– Анысы дөрес. Ләкин Америкада, кызганыч ки, әллә киресенчәме, андый мактаулы исемнәр юк. Әлбәттә, «Американың атказанган артисты» дигән исем шәп булыр иде булуын. Ләкин без бит сабыр һәм тыйнак кешеләр, безгә «Россиянең атказанган артисты» да ярап торыр иде, чөнки «СССРның халык артисты»на без бераз соңга калдык...

*«Мәдәни җомга», 2008, 1 август*
*Әңгәмәдәш – Алсу Хәсәнова*

## КИТАП ТА ЯЗА, КӨЙ ДӘ, ЯШИ ШУЛАЙ БЕР КӨЙГӘ

*– Кирам әфәнде, соңгы вакытта матбугат битләрендә сирәк күренәсез. Сәбәп нәрсәдә?*

– Бөтен гомерем ризыклык акча эзләп үтә дисәм, зарлану булыр! Әле шушы арада гына Уфадан кайтып төштем, Фидан Гафаров белән эшләп алдык. Аның кемлеген барыбыз белә: Россия, Башкортстан һәм Татарстанның халык артисты.

Күрешкәч үк ул: «Миңа моң кирәк!» – диде. Үзенә дә, башка артистларга да бик таләпчән шәхес. Моң мәсьәләсендә исә бу якларда чишмә булып ага ул! Уфа да, туган авылым Татар Ямалы да Агыйдел буена урнашкан. Бер үк суны эчеп, бер үк кошлар сайравын тыңлап үстек, чөнки Фидан абыйның туган төбәге дә Агыйдел буенда – Дүртөйле районында бит ул.

*– Анда ничек барып чыгарга булдыгыз?*

– Уфага Илһам Шакиров белән «Шәрык» радиосының юбилеена барган идек. Безне тамашачылар бик җылы кабул итте. «Илһам» сүзен ишеткәч, Нефтьчеләр мәдәният сараендагылар аягүрә басып бик озак алкышладылар.

Шунда мине Башкортстанга, Фидан Гафаров концертына чакырдылар. Киткәндә Фидан Сафа улы тиздән бергәләп Себергә барачагыбызны әйтте, Уфада кабат очрашуны көтеп калды.

*– Соңгы вакытта еш кына Илһам Шакиров белән чыгышлар ясый башладыгыз...*

– Аллага шөкер, гел эшләп торабыз. Артка таба санасак, 23 февральдә филармониянең концерт залында, 15 февральдә Татар дәүләт академия театрында Илһам аганың туган көненә багышланган концерт булды. Татарстан районнарындагыларын санап тормыйм. Сентябрьдә Оренбургта, аның алдыннан Түбән Новгородта булдык. Ә Мәскәүнең П.И.Чайковский исемендәге Концерт залындагы чыгыштан Илһам ага белән Татарстанга «Алтын Аполлон» премиясе алып кайттык. Россия күләмендә уздырылган бу бәйгедә Кара диңгез флоты ансамбле, Якутия-Саха Республикасы, Санкт-Петербург, Мәскәү, Түбән Новгород сәнгать осталары катнашты.

*– Алдагы планнарыгыз турында да әйтеп үтсәгез иде.*

– «Татар баянчылары»ның авторы буларак, халык соравы буенча аның икенче томын матбугатка әзерләү, баян һәм оркестр өчен язылган «Агыйдел буенда» исемле күләмле әсәремне радио

һәм телевидение өчен әзерләү белән мәшгульмен. Алла боерса, тиздән «Без, без, без идек...» дигән җыр китабым да басылып чыгачак. Рөстәм Вәлиевнең «Тальянда һәм хромкада уйнарга өйрән», «Баян өчен татар халык көйләре эшкәртмәләре» дигән җыентыкларын эшкәртүдә үземнең хәләл көчемне (Татарстан мәдәният министры И.Тарханов, музыка мәктәбе директоры А.Имаев белән бергә) куйдым. Ә китапларның җаваплы мөхәррире консерватория буенча курсташым, фольклор үзәге директоры К.Хөснуллин булды.

*– Ә концерт эшчәнлегенә килсәк?*

– Әлфия Авзалова белән яңа концерт программасы әзерләдек.

*– Телевизордан сезнең Татарстан баянчылары турында берничә тапшыруыгызны караган идек. Тагын булырмы алар?*

– Булыр. Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында.

*– Былтыр Архангельск сабан туена тикле барып җиткәнсез икән...*

– Әйе. Беренче тапкыр ул шәһәрдә дәүләт делегациясе составында булган идем. Сабантуйның нигез ташларын салуда Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин, Казан мэры К.Исхаков белән бергә катнаштым. Бу шәһәр тарихында беренче мәртәбә уздырылды ул. Сабантуйны оештыруда анда яшәүче милләттәшебез Рим Кәлимуллин зур тырышлык куйды.

*– Башка артистлар белән элемтәләрегез ничегрәк?*

– Яхшы. Вафирә Гыйззәтуллина белән Ташкент, Иваново, Новосибирск, Төмән, Мурманск шәһәрләрендә булдык. Концертларыбызда Татарстанның халык артисты Рәшит Сабиров, пианист М.Коварская һәм Казан дәүләт консерваториясе профессоры Марат Әхмәтов катнашты. Остазым, укытучым Мәсгут Имашев юбилеенда уйнарга туры килде.

*– «Татар җыры-2000»дә ике куян койрыгын тоттыгыз шикелле...*

– Нәкъ шулай. Җырчы янында Р.Вәлиев (тальян), Н.Мөхәммәтҗанов (баян) һәм мин (хромка) җырлы-биюле көйләр уйнап тамашачыларны каршы алдык. Тәнәфес вакытында биеттек, җырлаттык... Ә концерт вакытында иң истә калганы Флера Сөләйманова белән чыгыш ясаганнан соң Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең безгә чәчәк бәйләме бирүе булды. Президент үзе!

*«Ватаным Татарстан», 2001, 20 апрель*
*Әңгәмәдәш – Чулпан Фәрхетдинова*

# БАЯНЧЫНЫҢ ЭШЛЕКЛЕ ҖӘЕ

Быел танылган баянчы Кирам Сатиевка «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Беркөнне яшь җырчы Илназ Минвәлиев белән алар редакциябезгә кунакка да килде. Быел яз-җәй айларында гастроль сәфәрләрендә күп йөргәннәр. Куанычларын безнең белән дә уртаклаштылар.

*– Быел Әдәбият һәм сәнгать елында хәтерегездә калырдай нинди вакыйгалар булды, нинди эшләр башкардыгыз?*

– Без яшь җырчы Илназ Минвәлиев белән Татарстаннан читтә алты шәһәрдә чыгыш ясадык. Пермь краенда әдәбият һәм сәнгать көннәрендә дә катнаштык. Татарстанның Казакъстандагы вәкаләтле вәкиле Илдус Тарханов чакыруы буенча Казакъстан башкаласы Астана шәһәренә дә барып чыктык. Воронеж, Архангельск шәһәрләрендә концерт бирдек. Бөтен җирдә яхшы каршы алдылар. Казакъстанның Астана, Алма-Ата шәһәрләрендә үзебезнең татар җырларын сагынып көткәннәр. «Олы юлның тузаны», «Үтте дә китте яшьлегем», «Идел суы ага торыр», «Акъяр» кебек халык көйләрен һәм мәшһүр авторларыбызның җырларын яхшы ук беләләр, кушылып җырлыйлар. Яшь, талантлы җырчы Илназ Минвәлиев белән без күптән түгел генә эшли башладык. Пермь шәһәренә чакыру алгач, миңа: «Үзеңә лаек кеше тап», – диделәр. Аңа кадәр Татарстанның күп шәһәр-районнарында концертлар биргән идек. Һич икеләнмичә Пермьгә дә Илназны алдым.

2006 ел Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителү уңаеннан шактый эш эшләргә өлгергәнбез. Татарстанның шактый авыл-шәһәрләрендә булдык. Түбән Каманың «Мунча ташы» эстрада миниатюралар театрында эшләүче дусларыбыз безне күп кенә күренекле шәхесләр биргән Шәңгәлче авылы сабан туена чакырды. Казан мэры Илсур Метшин да шул авылдан икән, туган авылына кайткан иде. Сара Садыйкованың Гөлшат Зәйнашева шигыренә язган «Идел суы ага торыр» җыры башкарылганда, Илсур әфәнде дә аягүрә басып кул чапты.

*«Мәдәни җомга», 2006, 29 сентябрь*

Татарстан Республикасы
Президенты *М.Ш.Шәймиевкә*
Татарстан әдәбият-сәнгать
осталарыннан

## АЧЫК ХАТ

### Хөрмәтле Минтимер Шәрипович!

2007 елда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе үзенең 70 еллык юбилеен билгеләп үтә. Шул уңайдан әдәбият-сәнгать өлкәсендә зур чаралар уздырылуы көтелә.

Кирам Сатиев – филармониянең, гомумән бөтен татар халкының талантлы баянчыларыннан, оста гармунчыларыннан берсе. Сезнең указларыгыз нигезендә ул Татарстанның атказанган (30.04.1993) һәм халык артисты (03.03.2006) дигән мактаулы исемнәргә лаек булды. Ул – ике китап: «Татар баянчылары», «Ак баян» дигән китапларның авторы һәм «Моңлы саз. Моңлы гомер», «Сагындым, бик сагындым» дигән китапларның автордашы. Өч тапкыр төрле күләмдәге конкурсларда лауреат исеменә лаек булды. Әлмәт музыка училищесында һәм Казан дәүләт консерваториясендә белем алган. Совет Армиясендә хезмәт иткән. Югары белемле музыкант. Баян өчен эшкәртмәләр, җырлар, «Баян һәм оркестр өчен концерт» әсәренең авторы. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнде (28.06.2005).

Кирам Шәйхиҗан улы Сатиев үзенең бөтен гомерен әдәбият-сәнгатьне үстерүгә багышлады, 30 елга якын иҗаты Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе белән бәйле. Ул Советлар Союзының һәм Россиянең төрле почмакларында Татарстанның иң күренекле җырчы-артистлары Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәмдүнә Тимергалиева, Мәсгут Имашев, Габдулла Рәхимкулов, Хәйдәр Бигичев, Флера Сөләйманова, Зөһрә Сәхәбиева, Рафаэль Ильясов һәм башкалар белән күп тапкырлар чыгыш ясады. Аның уйнавын ерак чит илләрдә дә яратып тыңлыйлар.

Бүгенге көндә ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының өлкән укытучысы. Кирам Сатиевның башкарган эшләре бик күп, һәм аларны санап чыгуны максат итеп куймыйбыз да.

Без, Татарстанның әдәбият-сәнгать осталары, филармониянең юбилее уңаеннан Кирам Сатиевны «Россия Федерациясенең ат-

казанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек дип саныйбыз. Минтимер Шәрипович, безнең фикерне Сез дә хупласагыз иде. Иҗатташыбызга шул мактаулы исемне алып бирүдә ярдәм итүегезне өмет итеп:

1. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры К.Н.Нуруллин.

2. Филармониянең сәнгать җитәкчесе, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Россиянең «Алтын Аполлон», Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреатлары И.Г.Шакиров.

3. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты ректоры Р.Р.Юсупов.

4. Татарстанның халык депутаты, Россиянең К.С.Станиславский һәм Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, драматург Т.А.Миңнуллин.

5. Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының халык артисты З.Д.Сөнгатуллина.

6. Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ә.А.Авзалова.

7. Татарстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, «Татар җыры-89» конкурсы лауреаты С.З.Фәтхетдинов.

8. Г.Камал театры директоры Ш.З.Закиров.

9. Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе М.Г.Имашев.

*Казан, 17.09.07*

# КИРАМ САТИЕВНЫҢ ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ЮЛЫ

*1955 елның 21 июлендә* Татарстан Республикасы Актаныш районы Татар Ямалы авылында туа.

*1962–1970* – Татар Ямалы сигезьеллык мәктәбендә укый.

*1970–1974* – Әлмәт музыка училищесында белем ала.

*1974–1979* – Казан дәүләт консерваториясе студенты.

*1979–1981* – Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

*1981 елдан* Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлый.

*1988, 1989* – Татарстан телевидениесеннән беренче һәм икенче сольный концертын күрсәтә.

*1990, 2 июль* – КПССның XXVIII съезды ачылган көнне Үзәк (Мәскәү) телевидениедән сольный концерт бирә.

*1991, 24 апрель* – Актерлар йортында үз әсәрләреннән ике бүлектән торган сольный концерты.

*1992, май* – Ф.Туишев исемендәге конкурста лауреат (1 нче премия).

*1993, 30 апрель* – Татарстан Президенты Указы нигезендә «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелә.

*1996* – «Мәгариф» нәшриятында «Татар баянчылары» исемле китабы басыла.

*2005, август* – Казан шәһәренең меңьеллыгы уңаеннан Россия Президенты медале белән бүләкләнә.

*2005, октябрь* – «Идел-Пресс» нәшриятында «Ак баян» исемле китабы басыла.

*2005, 30 ноябрь* – Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында юбилей кичәсен уздыра. «Баян һәм оркестр өчен концерт» әсәренең премьерасы була. Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләнә.

*2006, 3 март* – Татарстан Президенты Указы белән «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелә.

*2007, 27 октябрь* – туган авылы Татар Ямалыда Кирам Сатиев исемендәге баянчылар һәм гармунчылар фестивале уздырыла һәм мәдәният йортында К.Сатиев музее ачыла.

*2007, 23 ноябрь* – Мәскәүдә, Кремльнең Съездлар сараенда Г.Заволокин исемендәге «Играй, гармонь» дип аталган Россия үзәгенең юбилей концертында чыгыш ясый.

*2008, июль* – Америкага гастрольгә бара. Вашингтонда, Нью-Йоркта концертлар куя, Сан-Францискода беренче тапкыр хөкүмәт дәрәҗәсендә дөньякүләм уздырылган сабантуйда катнаша.

# АВТОРЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

*Минтимер Шәймиев* – Татарстан Республикасы Президенты.

*Фәрит Мөхәммәтшин* – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе.

*Вера Минкина* – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.

*Туфан Миңнуллин* – драматург һәм дәүләт эшлеклесе, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

*Илфак Ибраһимов* – Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Зилә Сөнгатуллина* – Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.

*Кадим Нуруллин* – Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры.

*Рәшит Мостафин* – халыклар дуслыгы орденлы Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең оркестр җитәкчесе, дирижеры, Татарстанның халык артисты.

*Миңгол Галиев* – Татарстанның халык артисты.

*Мәсгут Имашев* – Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Халит Фатыйхов* – Башкортстанның халык артисты.

*Айрат Бариев* – журналист.

*Фәнүс Моратов* – Татарстанның атказанган табибы.

*Хәсән Сатиев* – К.Сатиевның бертуган энесе.

*Хәлим Гайнуллин* – журналист.

*Габделбәр Ризванов* – журналист.

*Марат Әхмәтов* – профессор, скрипкачы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*Илдус Илдарханов* – журналист.

*А.Александров* – журналист.

*Зарина Нигметова* – Казакъстан журналисты.

*Гөлүсә Закирова* – журналист.

*Илнар Хөснуллин* – журналист.

*Ривкат Азиханов* – Үзбәкстан журналисты.

*Рафаэль Җаббаров* – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты.

*Җәмил Шәфигулин* – үзешчән язучы.

*Алсу Хәсәнева* – журналист.

*Чулпан Фәрхетдинова* – журналист.

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш .................................................. 4
Консерватория .................................................. 7
Армия .................................................. 13
Филармония .................................................. 49
Сәнгать күгендәге йолдызлар
Изге кеше иде .................................................. 53
Маэстроның тормыш юлы .................................................. 54
Иң авыр таш .................................................. 56
«Аяклы» тарих .................................................. 57
«Сара безнең белән бара» .................................................. 58
Аңа уйнау уен эш түгел .................................................. 59
Моң сарыла йөрәк түреннән
Сагыну .................................................. 61
Ташчы кызга .................................................. 62
Яратам .................................................. 62
Сөйгәнемне эзлим .................................................. 63
Иделем таңнары .................................................. 64
Яшьлек гөле .................................................. 64
Туй бүләге (теләге) .................................................. 65
Батырлар .................................................. 65
Артта калды студент еллары .................................................. 66
Бәлки, очрашырбыз... .................................................. 67
Андый дуслар кирәк түгелләр .................................................. 67
Әйт дөресен! .................................................. 68
Бәлки, миндер синең эзләгәнең? .................................................. 69
«Яшьлек үтә...» .................................................. 70
Үтте яшьлек .................................................. 70
«Ник соң болай үтте минем яшьлек?..» .................................................. 70
Арысланга – Куян паспорты (*Мәсәл*) .................................................. 71
Куян белән Бүре (*Мәсәл*) .................................................. 71
Хәйләкәр Төлке (*Мәсәл*) .................................................. 71
«Матур апа» .................................................. 72
Син генә бит маяк юлымда .................................................. 73
Тормыш чакыра .................................................. 74
Җавап көтәм .................................................. 75
Җир астыннан юллар юк .................................................. 76
Мамык мендәр һаман чылана .................................................. 76
«Катлаулы бер зур хуҗалык...» .................................................. 77

«Кыр үрдәкләре очар, күлләр тонар...» .................................. 77
Кырларым, басуларым .................................................................. 78
Шүрәле, шүрәле... .......................................................................... 81
Нигә оныттың? .............................................................................. 82
Син генә ......................................................................................... 84
Җырлар өйрән куш каеннан ........................................................ 85
Йокы ............................................................................................... 86
Килдуразым ................................................................................... 87
Сине эзләдем ................................................................................. 88
Төшләремә керәсең ...................................................................... 89
Кече Чынлы, яратуың чынмы? .................................................... 90
Химбат таңнары ........................................................................... 92
Акбаш тугайлары .......................................................................... 93
Илсөяр ............................................................................................ 94
Сөюем хакына ............................................................................... 95
Китеп бардың ............................................................................... 96

Гомер үтә икән уй уйлап
Афоризмнар ................................................................................... 97
Фонограмма һәм заман ................................................................ 104
13 саны инсаны ............................................................................ 107
Авыл, мәдәният, без... .................................................................. 108
Без дә төшеп калмадык... ............................................................ 112
Кызлар исеме белән аталган җырлар ........................................ 113
Архангельнең үз Риме бар .......................................................... 115

Юморескалар
Беднең мөгедләр ........................................................................... 117
Микрофонны тота белмисез ....................................................... 119
Артистлар ит ярата ...................................................................... 120
Үзешчән кондукторлар ................................................................ 121
Ашыйсы килә, яшисе килә .......................................................... 123
Кыргый утрау ............................................................................... 125
Өч борынга керү .......................................................................... 127
Кирам Сатиев кытыклары ........................................................... 128

Кирам – сәхнә өчен туган талант
*И.Ибраһимов*. Афәрин, якташ! ................................................ 131
*К.Нуруллин*. Филармония горурлыгы .................................... 132
*Р.Мостафин*. Кирам Сатиев – «эш аты» ................................ 132
*З.Сөнгатуллина*. Консерватория шәкерте ............................ 133
*Ф.Моратов*. Якташым Кирам .................................................. 134
*В.Минкина*. Марсельнең иң яраткан баянчысы ................... 135
*М.Галиев*. «Баяның һәрчак чыңлап торсын» ......................... 136
*Х.Фатыйхов*. Дустым, иҗатташым ......................................... 137

Мәскәү Кремлендә – татар моңнары ........................................ 138
*А.Бариев.* Кирам Сатиев музейлы булды ............................. 138
*Х.Гайнуллин, Г.Ризванов.* Ленинградта – татар җырлары ...... 139
*Г.Ризванов.* Сургут кайнарлыгы ............................................... 140
*М.Әхмәтов.* Мосафир сәфәрдән кайтты ................................ 140
*И.Илдарханов.* Салкын диңгез буен җылыту ......................... 140
*А.Александров.* Сәхнә өчен туган талант .............................. 141
*З.Нигметова.* Сабантуй вместе с «Отаном» ......................... 141
*Г.Закирова.* Татарның моңлы баласы ...................................... 141
*И.Хөснуллин.* Төркиядә ................................................................ 142
*М.Имашев.* Талантлар канат чыгарган уку йорты ............. 143
*Р.Азиханов.* Песни, монологи, стихи... ................................... 144
*Р.Җаббаров.* Курамша, Кирамша һәм К° ................................. 144
*Х.Сатиев.* Ул – гаиләбез горурлыгы ........................................ 145
*Җ.Шәфигуллин.* Ак баянга мәдхия! ........................................ 146
Шәҗәрә ............................................................ 147
Татар гармуны Американы яулады (*Әңгәмәдәш А.Хәсәнова*) 148
Китап та яза, көй дә, яшь шулай бер көйгә (*Әңгәмәдәш Ч.Фәр-хетдинова*) ....................................................................... 150
Баянчының эшлекле җәе .............................................................. 152
Ачык хат ........................................................................................ 153

Кирам Сатиевның тормыш һәм иҗат юлы .................................. 155
Авторлар турында белешмә ............................................................ 156

Литературно-художественное издание

***Сатиев** Кирам Шайхианович*

КОНСЕРВАТОРИЯ. АРМИЯ. ФИЛАРМОНИЯ

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Сатиев** Кирам Шәйхиҗан улы*

КОНСЕРВАТОРИЯ. АРМИЯ. ФИЛАРМОНИЯ

Мөхәррире *Р.Н.Шакирова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә
салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.11.2009.
Форматы 84 ´ $108^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 8,40 + вкл. 1,68.
Тиражы 1000 экз. Заказ В-1621.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru  E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.